PRESSA

1926–1991 ЕЛЛАРДА АЗАТ ХАТЫН

№ 1 / 2022

СӨЕМБИКӘ

ISSN 0869-1398



ХАЙП
һәм әхлак
кайсы җиңәр

ӘНИЕМНЕҢ
туй күлмәге
яңа проект

яңача
әзерләнгән
ЧУРТАН БАЛЫГЫ

Фәнзилә ҖӘҮҺӘРОВА: «Фольклор – океаннан мәрҗәннәр эзләү ул».

PRESSA

Әнинең туй күлмәге...



Әниемнең туй күлмәге...
Сезнең гаиләнең матур
бер ядкаре.
Кадерле кешегезнең
яшьлегеннән бер кайтаваз.
Аның иң бәхетле бер көненең
шаһиты.
Сакланамы ул сездә?
Аны кулга алгач, йөзе балкып
киткән әниегез нәрсәләр искә
төшерә, нинди истәлекләр
сөйли?
Бездә яңа проект: әниегезнең
туй күлмәген киеп көзге
алдында бөтерелгән
мизгелне сурәтләгән
фотосурәтләрегезне көтәбез.
(«Минем кыз чагым син,
кызым!» – дип әйтәдер
әниегез сезгә карап.
Яратып, сөенеп, аз гына
моңсуланып...)
Тагын – аларның туй көненнән
бер мизгел дә көтәбез!

■ Алсу төстәге бу күлмәк һәрвакыт күз алдымда. Дүрт көнгә сузылган туй мәҗлесен бизәгән кәләш күлмәге! Киләсе елга әтием белән әниемнең никахына – 39 ел. Димәк, кавышу көннәренең шаһиты булган күлмәккә дә – шуның кадәр.
Шаһит дигәннән. Шаһитлары туйга кайтып җитә алмый аларның. Нәтиҗәдә... Тагын бер яңа гаилә туа! Әтинең өчтуган сеңлесен һәм икенче бер дустын шаһитлар итеп утырталар. Туйда танышу бу икәүнең дә, әйткәнемчә, кавышуы белән тәгәлләнә. Аларның олы уллары өйләнгәндә мин тантанага әниемнең алсу төстәге шушы туй күлмәген киеп бардым...

Алсу ГАЛИМОВА.
Казан.

Фото: Анна Арахамия

Сөй гомерне, сөй халыкны, сөй халыкның дөньясын!



© «Сөембикә» 2022



Фото: Анна Арахамия

Ежемесячное литературно-художественное и культурно-просветительское электронное периодическое издание на татарском, русском языках для женщин и семьи.

Территория распространения: Российская Федерация, зарубежные страны

Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендәге күзәтчелек буенча Федераль хезмәтендә (Роскомнадзор) 2015 елның 18 маенда «Сююмбике» дип теркәлгән. Теркәү таныклыгы Эл № ФС 77-61814

Язмалар авторның тулы адресы күрсәтелеп, паспорт мәгълүматлары, пенсия иминияте таныклыгы, ИНН таныклыгының ксерокс күчермәләре белән бергә җибәрелгәндә генә кабул ителә.

Кульязмаларга бәя бирелми, алар кире кайтарылмый.

Баш мөхәррир
Л. Н. Маликова

Редколлегия:
Зәлия Ахунова, Ирада Әюпова, Зилә Вәлиева, Гөлүсә Батталова, Эльмира Зарипова, Кадрия Идрисова, Альбина Насыйрова, Алсу Нәбиева, Сәрия Сабурская, Гүзәл Сәгыйтова, Нурия Һашимова, Рафаэль Шәвәлиев.

Редакциянең гомуми телефоны 222-09-77

Җитәкче урынбасары 222-09-78
Рәмзия Кашапова
Баш мөхәррир урынбасары 222-09-78
Гөлнур Хәсәншина
Җаваплы сәркатип
Алсу Шакирова
Әдәби мөхәррир
Эльмира Закирова
Сайт мөхәррире
Камилә Димөхәммәтова

Автор фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.

Реклама текстлары аны бирүчеләр җаваплылыгында.

Редакциянең язмача рөхсәтеннән башка материалларны «Сөембикә»дән күчереп басу тыела.

Тышлыкта:
Фәнзилә Җәүһәрова
Фото: Анна Арахамия

Мөхәррирләр
Чулпан Галиәхмәтова
Сөмбел Гаффарова
Фәгыйлә Шакирова
Верстка
Резеда Галиуллина
Корректор
Фирдәвес Исмәгыйлева
Фотокорреспондент
Анна Арахамия
Гамәли хезмәткәрләр
Ильмира Сөләйманова
Виталий Матвеев

Формат: 225х290 мм
Күләме 64 бит

Басарга кул куелды: 21.12.2021 ел.
Чыгу көне: 28.12.2021 ел.
Заказ Е-4272
Тираж 10100

Учредитель: Акционерное общество «Татмедиа»



ТР «Татмедиа» Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр республика агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.

Басма Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча федераль агентлык ярдәмендә нәшер ителә

Редакция адресы: 420066, Казан, Декабристлар урамы, 2 нче йорт.
www.syuyumbike.ru
E-mail: suumbike@tatmedia.com
ssuum@yandex.ru
тел./факс: (843) 222-09-77

Язылу индексы
ПАП рәсми каталогы буенча:
Татарстанда П2204 (ярты еллык), П8299 (берьеллык)
Татарстаннан читтә: П0279

Банк реквизитлары:
Филиал АО «ТАТМЕДИА»
«Редакция журнала «Сююмбикә»
Расч/счет 40702810600020010309
кор/сч 30101810000000000805
в ПАО «АК БАРС» БАНК г. Казань
ИНН 1655144950
БИК 049205805
КПП 165802002

16+




Фото: art16.ru@Елена Сунгатова

З. Батраев. «Кышкы көн»

Баш мөхәррир сүзе



Кадерле укучым!

Яңа 2022 елга да аяк бастык. Ел башында, артка борылып карап, узган елга яңача бер күз ташлау, нәтиҗәләр ясау гадәте сездә дә бармы ул? Редакциябез өчен 2021 ел җиңелләрдән булмады. Ике ветераныбыз – журналист, язучы, тәрҗемәче Саимә апа Ибраһимова һәм журналист, «Мөслимә» хатын-кызлар оешмасы җитәкчесе Әлмира апа Әдиатуллиналарны соңгы юлга озаттык...

Әмма тормышта югалтулар белән табышлар гел янәшә йөри. Уңышларыбыз да булды! «Күп төсмерле Россия» / «Многоликая Россия» Бөтенроссия ачык журналистлар конкурсында, «Милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләр мәсьәләләрен яктырту» республика журналистлар бәйгесендә икенче урынга лаек булдык. Ел дәвамында «Татар гаиләсе / үрнәк алыгыз» проектын алып бардык. Республикабыз буйлап йөреп, башкаларга үрнәк булырдай матур, тату татар гаиләләрен барладык. Бик күп чакрымнар уздык. Әллә никадәр язмышлар белән очраштык... (Җиңүче гаиләләрне котлау тантанасыннан фоторепортаж – журналыбызның 32–33 нче битләрендә).

Өр-яңа елга аяк бастык. Күңелдә-уйда – яңа планнар, проектлар... Әйе, әлбәттә, бар алар! Һәм һәрберсе сезне – укучыларыбызны күз алдында тотып туды.

Элеккеге редакторыбыз Роза ханым Туфитуллова әйткән бер сүз күңелемә кереп калды: «Тиешле нәтиҗәгә ирешә алмасаң да, максатыңа таба ясаган һәр адымың барыбер бу дөньяны үзгәртә», – дигән иде ул.

Кылган эш-гамәлләребез бераз булса да дөньяны үзгәртсә иде...

Яратып,
Лариса МАЛИКОВА

Безнең тышлыкта



«Фольклор ул – кешене кеше буларак саклап калу вакцинасы да. Фольклор аркылы кешенең җәмгыятьтә яшәрлек, аның каршылыкларына каршы торырлык табигый иммунитеты формалаша. Шуңа балалар фольклоры материалын балалар бакчаларына, мәктәпләргә махсус кертергә кирәк.»



10

«Ырымнарга ышану көчле бездә»

Раилә Хәялиева

14



«Аның үз юлы...»

Чулпан Галиәхмәтова

16



«Мин үзем дә Ркаил!»

Эльмира Закирова

20



Соңга калмаска иде...

Алсу Шакирова

ЭЧТӘЛЕК

Заман һәм без

Хайп нигә кызык? 6
Чулпан Галиәхмәтова

Татар дөньясы

Әнеки 24
Саимә Сабирова

Бер-береңә юл кую 27
Сәйдә абыстай Аппакова

«Син аларга җан өргәнсең...» 28
Зәлия Ахунова

Сез – республиканың йөзе 32
Гөлнур Хәсәншина

Мәдәни тормыш

Сагышларны таратырга... Мәңгегә яратырга... 34
Разил Вәлиев

Көндәшләр 36
Миләүшә Каһарманова

Новеллалар 41
Айдар Хәлим

Яшәеш

Бу яшьләргә ни җитми? 43
Марат Кәбиров

Улым, газизем... яки яшәү өчен көрәш 52
Гөлнур Сафиуллина

Хуҗабикә

Яшь әни: сорау–җавап 56

Бәйрәмнән соң дөрес туклану 58

Эч яссы булсын өчен 59

Өйнең яме – гөлләрдә! 62

Тест&йолдызнамә 63

Рәссам сәхифәсе: кайту 64
Зилә Нигъмәтуллина

44



Зөлфәт һәм Фирая
Филисә Хәкимова

48



«Фатыйма, тимер капкаң ач, ач!»
Гөлнур Хәсәншина

60



Яңа елдан – яңача!
Алсу Шакирова



ХАЙП НИГӘ КЫЗЫК?



Чулпан
ГАЛИӘХМӘТОВА

Эпатаж, низаг, бөтен шәхси тормышны күрсәтү... Бүген үзләрен блогер дип йөргән кешеләр арасында бу нормага әйләнә бара, бигрәк тә федераль дәрәҗәдә. Татар җәмәгатьчелегендә әлегә әхлак дигән төшенчә бар, әмма киләчәктә безнең җәмгыять өчен дә гадәти хәлгә әйләнмәс дип беркем ышандыра алмый. Социаль челтәрләрдәге татар аудиториясендә юк юк та әлеге күренеш килеп чыга. Замана теле белән әйтсәк, хайп дип атала ул. Һәм аның таралуында, хөрмәтле укучыларыбыз, сезнең белән безнең турыдан-туры катнашыбыз бар. Хайпның мәгънәсе нәрсәдә? Ни өчен ул безгә шулкадәр кызыклы? Аны туктатып буламы? Язмада экспертларыбыз белән шул хакта уйланырбыз.

Әрсез хайп

«Хайп» сүзе инглиз теленнән әрсез, бәйләнчек, агрессив реклама дип тәрҗемә ителә. Аның максаты гапгади – ясалма рәвештә ыгы-зыгы тудырып, киң аудиториягә танылырга тырышу. Әлеге термин Америкада XX гасыр башында барлыкка килә. КФУның Гомум һәм этник социология кафедрасы доценты Лилия Егорова әйтүенчә, бу сүз көнкүреш куллнылышка икътисадтан кергән. Икътисадта финанс пирамидалар принципы буенча эшләгән хайп проектлар булган. Ягъни яңа килгән инвесторлар хисабыннан башлангычта торган инвесторларга зур процент түләү. Андый проектларның гомере озын булмаган. Инвесторлар килми башлагач, эшчәнлек туктатылган. 2000 нче еллар башында әлеге төшенчә Америка яшьләре арасында кулланылышка керә. Ун елдан соң аны Россиягә рэперлар алып керә. Хайп сүзен алар җырларында, видеороликларында кулланалар. Ул коммуникацион процесс буларак кабул ителә башлый. Доцент әйтүенчә, 2017 елда илдәге иң популяр сүзләр рейтингында бу термин өченче урында тора.

Беренче урында – биткоин. Хәзер хайпны берәр шәхесне кыска вакыт аралыгында киң аудиториягә таныту өчен пиар стратегия буларак кулланалар, чөнки ул бик тиз барлыкка килә, вирус кебек тарала, үзенә күп игътибар җәлеп итә һәм озак та тормый актуальлеген югалта.

Хайп бүгенге көндә үтә популяр һәм аны бөтен кеше кулланырга тырыша. Җитмәсә, аның өчен хәзер идеаль мәйдан – социаль челтәрләр бар. Мәгълүмат секунд эчендә тарала. Халыкны шаккаттырып, аның игътибарын җәлеп итү теләге һәрвакыт булган, әмма билгеле бер кысаларда гына. Медиашәхесләр үзләре турында ялган мәгълүматлар тараткан, аерылышулары, хыянәтләре турында сөйләгән. Бу – сары матбугатның чәчәк атуына китерде.

Пропаганда белән бер рәттән, мәдәни-агарту функциясен башкарган телевидениегә дә хайп тиз арада үтеп керде. Ул хәзерге көндә гадәтти инструментка әйләнде. Финанс чыгымнары да юк. Танылу өчен зәңгәр экраннарда күренергә дә кирәкми, кулында смартфон булган һәркем теләсә кайчан интернетка керә, үзе үк матбугат, мәгълүмат чыганагы була ала. Ситуациягә шәрехләмә генә биреп калмый, теләсә нинди мәгълүматны да тудыра ала.

Нәрсә яратабыз?

– Бүген хайп социаль челтәрләрдә аккаунтларны үстерүдә зур роль уйный. Мәгълүмат күп булган чорда, кешеләр көчле эмоцияләр уяткан хәбәрләрне генә кызыксынып карый, – ди SMM-белгеч Ләйлә Лерон-Бахмутова. – Ул хәбәрне тараткан блогерга тиз арада язылалар, чөнки ахыры ничек беткәнен беләсе килә. Блогерлар гына түгел, матбугат та хайпны аеруча ярата хәзер. Ә блогер исеме матбугатта, бигрәк тә федераль матбугатта чыга икән, ул тагын да популярлаша дигән сүз. Хайпның ике төрле форматы бар: позитив һәм негатив. Позитив хайпны эшләү авыррак, чөнки кешеләр артык кызыксынмый, эмоция белдерми, күзәтми. Негатив хайп күрсәләр инде, тизрәк фикер белдерергә тырышалар – язалар, хәтта талашып китәләр. Бу блогер өчен кулай гына. Инстаграмның алгоритмнары аккаунтны кызык дип табып, аны кулланучыларга тәкъдим итә башлый – популярлар рәтенә кертә.



КФУның Гомум һәм этник социология кафедрасы доценты, социология фәннәре кандидаты Лилия ЕГОРОВА: «Интеллектуаль үсеш булганда гына негатив хайпларга урын калмаячак, чөнки алар кызыксызга әйләнәчәк».

Негатив хайпка ихтыяҗның шуның кадәр зур булуын гап-гади итеп аңлатырга була. Халыкның күпчелегенә читләр тормышыннан хәбәрдар булу ошый. Яратмаган күршеме ул, танылган сәхнә кешесеме – мөһим түгел. Гайбәт элек-электән үк булган. Элек аны пышылдап кына, колактан-колакка гына сөйләсәләр, хәзер инстаграм ише социаль челтәрләр гайбәт оясына әйләнде. Ихтыяҗ булгач, тәкъдим тумый калмый.

– Кешенең әхлагы, рухи үсеше, белеме тәэсир итә алмаган инстинктлары бар. Инстинктларда кеше кайгысына сөенү эстетикасы өстенлек итә. Матбугатны анализласак, статистика буенча, менә шул инстинктны тудырган язмаларга (үлү, аерылышу, фаҗига турындагы хәбәрләр – *Ч. Г.*) укучылар күбрәк игътибар итә. Бу төр хәбәрләрне укыганда минем тормышым чагыштырмача яхшы икән әле дигән уй килми калмый аңа... Хәзер кеше кайгысына сөенү эстетикасы интернет ярдәмендә тиражга чыкты. Җитмәсә, интерактивлылык барлыкка килде. Ягъни социаль челтәрләрне кулланучы фикер белдерә ала, үзенчә бу ситуациядә «катнаша». Монысы инде икеләтә рәхәтлек бирә, – дип аңлата кешеләрнең негатив хайпка тартылуын КФУның Психология һәм белем бирү институтының педагогика психологиясе кафедрасы доценты, психология фәннәре кандидаты Рамил Гарифуллин. Доцент фикеренчә, хайпның популярлашуында безнең инстинктлар «гаепле».

Ә әхлак?!

Киң масса катламының нәрсәгә битараф булмавын аңлаган, бушка гына популярлык казанырга теләгән блогерлар фантазияләрен эшкә җигә. Кызганыч, алар негатив хайпны күбрәк куллана. Хәтта әхлак кысаларыннан чыгып китә башлыйлар. Хәзер пранк блогерлык (кешене уңайсыз хәлгә куеп, аннан көлү) популярлаша. Аерым блогерлар хәтта ни кыланганын белештерми башлый кебек. Мәсәлән, Мәскәүдә бер блогер Бөек Ватан сугышы ветераны портретына кече йомышын үтәгәнен видеога төшереп, аны интернет киңлекләренә элә. Ә сәхнә йолдызлары, хайп тудырырга теләп, тормышларын реалити-шоуга әйләндерә: җыр бүлешәләр, аерылышалар, бер-берсенә пычрак аталар, елыйлар... Әйткәнебезчә, халык драманы күзәтергә ярата инде ул. Күптән түгел шулай Татарстан эстрадасының бер җырчы гаиләсе аерылышуын бөтен республика белән карап, күзәтеп бардык. Әйе, ул тарих инде онытылды, хайпның төп үзенчәлеге дә шунда: тиз онытыла. Әмма җырчылар бу хайп аркасында язылучылар санын арттырды. Дөрес, җыйган аудиторияне кире таратмау да зур көч сорый. Моның өчен блогерга йә атна саен хайп ясарга, йә язылучылар өчен кызыклы һәм файдалы мәгълүмат чыгарып торырга кирәк булачак. Авыр эш, килешәсездер. Атна саен низаг чыгарып йөреп булмый бит...

– Блогерларның төрлесе була. Кемдер хайпны эләктереп алып,

Фото: www.pixabay.com

PRESSA

Хайпның максаты гап-гади – ясалма рәвештә ыгы-зыгы тудырып, халык арасында танылырга тырышу.

аны байрак итеп күтәреп йөри, чөнки моның хәзерге вакытта халыкка, матбугатка кызык икәнен аңлый. Хәтта билгеле бер сценарий буенча яши башлыйлар, – ди Ләйлә Лерон-Бахмутова. – Әмма күпчелек блогерлар хайпсыз үсәргә тырыша. Мин Казан блогерлары белән аралашып торам. Алар негатив хайп яклы түгел – хайп ясыйм әле дип эшләми контентын. Күп очракта уйлап бетермичә, аудитория, мохитне аңламаганнан, негатив хайпка эләккәннәре бар. Әлбәттә, алар хайп «тоттым», миңа кешеләр килде дип сөенеп утырмый. Бу вазгыятьне ничек үзгәртим икән дип каушап калалар.

Күптән түгел Чистай блогеры Гүзәл Хөснетдинова оештырган уеннарының берсендә катнашучыларга кабер казып, шунда төн уртасында бер сәгать ятып торырга кушты. Бу республика җәмәгатьчелегендә фикерләр каршылыгы тудырды. Матбугат күтәреп алды, блогердан интервью алырга тырыштылар. Ул хайпка әйләнде. Гүзәл әлеге биремне алдан уйлап, үзенә игътибар тудырыр өчен эшләгәнме йә уйламыйча гынамы бу хакта үзеннән җавап ала алмадык. Блогер чит илдә ял итәм, дип кенә җавап кайтарды. Ә моңа кадәр үз социаль челтәрләрендә: «Балалар йортына ярдәм итәр өчен миллионнар җыйганда минем хакта беркем сөйләми иде», – дип, үпкәсен белдергән иде. «Хайпны үз мәнфәгатенә эшләтүчеләр дә бар, – ди бу җәһәттән SMM-белгеч. – Мәсәлән, блогер Гүзәл Хөснетдинова хайпны «тотып алды». Аңа күп язылдылар, товар сатучылар аңа тиз арада реклама бирә башлады, чөнки аңлыйлар: хәзер бу блогерга федераль матбугат игътибар итә, интервью ала, димәк, аның белән кызыксынучылар саны арта. Гүзәл югалып калмады, әлеге ситуациядән акча да җыеп калды».

Шунысы да бар, бу чорда блогер белән хокук саклау органнары да кызыксына башлады, дип яздылар матбугатта. Татарстан Республикасы Эчке эшләр министрлыгының матбугат хезмәте мәгълүматларына караганда, полиция хезмәткәрләре матбугатны һәм социаль челтәрләрне даими рәвештә күзәтеп бара, Россия кануннарын бозган видеороликлар табылса, җаваплылыкка тарта. Соңгы вакытта Россия күләмендә блогер-



Айназ ГАБИДУЛЛИНА, татар блогеры

Социаль челтәрләрдә төрле аккаунтлар бар. Мин аларны ике төрлегә бүләм: берсе фонарь кебек, һаман яктыртып тора. Аларга белем арттырыр, кәеф күтәрер өчен керәсең. Икенчесе: салют аккаунтлар. Эмоцияләр тудыра, «тавышы» көчле, битараф калып булмый, әмма ул функциональ түгел. Хайп та салют эффекты бирә. Халыкка нигә шуның кадәр кызыклы булуын болайрак аңлыйм: элек китап укыганнар, кинофильмнар караганнар. Анда кызыклы сюжет, кискен үзгәрешләр, яраткан йә күралмаган геройлар... Укыганда, кино караганда дөньяңны онытасың. Хәзер шуның кадәр ялкауландык, эмоцияләрне бик тиз генә чыгарырга кирәк безгә. Озаклап китап укып утырасы да, фильмнар карыйсы да килми. Җитмәсә, дөньяда килеп туган пандемия дә тәэсир итми калмады. Күпләр өчен бөтен кызык тормыш – телефондагы социаль челтәрләрдә. Блогерлар тормышын сериал караган кебек карап баралар. Башка җирдән эмоция эзләүнең кирәге дә калмый. Хайп менә шушы аудиторияне тотып тору өчен кирәк тә инде блогерга. Әмма хайп аңлы кешеләр белән идарә итә алмый, чөнки андыйлар социаль челтәрләргә нәрсәгә кергәнен аңлап керә. Кеше тормышын карап, бушка вакыт уздырмый алар.

Мине хайп белән танылды дип әйтүчеләр белән килешмим. Әйе, мин уйлап тапкан авыл апасы Мөнирә образы мине халыкка танытты. Әмма бу хайп түгел иде. Ягъни мин хәзер шушы образны тудырам да, үземә язылучылар җыям дип башламадым ул проектны. Аннан соң мошенникларның акчабызны урлавын язуымны да хайп ясарга тырышасың, дип тәнкыйтьләүчеләр булды. Әмма аннан да хайп коралы ясамадым. Бары тик үз тәҗрибәбезне сөйләп, башкаларга ныграк сакланырга кирәклеген аңлатасым килгән иде. Шәхсән үзем хайпны яратып бетермим. Ул озакка сузылачак феномен дип тә санамыйм. Әйе, хайп белән язылучылар санын арттырып була, әмма аларны тотып тору өчен атна саен хайп кирәк булачак. Ягъни шундый яшәү рәвеше тудырырга кирәк. Әмма бу бик зур стресс дип саныйм. Йә инде бернинди принципларны саклый белмәгән алдакчыга әйләнергә мөмкин. Инстаграм өчен яшәү дөрес түгелдер ул. Ә үзеңә кызык булырлык итеп тормышыңны корып, хобби-лар, яраткан эшең, барган сәяхәтләреңне социаль челтәрләрдә күрсәтсәң, шуның белән язылучыларыңны илһамландырсаң, шуннан да яхшысы булмас. Социаль челтәрләрдә дә үзең булып калырга кирәктер дип саныйм.

ларны җаваплылыкка тарту күренешләре ешая башлады. Кемнәрдер моны ирекне кысу дип кабул итсә, икенчеләр һәр адым өчен җавап бирергә кирәк дип саный.

Хайптан котылып буламы?

«Хайп булган, бар һәм булачак. Бөтен кеше дә хайп ясарга теләп, көндәшлек артса гына, асылы үзгәрергә мөмкин», – ди социолог Лилия Егорова. Белгеч үз-үзебезгә социолог булырга киңәш итә. Аның фикеренчә, ниндидер резонанслы хайп тудыралар икән, димәк, безнең игътибарны башкага күчерергә тырышалар. Ә блогерларның хайп куллануын аларның профессиональ журналистларга каршы куярдай бердәнбер коралы дип саный социолог. «Журналистлар – шәхси һәм профессиональ потенциалы югары булган белгечләр. Белеме булмаган, фикерләү сәләте түбән булганнарга хайп тудырырга гына кала. Башкача ул журналистларга каршы тора алмый. Андый блогерлар бер тапкыр халык игътибарын җәлеп итә ала. Әмма икенче тапкырында ул инде кызыксызга әйләнә», – ди Лилия Егорова.

Хайпка сукырларча капланмас өчен, социолог аңа читтән карарга, миңа ул нинди файда бирә дип уйларга киңәш итә. Әлеге сорауга җавап табарга керешкәч, аның шәхсән сезнең өчен кызыксыз булганы ачыкланачак. Белгеч фикеренчә, 10–15 ел элек булган хәл белән чагыштырганда, җәмгыятьтә гомум эмоциональ, мәдәни, интеллектуаль дәрәҗә арта. Яшьләргә үзләрен үстерер өчен төрле белем алу мәйданнары бар. «Интеллектуаль үсеш булганда гына мәгънәсез хайпларга урын калмаячак, чөнки алар кызыксызга әйләнәчәк. Мондый төр хайплар чоры тиз узар ул», – ди Лилия Егорова.

Ә әлегә үз тормышыбыз турында онытып, кеше тормышын тикшерер өчен, бүген «ачкыч ярыгы» ролен уйнаган социаль челтәрләрне актару белән мәшгульбез. Үз тормышыбыз соры, күңелсез кебек тоела, бераз «борыч» җитми. Хайп әнә шул борычны бирә дә инде. Югыйсә ниндидер низаг ник кызыклы һәм файдалы булырга мөмкин. Ул безгә бөтенләй кагылмый бит. Ә ул низагны күзәтеп, әле, җитмәсә, тозлапборычлап, берничә шәрехләмә дә язсаң, беренчедән, үзеңне акыллы итеп тоя башлыйсың; икенчедән, үзеңне ул тормышның бер өлеше итеп күз алдына китерәсең. Тормышта кызыклы хәрәкәт барлыкка килә кебек. Бу, әлбәттә, иллюзия. Әмма без үзебезне алдалап яшәргә күнеккән шул... Алай рәхәтрәк һәм кызыграк. Әмма шуны да онытмыйк, без рәхәтләнеп алданганда, хайп «тоткан» блогерлар безнең хисаптан акча эшли.



Альберт ШАКИРОВ,
журналист-блогер,
«Юлчы» телевизион проектының
алып баручысы

Социаль челтәрләр һәм аларда аралашучылар, контент алмашучылар саны үскән саен, ул дөньядагы тәртипләрнең, терминнарның безнең тормышка керми хәле юк. Ләкин, күп очракта, бары тик башкаларны гаепле, ә үзеңне тәртипле яки зыян күрүче як итеп күрсәтү өчен, әлеге терминны кирәксә-кирәкмәсә кулланалар. Әлбәттә, көн саен 100 уңай комментарий укып барырга күнеккән кеше үзен кашка тәкә итеп тоя башлый. Шулар арасына бер тискәре фикер керә икән, аны язган кеше «хейтер» була. Теге 100 уңай комментны язучылар да әлеге кешене бик тиз чукып ташлаячак. «Ошамаса карама!», «Аның кадәр булырга кирәк әле!» ише сүзләрне еш күрәсездер. Бүгенге көндә хәтта тәнкыйтькә дә «хейт» һәм «хайп» дип кенә карый башлаучылар күп. Үз фикерләрен тәнкыйть, сатира, ирония, фельетон ише жанр кулланып җиткерергә теләүчеләрне хейтерлар рәтенә кертүне кабул итә алмыйм.

Интернетта исем ясау дип сөйләшү бик сәер әйбер, миңа калса. Челтәрләрдә кеше ниндидер ник (исем) һәм образ тудырып язылучылар җыя, популярлаша. Ул сәхифә бүген бар, иртәгә юк. Язылучылар да килә-китә. Кешенең исеме белән түгел, ул күрсәткән контент белән бәйле барысы да. Әйе, күпчелек язылучылар нәкъ менә гауга көтә һәм шундый контент ярата. Низагта теге яисә бу якны яклап, бик теләп кычкырышырга да мөмкиннәр әле. Мондый материалны оста файдаланучылар да бар, билгеле, әмма гауга белән генә аудиторияне тотып торып булмый. Андый конфликтларның кайтавазлары да ардыра, реаль жаваплылыкка да китереп чыгарырга мөмкин. Хайпның максаты – провокация аша халыкны селкетеп, уятып җибәрү. Күбрәк кайтаваз җыю, шәрехләмәләр туплау. Төрле изге гамәлләр аша хайп ясаучылар да бар. Хайп дигәч тә, гел начар гына дигән сүз түгел. Теге яисә бу материалны, видеоны куйганда аңа кайтаваз ничек булачагын барыбер чамаларга була. Тик шулай да чын хайпның табигате бик примитив. Ул барлык кешедә булган кылларны чиертә. Йә кызгану хисе, йә теләктәшлек, йә нәфрәт, йә кызыгу, йә ашыйсы килү...

Хайп чире бар, димәс идем. Чын хайп – ул интернет аудитория белән эшләүнең бер алымы. Затсыз, түбән, әмма тиз нәтиҗә бирә торган алымы. Хайпка атланырга теләүчеләр иң беренче зыянны үзләренә сала. Беренчедән, аларның исеме шул гауга белән бәйле булып истә калырга мөмкин; икенчедән, үзләре кеше кызыксындырырлык булмасалар, гел хайп ясарга мәҗбүр булачаклар. Кемдер моннан тартынмаска мөмкин, чөнки әхлакый зыянны миллионлаган аудитория һәм рекламадан килгән акча каплый. Ләкин тормышмы икән соң ул?! Андый юлга керү – үз йөзеңне, шәхесеңне югалтуга китерергә һәм аудитория теләгән үтәп торучы курчакка әверелдерергә мөмкин. Андый курчаклар да җитәрлек.

«ЫРЫМНАРГА ЫШАНУ КӨЧЛЕ БЕЗДӘ»


Фото: Анна Арахамия

Фольклор океанынннан мәрҗәннәр эзли ул, югалып барган халык җәүһәрләрен барлый, үткәнне – бүгенгегә, бүгенгене киләчәккә бәйли. Язмамның үзенчәлекле герое – халкыбызны бер түгәрәккә бастырып берләштергән, төбәкләрдә милли тормыш ялкыны кузгаткан «Түгәрәк уен» татар фольклоры фестивален уйлап тапкан, татар ядкарьләренә тузан кундырмый заман яссылыгына салган фольклорчы, галимә – Фәнзилә ҖӘҮҺӘРОВА.



Раилә ХӘЯЛИЕВА

Гореф-гадәт, фольклор дөньясына фән аша гына якын килеп булмыйдыр ул. Аның өчен балачактан ук әбекәйнең итәк җылысын тоярга, тау битләрендә тәгәрәп үсәргә кирәктер сыман?

– Гаҗәп, минем хәтердә балачакның бик күп мизгелләре саклана. Без гаиләдә алты бала үстек. Алар арасында мин иң күп мәзәк белүче, җырлаучы, такмаза сөйләүче идем. Әтием Хәкимулла да нәсел-нәсәп арасында атаклы мәзәкче саналды, ул булган җирдә уен-көлке, җыр, мәзәк була торган иде. Йокы вакыты җиткәч, балалар бакчасыннан качып, үземнән бер-ике яшькә олырак малайлар белән су буена төшеп утырабыз. Кайтыр вакыт җиткәнче агач төбендә мәзәк сүз сөйләшәбез, такмаза әйтәбез, сорау–җавап уйныйбыз.

– Аптыратыйммы?
– Аптырат.
– Аптырат кайда?
– Кесәдә.
– Кесә кайда?
– Киемдә.
– Кием кайда?
– Чөйдә...

Элек бит авылда балаларны бакчага илтү, алып кайту юк иде, үзебез йөрибез, вакытын белеп үзебез кайтабыз. Минем телемдә җырлы такмаклар да күп иде. Анысы да әтидәндер, дим. Кечкенә чакта әти безне гармунга биетә иде, биеткәндә гел такмак әйтә. Яз җитеп, тау битләре ачылуга, «кәҗә сакалы» җыярга барабыз. Аны һәрвакыт

ике уч тутырып алып кайтасы: берсе – гаиләгә, икенчесен ялгыз карчыкларга кертәбез. Мин бик кечкенә вакытларда хәтеремдә (әни – укытучы, әби дә ул вакытта совхозга төрле эшкә йөри иде әле) иртән иртүк безгә бишектә ятучы туганнарымны карарга, безгә күз-колак булырга Маһибәдәрәттәй килеп җитә. Аның үчтеки итүләре, бишек тирбәтүләре, кечкенәләрне уятмасыннар дип, безнең күңелне күрүләре! Ул акча алмый, безнең гаиләдә ашый-эчә, кичен йокларга кайтып китә дә, иртән тагын килә. Ял көннәрендә, бәйрәмнәрдә камыр ризыгы пешерәбез икән – Маһибәдәрәттәйгә кертәсе, аны шимбә мунчасына дәшәсе. Авылындагы ялгыз карчыкларын менә шулай – кирәклекләрен тоеп яшәтер өчен халык үзе бу институтны булдырган икән. Бераз соңрак, әти белән әни атка утырып кунакка киткән вакытларда безнең белән Чибәр абыстай калып тора иде. Ул безнең нәселнең килене, исеме – Мәрхүпҗамал, ә безнең өчен – Чибәр абыстай! Иж-Бубыйдагы кызлар мәдрәсәсендә күпмедер белем алган ул. Безгә «Рисаләи Газизә»дән хикәятләр, Тукай әсәрләрен күпләп яттан сөйли иде. Зәңгәр күзле, һәрчак актан киенгән булыр... Шуңамы, мәктәптә Әмирхан Еникинең «Ак әби»сен укыганнан бирле минем акылымдагы ак әби һәрвакыт зәңгәр күзле... Әтинең авылның икенче башында яшәүчеләр белән ничек исәнләшергә кирәклеген өйрәткәне искә төшә. Зәки җизни янында туктап исәнләшәсе, Мөҗәһит бабайны күрсәң, «Мөҗәһит бабай, исәнмесез, нихәлләрегез бар?» – дип әйтәсе, Габдрахман бабай: «Син кем кызы?» – дип сораса, «Хәкимулланыкы», диясе...

Минем балачактан килгән бик зур хыялым – океанолог булу иде. Ә якын-тирәдәге туганнардан: «Фәнзилә артист була!» дигәнне гел ишетеп үстем. Әмма безнең әни бик таләпчән, чын татар анасы һәм хатыны. Һәрберебезнең тормыш сукмагына карасаң – күпмедер дәрәҗәдә әни сайлаган һөнәр иясе без. Әни әйттеме – әничә булырга тиеш! Ул үзе Казан университетының татар филологиясе бүлеген тәмамлаган. Мине дә шул юнәлешкә җибәрделәр. Укырга кергәч, ике ел әнидән университетны ташларга рөхсәт сорап еладым. Аннан соң филология мине үзенә тарта башлады, уку җиңел бирелде, гел алдынгылар рәтендә булдым. Укуны бетергәндә без, тугыз кешелек төркем, Себергә укытырга китәбез дип шау килдек. Яхшы укыгач, беренчеләр рәтендә комиссия алдына басып, кая китәсен үзебезгә сайлау мөмкинлеге бар иде ул вакытларда. Алдан сөйләшенгәнчә, эшкә юллама кәгазен алырга кергәч, мин Себергә китәм, дидем. Һәм ахырдан шул билгеле булды: Себерне мин берүзем сайлаган булып чыктым. «Каз канаты» ансамбле белән чыгыш ясап йөреп, Наил Алан дәүләт имтиханына соңга калу аркасында дипломсыз чыкты, шул сәбәпле, комиссия алдына иң соңгы кеше булып керде. Рухы шат булсын инде, мине Себергә үзем генә китмәсен дип, ул да Себерне – Төмән өлкәсен сайлады. Себер җире, табигате, андагы татарлар, аларның сөйләшләре, яшәү үзенчәлекләре – барысы да акылга, күңелгә бер сәйлән булып тезелгәннәр... Аннан соң Әстерхан төбәге буенча диссертация язу эшенә керешергә туры килде, анда инде Әстерхан җирләрендә йөреп, җирле халык белән аралашу мөмкинлегем зур булды... Фәнни эшләрем әдәбият өлкәсенә караса да, Аллаһы Тәгалә мине шул рәвешле акрын гына фольклор дөньясына керергә әзерләгән булып чыкты. Ахырдан мин әниемә дә бик рәхмәтле булдым. Татар телен камил белү, сүз куәсен, аның энергетикасын тою буенча табигый күнекмәне филология бүлеге генә үстерә ала дип уйлыйм хәзер.

Фольклор ул – кешене кеше буларак саклап калу вакцинасы.

Фәнни мәгълүмат артыгы белән күп булган заманда ырым-ышануларга урын каламы? Элеккеге ышанулар бүгенге көнгә туры киләме?

– Имләүләр, өшкерү сүзләре, өшкергән вакытта кулланыла торган предметлар... Ырымнарга ышану әле ничек кенә көчле бездә, имче карчыклар да бик популяр. Аларның күбесе, татар тәрбияләләре диюем, күрәзәчелек итмиләр, ләкин кешеләргә җанны, тәнне сихәтләндерү мөмкинлеген киңәш, ниндидер практика-гамәлләр башкару формасында табарга ярдәм итәләр. Шунысы мөһим: барысы да ышануларга таянып эш итә. Алар арасында мөселман динендәге дога белән өшкерүчеләр дә бар. Ышанулар безнең тормышта шактый күп әле. Мисал өчен, кияү егете кызның туй күлмәген алдан күрергә тиеш түгел, дибез, туй күлмәген башка кызга биреп торырга ярамый, дибез, бәбигә узгач, чәчне кистерергә дә, бәйләү бәйләргә дә ярамый... Киләчәкнең рәхәт җиңел булырына өметләр бик аз булган заманда, төрле ышанулар, аларга нисбәтле яшәүче им-томнарга җирлек арта гына.

Безнең заманнан да ниндидер йолалар сакланып калырмы?

– Традицион фольклор, хәзерге заман фольклоры дигән төшенчәләр бар. Әлбәттә, күп кенә традицион жанрлар инде көндәлектән төшеп калды. Башлыча, сәхнәдә, мәктәп дәреслекләрендә, төрле конференция кысаларында гына яши алар. Шул ук вакытта без фольклор иҗат ителми дип тә әйтә алмыйбыз. Фольклор әсәрләрен иҗат итү хәзер бик актив рәвештә интернет аркылы социаль челтәрләрдә, кайбер блогерлар иҗатында бара, җырлар, такмаклар, бәетләр иҗат ителеп тора. Халык бик яратып Болгар җиренә сәяхәт итә. Андагы экскурсияләр вакытында ышануга нисбәтле гаҗәп кызыклы гамәлләр башкарыла. Кече манара тирәсендә җиде тапкыр әйләнсәң, теләк кабул була, имеш, кайбер ташларга кагылып узсаң, тагын нидер була икән... кебек ышануларга корылган гамәлләрне гел күзәтеп киләбез. Шул ук вакытта «менә мондый өр-яңа йолалар барлыкка килде» дип тә кистереп әйтеп булмый. Шулай да безнең мифологик күзаллавыбызга бөтенләй катнашы булмаган Яңа елны каршылау да әллә нинди ритуалларга күмелеп, календарь йола эчтәлеген үзендә туплый башлады. Мәсәлән, Яңа ел каршылаганда табының мул булса – елың да мул була, барың бергә җыелып каршы алсаң – ел буе дус-тату яшисең, курантлар суккан вакытта теләк теләсәң, ул тизрәк чынга аша, кебек дистәләгәнне язып була... Халык менә шундый туктаусыз иҗатта.



Түбән өлкәсе Ялутор районы авылларына оештырылган экспедиция (2008 ел).

Ә менә гаилә-көнкүреш йолаларыннан булган туй, мәетне озату, мәрхүмне искә алу йолалары эчтәлегендә төрки-татар җирлекле ышанулар әле дә сакланып килә. Әлбәттә, аларда да беркадәр үсеш-үзгәрешләр күрәбез. Табигатькә нисбәт иткән, аның көченә ышануга юнәлтелгән йолалар да юкка чыкты дия алмыйбыз. Аларга ышану соңгы вакытларда елларның коры килүләре аркасында тагын да көчәйде. Яңгыр боткалары, Изгеләр, Яхшылар ашлары, Шыйлыклар төрле җирлекләрдә төрле исемнәр белән, үзенчәлекле эчтәлек аермалары белән актив үткәреләләр. Изге урыннарга бару, изге шәхеснең каберен зиярәт кылу, изге чишмәләргә йөрү дә бик популярлашты хәзер. Шул ук вакытта формага үзгәртелгән шартлы эчтәлек салып, театральләштереп уздырылучы ясалма чаралар да бик күп. Болар – мәдәният хезмәткәрләренең планы буенча үткәрергә мәҗбүр ителгән «йола-чаралар». Мине иң борчыганы – балаларны яшьләр, өлкәннәр фольклорына кагылышлы материалга кертү. Балалар бакчаларында «Каз өмәсе» яки «Аулак өй» күренешләрен күрсәткәндә еш кына читенсенеп куярга туры килә, чөнки күренеш шулкадәр ясалма килеп чыга. Мондый ясалма «бәйрәмнәр» оештырасы урында балаларның телен, зәвыгын, зиһенен, фикер йөгереклеген чарлар өчен халык тарафыннан махсус уйлап чыгарылган балалар фольклоры материалы белән эшләсәк, күпкә уңышлы булыр иде. Күрәсең, әлеге материал белән эшләргә өйрәтүче методика юк.

Аннан тагын бер җөмләне ассызыклыйсы килә. Сәхнәдә күрсәтелгән йола күренеше – йола түгел! Аның төп максаты – менә мондый йола да булган дигән фикерне генә җиткерү.

Йола-гадәтләр – кеше тормышындагы бер уен гына түгелме ул?..

– Гомумән, адәм баласы ул һәрвакыт уен белән яши. Галиҗәнап уен! Кем әйтә, туй уен түгел дип? Әлбәттә, уен! Мәет озату йолалары уен түгелме? Ул да уен. Һәр уенның кагыйдәләре бар, төгәл итеп рольләре бүленгән. Исем кушу, сөннәткә утырту, солдатка озату, егетнең кызга тәкъдим ясавы... Бер яктан, без хәзерге заманда бу гадәтләрнең чикләре киңәюен күзәтәбез, икенче яктан якын килсәк, йолага нигезләнгән булырга тиешле гамәлләр халык иҗатын тарайталар да. Мәсәлән, егетләр, сөйгәннәренә үзләренең хатыннары булырга тәкъдим ясауны тулы канлы бер ритулга әйләндереп, шактый креативлык күрсәтеп, сайлаган ярларын шаккаттырырга омтылалар. Бу да – уенның бер төре. Тормыш, гомумән, уен.

Дин һәртөрле ырымнарны этеп чыгарырга тырыша сыман. Бу процесска ничек карыйсыз?

– Теләсә кайсы диннең мәҗүси күзаллаулар белән көрәшергә тырышуы табигый хәл. Элек-электән мәҗүсилектән калган ырым-шырымнарга хорафат дип карау булган диндә, бу көрәш процессы әле дә бара. Бездә дин барыбер татар төсмерле ул. Татар төсмерле дигән сүзнең асылында безнең бик борынгыдан килгән ышанулар системасы ята. Бу бигрәк тә экспедицияләрдә йөргәндә ачык күренә. Мәсәлән, авылга килгәч, теге яисә бу йортка кергәндә бусага алдында идәнгә кадаклап куелган ат дагасына тап буласың. Бусаганы атлап ишек өстенә күз салсаң, анда Аят әл Көрси язылган шәмаил эленгән. Бу – ислам дине белән мәҗүсилекнең берләшүе. Ат дагасы да, шәмаил дә җен-парилардән, хөсетле бәндәләрдән, әшәкелектән саклый дигән ышануга нигезләнеп куелган. Инде мәет озату йолаларындагы мәетне искә алу гамәлләре булган мәетнең өчесен, җидесен, кырыгын үткәрүгә тукталыйк. Әле күптән түгел генә бу йолаларга нисбәтле гаугалар чыккан иде. Согуд Гарәбстанында белем алып кайткан бер төркем муллаларыбыз «Коръәндә ул хакта язылмаган», дип, бу традицияләребезне кысрыклау юлына басканнар иде. Халыкта бу ризасызлык тудырды. Аннан соң җирле Дини нәзарият бу төр ритуаллар башкаруның һәр гаиләдә, беренче чиратта, ислам дине мәдәниятенә нигезләнгән гамәлләр икәнен дәлилләп, халкыбыз аңында меңәрләгән еллар буе килгән бу гадәтләрнең дәвамлы булырга тиешлеген ассызыклады. Бу нисбәттән, әлеге мәҗлесләрдә абыстайларыбызның укыган догаларын, багышлау вакытында йорт, абзар ияләрен, су хуҗаларын да искә алуларын билгеләп үтәсем килә. Халкыбызда әле дә булса теге яисә бу чирдән сихәтләнү йөзеннән, «таң суы алу» дигән им-том бар. Аның асылында безнең бик борынгы «кояшка табыну» заманнарыннан килгән таң кояшының көченә ышану ята. Ә таң суы белән коенган вакытта ислам дине догалары белән генә коену да фарыз. Болар барысы да – официаль диннең максаты глобальләштерү булуга карамастан, халык акылында әле этеп чыгарырга мөмкин булмаган, буыннан-буынга күчеп килә торган ышануларыбыз ятуын дәлилли.

Бар дөнья җаваплылыгын үз кулына алырга тырышкан хатын-кызлар хакында ни уйлыйсыз?

– Бүгенге көндә ир-атларның гаилә терәге булуы бик шартлы. Аларның инде мамонт артыннан йөгерәсе дә, авыр мамонт түшкәсен күтәреп кайтасы да юк. Хәзер авылда мал суйганда да аерым осталар килеп, тиз генә эшне бетереп китәләр. Бүгенге көндә ир-атка йөкләнелгән вазыйфаларның берсе – акча табу. Ә ир-ат акча таба ала торган өлкәләр күп түгел. Хатын-кызның акылы сыгылмалы: кирәк икән теге якка да, бу якка да борыла ала.

Шуңа ул бик тиз генә бер сферадан икенчесенә күчеп, янәдән үз урынын табарга сәләтле. Бүгенге көндә улларын өйләндерергә җыенган әниләрнең булачак киленгә таләпләре элеккечә кала бирә. Алар – килен улымны санларга, өс-башын карарга, тамагын туйдырырга, сәламәт балалар табарга тиеш кебек таләпләр җыелмасы. Шул ук вакытта улына гаиләсен туйдырырга, гаилә хуҗасы булырга тиеш дигәне беренче планга бик куелмый. Бүгенге көндә тырыш ир кеше төп эшен башкарганнан соң, гаиләсенә бераз өстәмә керем алып кайту максатыннан, таксига утырырга, идән җыярга, йөк ташырга, тагын әллә ниләр башкарырга мәҗбүр. Кайсылары чит өлкәләргә чыгып китеп, ике-өч айга бер тапкыр гына гаиләсен күрә ала. Бу, әлбәттә, гаилә башлыгын «эт итә», аның гаилә башы – хуҗасы роленә керер хәле дә, теләге дә калмый. Нәтиҗәдә, «бәхетле гаилә» шартлы төсмер ала. Моны күргән «өнле» ирләр тормышны алай кабаланып көтәргә омтылмыйлар. Аннан тормыш таләпләрен һәркем үз ата-анасы тәрбиясендә вакытта ук күреп үсә. Мәсәлән, әниемнең әтигә булган мөнәсәбәтенә бәйле, мин дә иремне гомер буе ишек төбендә каршы алам, ирем кайтуга өйдә кайнар ризык булуын кайгыртам. Болар – безнең гаиләнең язылмаган кануннары. Нәселгә кызыллык китермичә, нәсел кагыйдәләре белән яшәргә омтылучы халык без. Хәзер ир белән хатынның кулга-кул тотынып, бергә эшләүләрен, бер бизнеста кайнауларын күрү мине бик сөендерә. Ирне мактап, үсендереп тору (безнең татарда ул мәҗбүри!), гаилә дөньясын матур итеп тоту, йортта бәрәкәт булдыру – хатын җилкәсендә. Ирне – хатынга, хатынны иргә карап бәялиләр бит.

Сезнең гаиләдә нинди традицияләр яши?

– Ирем ягыннан да, үземнең дә – әниләребез исән-сау, Аллага шөкер. Шуңа күрә бәйрәмнәрдә, беренче чиратта, әниләребезне зурлыйбыз, аларга игътибар күрсәтергә тырышабыз. Элек-электән калган гадәт – шимбә көнне камыр ризыгы пешереп, мич исе чыгару. Минем өчпочмакларымны авыз итәргә гаилә белән җыелабыз. Аш бүлмәсендәге өстәл артында һәрберебезнең үз урыны бар. Башта ризык әтиебезгә бирелә, аннан улыма, кызыма бирәм. Әтиебез урынына беркем дә утырмый. Мин күп балалы гаиләдә үстем, анда да шулай иде. Без үскән йорттагы өстәлебез әле дә исән, без һаман шунда җыелабыз. Кайда кем утыра иде дип сорасалар, төгәл итеп әйтә алам. Мин кечкенә вакытта, Гаеткә атап, безгә яңа кием бүләк итәләр иде. Бу традицияне әле дә сакларга тырышабыз. Туганнар белән җыелышырга, җыелышкач бергәләп җырларга яратабыз. Балаларым инде күптән укып бетерсәләр дә, әле һаман Казан федераль университетының татар хорына йөриләр. Безнең гаиләдә татар җырлары бик еш яңгырый. Гаилә белән бергәләп сөйләшеп утырырга яратабыз. Өйдән кая гына чыгып китсәк тә, нинди вакытта булуына карамастан, әтисе – миңа, мин әтисенә хәбәр биреп йөрибез. Ватсапта гаиләбезнең төркеме бар. Анда татарча матур итеп хәерле иртәләр әйтелә, тыныч төннәр теләнә, көнгә хисап тотыла, планнар корыла, үтәлеше языла. Кош баласы оясында ни күрсә, очканында шуны кыланыр, ди.

Дөньяда балалар борчуы бик артты. Чирләр, психологик тайпылышлар… Бу күренеш яшь әниләрнең рухи мирасны куллана белмәвеннән килеп чыкмыймы икән?

– Бала тәрбияләү перспективасы куркыныч булган проблемага әйләнеп бара. Бүгенге көндә ата-ана балага табынып яши, табынудан тәм таба. Яки бала психикасына авыр булган бурычлар куела, бала, шуларга күмелеп, югалып кала. Без, уйнап, кагыйдәләргә буйсынырга өйрәнеп үстек. Көннәр буе «Көтүчеле» («Тәпәч» дип тә йөртә идек) уйный идек. Җитез булмасаң, сине берничә сәгать куарга мөмкиннәр. Берәр чакрым йөгереп төшәсең, елап, арып бетәсең, ә кагыйдәне бозарга ярамый! Уеннан чыгасың икән, сине икенче вакыт уенга кертмәячәкләр! Бу – ихтыяр көчен, чыдамлылыкны сыный торган уен. Бүгенге көндә балалар кагыйдәгә буйсынмый, чөнки аларга ул кагыйдәләр куелмый. Тагын бер унбиш-егерме елдан бүгенге 7 яшьлек бала, дөнья тоткасы булып, берәр җирдә эшли башлаячак, җитәкче булачак… Ә алар команда белән эшләүне, билгеле бер кагыйдәләрне үтәргә мәҗбүриятне тоеп үсмиләр. Дөнья көтү барышында шактый авыр хәлгә калырга мөмкинсең бит. Шулай да бу проблемадан чыгу юлы бар дип саныйм мин. Фольклор ул – кешене кеше буларак саклап калу вакцинасы да. Ул вакцинаны дөрес итеп тиешле вакытта тиешле дозада кулланырга өйрәнергә кирәк. Фольклор аркылы кешенең җәмгыятьтә яшәрлек, аның каршылыкларына каршы торырлык табигый иммунитеты формалаша. Шуңа балалар фольклоры материалын балалар бакчаларына, мәктәпләргә махсус кертергә кирәк. Шул рәвешле бала аралашырга, кагыйдәләргә буйсынырга, татарча сөйләшергә өйрәнер, акыл җитезлеген, командада эшли белүен, үзенә таяныч табу мөмкинлеген үстерер иде.

Фольклорны өйрәнергә, традицияләрне дәвам итәргә яшь галимнәр киләме? Үзегез нинди проектлар эшлисез?

– Фольклорга багышланган диссертацияләр язылып тора. Фольклорга килү өчен шактый әзерлек, бу искиткеч дөньяны күрә һәм тоя белү сәләте дә сорала бит. Бүгенге көндә фольклористиканың предмет киңлеге искиткеч зурайды. Кайвакыт экспедициягә җыенганны күреп, фольклор бетте бит инде, кая барасыз, диләр. Әгәр дә халык һәм аның теле яши, традицияләр саклана икән, аның фольклоры да, заман таләпләренә туры китерелеп, үзгәрә-үзгәрә яшәячәк. Халыкның аңын кисеп атып буламыни?! Фольклор ул – энергия, физик закон! Әлбәттә, без хәзер ясалма интеллект барлыкка килгән үзенчәлекле дөньяда яшибез. Киләчәктә инде башка формалар барлыкка килеп, эчтәлеге, гамәлләре, предметлары башка булган йола-гадәтләр туып торырдыр. Әмма фольклор бетә дигән фикерне берничек тә кабул итә алмыйм.

Фольклорчы буларак, җыелган багажым шактый. Өстәлемдә һәрвакыт өем-өем китаплар… Бүгенге көндә «Татар ядкарьләре» дигән шәхси оешманы җитәклим. Социаль челтәрләр аша халык йолалары хакында сөйлибез, күрсәтәбез. Тагын яңа проектлар башкарыр теләгебез бар. Ни генә эшләсәк тә, бары да халкыма хезмәткә!

РЕКЛАМА ХОКУКЫНДА



«Аның үз юлы...»

Үсмерлек чоры. Ата-ана өчен иң зур сынау вакытыдыр бу, мөгаен. Сүзеңне тыңлап, һәрвакыт янда сырпаланган бала көннәрдән бер көнне бөтенләй үзгәрә дә куя. Аңа инде әти-әни абруй түгел, аның үз дөньясы... Бала белән бәйләнешне ничек саклап калырга? Үсмер белән үзеңне ничек тотарга? Бернәрсә булмагандай кыланыргамы, каешка үрелергәме? Кемнәрдер психологка бара, кемнәрдер китаптан, дус кызларыннан акыллы киңәш эзли башлый. Бәлки, безнең геройларыбыз тәҗрибәсе дә ярдәм итәр. Әнинең генә түгел, үсмер фикерләрен дә тыңлап карыйк әле. Яңа рубрикабызның беренче геройлары «Татарстан–Яңа гасыр» телеканалы, «Болгар» радиосы алып баручысы МИЛӘҮШӘ КӘШАФЕТДИНОВА һәм аның кызы ДИАНА.

Диана, сине әниең һәрвакыт аңлыймы?

– Ул миңа һәрвакыт теләктәшлек белдерә. Мәсәлән, чәчемне алсу төскә ул үзе буяды. Бик күп әниләр билгегә зур игътибар бирә. Минем әни андый түгел. Аның өчен иң мөһиме – белемнең башымда булуы. Анда юмор хисе бар, аның белән көлешә-көлешә сөйләшеп була. Үзара аңлашмаулар, конфликтлар була, әмма алар озакка сузылмый. Иң күбе – музыка мәктәбе өчен ачуланадыр. Аның фикеренчә, җитәрлек шөгыльләнмим, мин даими фортепианода уйнарга тиеш. Ә музыка мәктәбендә бары тик үзем өчен генә укыйм, киләчәктә ул миңа кирәк булмаячак, шуңа күрә, аңламыйм, ник баш бәрә-бәрә укырга?! Әни имтиханнар бирә алмас дип куркадыр инде. Әзерләнәм мин, әзерләнәм...

Берәр хәлгә очрасаң, кемгә иң беренче шалтыратачаксың?

– Әнигәдер. Мәсәлән, ул белгән иптәш кызым белән ачуланыштым ди, әнигә шалтыратам. Ул миңа киңәш бирми калмый.

Син нык итеп бизәнеп йөрергә яратасың? Әниең бу уңайдан нәрсә әйтә?

– Ул бизәнмә, дими, әмма төсләрнең дөрес төсмерләрен сайларга куша. Татуировка, чәчне төрле төскә буяу, кара төстәге тырнаклар, макияж, гадәти булмаганча киенү – болар барысы да үз-үзеңне күрсәтү, дөньяга үз позицияңне белдерү өчен кирәк дип уйлыйм. Һәм бу без – үсмерләр өчен бик мөһим. Башкалардан аерылып торасың икән, димәк, син – үзенчәлекле, син – кәттә. Әгәр минем яшьтәшләрем бик тыныч, хәттә бизәнмиләр дә икән, димәк, алар – соры тычкан. Ә андыйлар беркемгә кызык түгел. Үсмерлек чоры бер генә вакыт. Ул чорда бар нәрсәне дә белеп, татып карыйсы килә. Соңыннан тынычланасыңдыр. Башкалардан аерылып торган үсмерләрнең үскәч тә тормышларында үз позицияләре, үз чикләре булачак. Яхшы бит инде!

Диана, телефон экранында әниеңнең берничә тапкыр шалтыратканын күргәч, иң беренче уең?

– Әнинең нәрсәләр уйлап бетергәнен күз алдыма китерәм дә, миңа куркыныч була! Ә мин бит бары ишетмәгәнмен. Юри трубканы алмаган чагым юк. Шалтыраткач, мине әрли инде! Үпкәләмим, аның борчылганын аңлыйм.

Әниеңә барлык дусларың, булган хәлләр турында да сөйлисеңме? Сөйләп бетермәсәң, ни өчен яшерәсең?

– Яңа гына танышкан кеше турында сөйләмим. Аның яхшы кеше булганын, киләчәктә аралашачагыбызны аңлагач кына, әнигә әйтәм. Аңынчы артык мәгълүмат нигә?!. Аннан соң ул нигә аралашмыйсыз, ни булды, дип аптыратып бетерәчәк. Ә болай әнидән зур серләрем юк бугай. Элек бар иде.

Әниең телефоныңны актарамы? Мондый төр контрольгә ничек карыйсың?

– Ул бит минем шәхси әйберем! Әгәр караганын күрсәм, бик үпкәләр идем. Әни телефонны, шкафымны карамый, киемнәрне тикшерми. Болар барысы да минеке! Аларга тигән өчен ачуым чыкканын белә. Минем шәхси пространствога әни керми.

Ачуың килеп, ишекне шапылдатып ябып, бүлмәңә кереп киткән чакларың буламы? Кем беренче дуслашырга килә?

– Андый вакытлар була. Миңа бик авыр. Үпкә хисләре дә, бу конфликт озакка сузылыр инде дигән куркулы уйлар да... Эмоцияләр белән әллә ниләр әйтеп ташларга була, аннан соң гаебеңне танып, гафу үтенергә бик авыр. Әмма үземдә көч табып, гафу үтенә беләм. Гафу үтенгәндә бик куенсынам, чөнки гаепле икәнемне аңлыйм. Ә дуслашырга бүлмәгә иң беренче әни керә...

Әниең белән бергә кичергән иң рәхәт вакыт?

– Бервакыт бик озак үпкәләшеп, сөйләшми йөрдек. Соңыннан утырып сөйләштек, дуслаштык. Бу минем өчен иң бәхетле чор иде. Хәзер алай озак үпкәләшеп йөрмибез. Әни бик күп эшли, минем дәресләр, музыка мәктәбе, инглиз теле... Атна уртасында артык аралаша да алмыйбыз. Ялларда икебез берәр кая барып, сөйләшеп, йөреп кайтабыз икән, аннан да шәп мизгел юк.

Әниең синең өчен иң элек әниме, дус кызмы?

– Дус кыздыр. Аның белән теләсә нәрсә турында сөйләшеп була. Аңа үсмерләр арасында булган приколлар, сленглар кызык. Ул темада булсын өчен, барысын да сөйлим. Минем тормышым белән кызыксына, шул ук вакытта артык кысылмый да.

Миләүшә, син нинди үсмер идең, хәзер нинди әни?

– Үз сүзен әйтә белми торган, бар нәрсәдән курыккан, артык тыйнак үсмер идем. Әйе, шигырь сөйләүчеләр бәйгеләрендә катнаштым, әмма мәктәптә беркайчан да янып, башкалардан аерылып тормадым. Үземне менә шулай итеп хәтерлим. Мин кысаларда үстем. Ул вакытта әти артык кырыс иде, һәрвакыт һәрнәрсә тыелды. Шуңа күрәдер, балага ирек бирү теләгем зур иде. Мин ишеткән катгый «юк»ны балаларым ишетми. Билгеле, нindидер әхлакый кысалар бар, әлбәттә. Бала белән контрда булмас өчен, аңа сайлау ирегe бирергә кирәк дип укыган идем бер китапта. Бу фикерне күңелемә салып куйдым. «Ярамый» дип әйтмим, «Синең сайлау мөмкинлегең бар», дип әйтәм.

Диананы һәрвакыт аңлыйсыңмы?

– Юк, әлбәттә. Үзенең кыланышлары белән мине сүзсез калдырган чаклары булды. Без аны ике ел элек үттек. Лагерьга китте дә, аннан бөтенләй үзгәреп кайтты. Мин баламны танымадым. Үз эченә бикләнде, сөйләшми, бар нәрсәне кирегә бора. Ә ул шундый назлы бала иде. Моның үсмерлек чоры икәнен аңладым, әмма кабул итүе бик авыр. Аңа бит бары 12 яшь! Без Диана белән хәтта тыныч кына сөйләшә алмый идек. Әйткәләшеп, елашып беткән чаклар да күп булды.

Кызың берәр хәлгә очраса, беренче кемгә шалтыратыр дип уйлыйсың?

– Миңа шалтыратыр дип бик өметләнәм. «Кызым, ни генә булса да, ярдәм итәчәкмен», – дим һәрвакыт. Әмма барыбер шунда ук шалтыратмас әле, йөз кат уйлар...

Диананың бизәнүенә ничек карыйсың?

– Менә монда безнең фикерләр каршылыгы чыга инде. Диана каты итеп бизәнергә ярата. Күзенә стрелкаларны сызып куя инде... «Кызым, зинһар өчен, дискотекага барган кебек буянма», – дип гел әйтәм. Макияжның төрле тормыш очраклары өчен төрлечә булганын аңлатырга тырышам. Элек ишетергә дә теләми иде, хәзер инде килешә башлады кебек. Әмма беркайчан да көчләп кире сөрттергәнем юк! Болай эшләргә үземә рөхсәт тә итмим! Уйлап кара: безнең белән шулай эшләсәләрме?!. Күз алдыма китерсәм, йөрәгем жу итеп китә. Әйе, ул чынлап та иртә бизәнә башлады. Бу – аның карары.

Кызың телефонын озак вакыт алмаса...

– «Ник алмыйсың трубканы! Мин сине башка беркая җибәрмим!» – дип кычкыра башлыйм телефонын алуга. Бу минем беренче реакциям. Үземне тыя алмыйм. Алар иптәш кызлары белән үзләре генә йөри башлады. Хәзер йөрәк бөтенләй урынында түгел, үзең аңлыйсың. Әмма ул бик яхшы белә: хәзер кычкырып алам да, соңыннан бар да яхшы булачак. Җитмәсә, Дианага әтисеннән төпле, салкын акыл күчкән. Ул шунда ук: «Әни, тынычлан. Син хәзер үзеңнең дә, минем дә кәефне бозасың», – ди. Үз сүзен әйтә белә. Аның шундый булуы ошый миңа.

Миләүшә, синнән яшерен серләре бар дип уйлыйсыңмы?

– Әлбәттә, бар. Бу гадәти хәл, минемчә. Бар нәрсәне әнигә сөйләү дөрес түгел инде ул. Шәхси пространство дигән төшенчә бар бит әле. Ул һәр кешенеке булырга тиеш.

Телефонын тикшергәнең булдымы?

– Әйткәнемчә, кисәк кенә үзгәреп, йомылгач, Диана белән мөгамәлә урнаштырырга белми йөдәгәч, телефонын актарырга мәҗбүр булдым. Әлбәттә, минән яшергән серләрен белдем. Утырып сөйләштек. Кызлар өчен нинди чикләр барлыгы, егетләргә ышаныч турында да сүз булды. Сүз дә юк, һәр әни кебек, мин дә бик куркам. Ул минем бик чибәр, инде җиткән кыз, җитмәсә, анда хатын-кыз энергетикасы бик көчле. «Башка телефоныңны актармыйм, әмма син пароль куйма», – дип әйттем. Ул башка пароль куймады. Бу – ышаныч билгесе. Мин аңа шуның өчен бик рәхмәтле.

Кызың, ачуланып, бүлмә ишеген каты итеп ябып чыгып киткәндә син нишлисең...

– Бу ситуациянең кайсы якка борылуында минем шул чактагы халәтем роль уйнамый калмый. Берәр проблема аркасында ярсыган чагым булса, шунда ук ишек ачып: «Бу нәрсә булды?» – дип, низагны дәвам итәргә мөмкинмен. Ул, гадәттә, икәүләп утырып елау белән тәмамлана. Әгәр мин тыныч икәнмен, бу адымына күз йомам, әмма тынычлангач, сөйләшми калмыйбыз.

Ә кем беренче дуслаша?

– Сүзгә киләбез икән, ул бераздан шалтыратып: «Әни, мине гафу ит», – ди. Диананың мондый адымын бик хуплыйм. Гаеп миндә икән, тыныч кына гафу үтенә алам. Гафу үтенә белү тормышта бик кирәк ул.

Диананы дәвамчың итеп кабул итәсеңме?

– Юк, юк, юк, һич тә! Кайбер вакытта аның башындагы уйлар мине куркыта, әмма шатландыра. Аның фикер сөреше бик киң. Мин, мәсәлән, аның яшендә Арчада уку турында уйлый идем, хәтта Казанда да түгел, ә ул бөтенләй башка урында белем алу турында хыяллана. Бу сыйфат хәзерге үсмерләргә, яшьләргә хас. Шаккатам һәм сокланам. Диана минем дәвамчым түгел, аның үз юлы! Һәм мин ул сайлаган юлны хөрмәт белән кабул итәчәкмен.

Чулпан ГАЛИӘХМӘТОВА

Фото: Анна Арахамия





Татарстан Язучылар берлеге рәисе, Татарстан Республикасы халык депутаты, Татарстанның халык шагыйре, Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Ркаил ЗӘЙДУЛЛА

МИН ҮЗЕМ ДӘ РКАИЛ!

МИН ВЛАСТЬ ӨЧЕН ҖАЙЛЫ КЕШЕ ТҮГЕЛ! Салкын акыл юк миндә. Чәчрәп чыгам, әйтеп ташлыйм. Кайчагында үкенеп тә куям аннары.

Дөресен генә әйткәндә, бу юлдан кереп китәрмен дип планлаштырмаган да идем. Мин менә драматургия белән җитди генә шөгыльләнеп алган арада – анда бит инде керем бүтән төрлерәк: пьесаң куелса, халык йөрсә... Шуңа менә Кама Тамагында, Туфан абыйның туган ягында Карамалы елгасы буена йорт салдым. Кышын чаңгыда шуып, җәен су коенып, шунда әсәрләр язып кына ятармын дип уйлаган идем. Ләкин **КЕШЕ БЕРТӨРЛЕ НИЯТЛИ, ЯЗМЫШТА БӨТЕНЛӘЙ БАШКАЧА ЯЗЫЛГАН БУЛЫП ЧЫГА.**

Инде ике ел ярым вакыт үтеп тә киткән, ә мин депутатларның 80 процентын әле дә белмим. Чөнки күбесе сессия утырышларында гына утыра, ә тавышларын ишеткән юк, чыгып сөйләмәгәч... Чыгып сөйләүчеләрне, актив депутатларны беләсең бит инде. Үзем шундый! Минем сөйләми калган сессия утырышлары бик сирәк. Комитет утырышларында кайбер мин сөйләгән, мин тәкъдим иткән нәрсәләрнең тормышка ашуы барыбер күңелгә ниндидер канәгатьлек бирә. Мәсәлән, Шаян ТВ өчен балалар җырлары конкурсы минем инициатива белән туды. Мин жюри әгъзасы да анда. Шулай дигәч, бер кызык искә төшә... Без университет тәмамлаган 1984 елда Равил Фәйзуллин язучы халкын туган көненә чакырды. Ниндидер пароход яллап, Маркиз утравына киттек. Гариф Ахуновның ун ел эшләгәннән соң рәислектән киткән генә чаклары. Юатучыларга: «Әле минем тагын 13 вазыйфа бар», – дигән була ул, шаяртуга борып. **АНЫҢ БИТ ВАЗЫЙФАЛАРЫ ДА РӘИС БУЛГАНДА ГЫНА БУЛА. РӘИСЛЕКТӘН КИТТЕҢМЕ, ТЕГЕЛӘРЕ ДӘ КИТӘ, ҮЗЕҢ ДӘ КИТЕП БАРАСЫҢ ӘКРЕН ГЕНӘ.** Шуның кебек, боларның барысы да шул рәис булудан, депутат булудан килә торган вазыйфалардыр инде минем. Теге урыннан киткәнсең икән син, монысында да була алмыйсың.

Дөресен генә әйткәндә, Язучылар берлеге рәисе булу бик мәшәкатьле эш инде! Үземнән элгәргеләр, язып булмый дисәләр, елмаеп кына куя идем... Бөтенләй язмыйм дип әйтә алмыйм анысы. Шигырьләрне үзем өчен булса да язгалыйм. Ә болай зуррак проза әсәре язармын дип уйлаган идем. Тәҗрибә дә бар, чыганаклар да, материал да... Ул әсәр зур роман булып җитешәчәк. Бәлки, ул хыялыма ирешермен. Бәлки, бу урыннан җибәрерләр. **ҮЛГӘНЧЕ ДЕПУТАТ БУЛЫРГА ДИМӘГӘН БИТ ИНДЕ.**

Авылыгыз Татарстаннан читтә, Чуашстанда ук дип әйтсәләр дә, Азнакай, Актанышлардан ике тапкыр якынрак ул Казанга! Шуңа күрә Казанның йогынтысы көчле. Элек тә шулай булган, хәзер дә шулай. Әлбәттә, бүтән республикада булгач, рус телендә укыттылар безне, гәрчә бер урыс булмаса да. Безнең авыл – Чичкан. Елга аша гына чуаш авылы, без чуаш ягындагы мәктәптә укыдык. Гомергә чуашлар белән аралашып, тату яшәдек. Анда чуашлар – татарча, татарлар ипилектозлык чуашча белә. Мин үземне бәхетле саныйм: азмы-күпме чуаш әдәбиятын беләм. Бүтән милләтләр янәшә булса, ул барыбер баета инде. **ӘГӘР ДӘ БЕРӘРСЕ АССИМИЛЯЦИЯЛӘРГӘ ТЫРЫШМАСА. ӘГӘР ДӘ ИКЕ МИЛЛӘТ ЯНӘШӘ ЯШӘГӘНДӘ КАЙСЫСЫДЫР СИНЕ ЙОТАРГА ТЕЛИ ИКӘН, БУ, ӘЛБӘТТӘ, ДИСКОМФОРТ КИТЕРЕП ЧЫГАРА.** Бездә андый нәрсә булмады.

МИН ҮЗЛЕГЕМНӘН УКЫП ТАТАР ТЕЛЕНДӘ КАМИЛЛЕККӘ ИРЕШТЕМ, ТАТАР ТЕЛЕНДӘ ШИГЫРЬЛӘР ЯЗА БАШЛАДЫМ. Бала вакытта ук «Ялкын»га, «Яшь ленинчы»га мәкаләләр, шигырьләр җибәрә идем. «Яшь хәбәрче» таныклыгы килгәне бар. «Чаткы» конкурсларында һәрвакыт җиңдем. Ә инде редакциядән зу-у-ур конвертта: «Шигырьләрең безнең журнал таләпләренә туры килми», – дигән хат та килсә... Басылуы да кирәк түгел. Синнән дә бәхетле кеше юк! Андый конвертта беркемгә хат килми!

МАЛАЙЛАР АРАСЫНДА МИН ЛИДЕР ИДЕМ. Төрле әйберләр оештырырга, Тимур командалары белән әбиләргә булышып йөрергә... Җитмәсә, отряд советы председателе дә әле. Һәм үзем хулиганрак та идем инде. Әти мәрхүм, мин Казанга киткәч: «Җилкәдән авыр йөк төшкән кебек булды», – дип әйткән иде. Ләкин мин Казанга китеп тә тынычлыкта калдырмадым инде, аннан соң да. Әти минем – укытучы, мәктәп директоры, Канаш медучилищесын тәмамлаган әни – фельдшер-

Фото: Анна Арахамия

акушерка иде. Минем хатынның да кендек әбисе булган ул.

Әти – Чичканнан, әни – Шыгырданнан. Башкалардан күреп, шәҗәрәне тикшерә торгач, әнинең бабасы тамырлары белән Буа районы Алчык, Тәтеш районының Үтәмеш авылларына барып тоташканын белдем. Миңа ошап бетмәде инде бу, нишлисең. «**ЧИСТОКРОВНЫЙ МИШӘР» БУЛЫП ЧЫКМАДЫМ.** Минем нәселгә язучылар да катнашкан. Тукай чордашы Зариф Бәшири, мәсәлән, минем әбинең абыйсы. Фәтхи Бурнаш та безгә чыбык очы икәнен ачыкладым. Алар бит бербересе белән кыз алып, кыз бирешеп туганлашкан. Кави Нәҗми дә кардәш тиешле дип ишеттем. Төбенә төшеп тикшермәдем. Миңа нәрсә... Кави Нәҗми булды ни, башкасы ни... Мин үзем дә Ркаил!

БАЛАЧАКТА УК ЯЗУЧЫ БУЛЫРГА ХЫЯЛЛАНДЫМ! 5 яшьтән үк китаплар укый идем инде. Миңа китапларны гел кайтартып торалар иде. Үзем – мишәр татарлары авылыннан. Шигырьләрне рифма-ритмның, әдәби телнең нәрсә икәнен дә белмичә:

Кояш цык-цык,
Көндез дә цык, төн дә цык.
Синең өцен һәрцакта
Минем тәрәзә ацык, – дип язам. 10 нчы класста укыганда Казанда Язучылар съездында делегат булып катнаштым. Әти минем финанс-икътисад институтына укырга керүемне тели иде. Ә миңа саннар, цифралар дөньясы бик тә күңелсез тоелды. Съездда Газинур Морат белән таныштым. Поездлар уза торган чокырларны үтеп, ул яшәгән тулай торакка да бардым. Ошады! Университетның татар бүлегенә укырга керәм дигән ныклы фикергә килеп кайтып киттем.

Шигырьләремне күрсәтеп, мин чынлап та шагыйрь була аламмы икәнен белер өчен Хәсән Туфан, Сибгат Хәкимнең өйләренә үк бардым. **ХӘСӘН АБЫЙНЫҢ ЯШЕЛ КАРА БЕЛӘН ЯЗГАН БӘЯЛӘМӘСЕН ӘЛЕ ДӘ САКЛЫЙМ.**

ДӨНЬЯНЫ ҮЗГӘРТӘСЕ КИЛҮ ТЕЛӘГЕ КӨЧЛЕ. Бигрәк тә яшь чакта. Шагыйрь өчен бу шулкадәр табигый!

ӘДӘБИЯТНЫ ДА, ШИГЪРИЯТНЕ ДӘ АЛГА ЭТӘРҮЧЕЛӘР ЭЛЕК-ЭЛЕКТӘН ИР-АТ БУЛГАН. Яшь язучылар арасында егетләрнең аз булуы күңелдә борчу уята.

ИҖАТ ИЛҺАМЛЫ БУЛЫРГА ТИЕШ. Ләкин ул еш килә торган кунак түгел. Туфан Миңнуллинның киңәше истә: «Әдәби әсәр язылмаган очракта дәфтәргә берәр нәрсә теркәп куй: истәлекме ул, ишеткән кызыклы вакыйгамы, китаптан укылган гыйбрәтме...» Ул үзе кызыл дәфтәргә яза башлаган. Минем исә кул астындагы дәфтәр башта ук нигәдер тышсыз иде.

Төркиядә төрекләргә кияүгә чыккан татар кызлары – филологлар бар. Алар да тәрҗемә итә. Иң кызыгы – төрекләр татарчадан төрекчәгә үзләре тәрҗемә итәләр. Университетта безнең Чулпан Читиннар укыткач, шәкертләре рәхәтләнеп татарчадан төрекчәгә тәрҗемә итәләр. **БҮТӘН ХАЛЫКЛАРГА ДА КҮРСӘТӘ ТОРГАН ШӘП ӘДӘБИ ӘСӘРЛӘРНЕ ДӨНЬЯГА ЧЫГАРЫРГА КИРӘК.**

Күпмедер еллар үткәннән соң, әдәбиятта уңыш дигән әйбер уңышсызлыкка да әверелергә мөмкин. Мин шундый әсәр яздым, халык яратты дип йөрисең. Бер 20 ел үтә, халык оныта, ул инде искергән, беркемгә кирәк түгел, бу заманга ярамый. Һәм, киресенчә, уңышсыз дигән әсәр уңышлы булып китәргә дә мөмкин. **СИКЕРЕП, УҢЫШ ДИП ШАТЛАНЫРГА, УҢЫШСЫЗ ДИП, АРТЫК КӨЕНЕРГӘ КИРӘКМИ.**

Шагыйрьнең, өлкәнәя-өлкәнәя, бөтен иҗаты сагынудан гыйбарәт аның. Төш күрсәң – әлбәттә, балачыгыңны күрәсең. Бөтен хатирәләрнең 90–95 проценты – балачак хатирәләре. Алар онытылмый да. Язганда да һаман шул балачак хатирәләренә мөрәҗәгать итәсең. Кеше кич ашаган ризыгын онытырга мөмкин, ә балачагында ашаган җиләк тәме – һаман иреннәрдә. Сагыну, юксыну шагыйрьләр өчен генә түгел, һәр кеше өчен табигый. Аннары инде сагынасың яшьлегеңне һәм... уңышсыз мәхәббәтләреңне. Барысы да искә төшә... Кинодагы кебек. «И аны нишләп шул вакытта шулай итмәдем инде, бөтенләй бүтәнчә булыр иде бит», – дип уфтанасың. Сораштырган бар, күпләргә хас әйбер икән ул. **ЯШЬЛЕКНЕҢ УҢЫШСЫЗЛЫКЛАРЫН САГЫНУ ДА КҮҢЕЛГӘ РӘХӘТЛЕК БИРӘ.**

ЕШ МӨРӘҖӘГАТЬ ИТӘ ТОРГАН КИТАБЫМ, ӘЛБӘТТӘ, ТУКАЙ ТОМНАРЫ. Аннары гел менә минем каршыдагы киштәдә Адлер Тимергалинның «Миллият сүзлеге» тора. Анда бик күп мәгълүмат тупланган. Роман кебек укып чыга торган китап түгел ул. Бөтенләй көтелмәгән ачышларга юлыгасың. Язучы кешегә миллият сүзлеге шулай ук бик кирәк. Ә теге, күңелгә якыннары... Үзем яраткан, үзем аралашкан шагыйрьләрнең китаплары. Зөлфәт, Мөдәррис Әгъләмов, Роберт Әхмәтҗанов, Рәшит Әхмәтҗановлар... Мөхәммәт абый Мәһдиевне яңадан алып укырга яратам.

ӘДӘБИЯТ УЛ – МИЛЛӘТ ХӘТЕРЕ. Халыкның гасырлар дәвамындагы холык-фигылен, яшәү рәвешен, гореф-гадәтләрен, өмет-хыялларын, әрнү-сагышларын үзенә сеңдергән.

Студент чакта мин кәгазьне чемодан өстенә куеп яза идем. Шартлар юк дип зарланырга башка да килмәгән. Яшь чакта бөтен шартлар да үзең белән. **ЯХШЫ ЯЗАСЫҢМЫ, НАЧАРМЫ – БАШ ӨСТЕНДӘ ТҮБӘҢ БУЛУ ЗАРУР.**

ЯЗЫЛЫП БЕТМӘГӘН ӘСӘР ТУРЫНДА СӨЙЛӘРГӘ ЯРАТМЫЙМ. Алдан сөйләсәм, әсәрнең мамыгын коярмын сыман.

Яшь чагында дуслар да күп була. **КҮП ОЧРАКТА СИН ДУС ДИГӘННӘРЕҢ ДӘ БИК ТИЗ ЮККА ЧЫГА.** Берән-сәрән генә кала алар. Дуслык ул нарат агачы кебек: шулкадәр таралып, бөдрәләнеп үсә яшь чагында. Читтән караганда шундый купшы! Ә берзаман үсә-үсә ботаклары коела, өстендә генә бер өч-дүрте күренә. Өлкәнәя-өлкәнәя, кеше ялгызлыкка таба бара башлый. Нишлисең бит, кеше ялгыз туа, ялгыз үлә инде шулай. Олыгая-олыгая, ялгызлыкка күнегер өчен, табигать, Аллаһы Тәгалә шулай яраткан күрәсең. Картлык ул – ялгызлык дигән сүз.

ЭЧТӘН ХӨР БУЛГАН КЕШЕ ТЫШТАН БАЙ КҮРЕНӘ. Зөлфәт Хәкимне әнә искиткеч бай дип уйлыйлар. Чөнки күңеле хөр, рухы азат. Миллионнарча акчасы булган рухи хәерчеләр күпме?!

БАЙ ТАТАРЛАР КИТАП УКЫМЫЙ, КИТАП АЛАРГА БУШЛАЙ ДА КИРӘК ТҮГЕЛ.

КОЛЛАР БЕЗ – ҮЗАРА ХАН БУЛЫП КЫЛАНАБЫЗ, ҮЗЕБЕЗ ЯТЛАРДАН ТЕЛЕБЕЗНЕ ТЕЛӘНӘБЕЗ.

Байлыкка омтылу ул, гомумән, шагыйрь өчен гайре табигый эш дип уйлыйм. **ШАГЫЙРЬ АЗ ГЫНА АЧ БУЛЫРГА ТИЕШ.** Чөнки ачның ачуы яман. Ачлыкны мин канәгатьсезлек хисеннән күрәм. Ачлыктан, бөлгенлектән аптырап йөрүне әйтмим.

Сиңа кыен булса, иң беренче туганнар ярдәмгә килә гел. Сиздермәскә тырышсаң да, ничектер сизәләр барыбер. **НАЧАР ХӘБӘР БИК ТИЗ ЙӨГЕРӘ ТОРГАН БУЛА.** Яхшысы гына озак килә. Килсә дә әле аңа әллә ни игътибар итмиләр, табигый хәл итеп карыйлар. Кеше турында да бит бер начар сүз әйтсәң, сәгате-минуты белән барып ирешә, ә яхшы сүзне җиткерүче дә булмый, җиткерсәң дә, артык исләре китми. Менә шундый хасияте бар инде яшәешнең...

Эти минем кырыс иде. Директор булгач, мәктәптәге шуклыкларымны укытучылар гел аңа барып әләклиләр иде. Берчак, 7 нче сыйныфларда укыганда, инглиз теле дәресендә, яшь укытучы кызны санламыйча, и сөйлим малайларга нәрсәдер. Берәр кызыклы хәл булгандыр инде. Мин әле бераз күпертеп, бизәп сөйләргә дә яратам. Мавыгып киткәнмен инде, ишектән эти килеп кергәнне дә сизмичә калганмын. Шунда яңак төбенә кемдер ямады. Миңа сугардай кем бар инде дип аптырадым да әле. Идәнгә ауганда этине күреп алдым. Гомергә онытылмаслык сабак булды ул. Менә шуннан соң дәрестә укучы-ларның игътибарын җәлеп итеп, парта өсләренә басып, чыгышлар ясамый башладым. Һәм ул миндә әлегәчә дәвам итә. **СИНЕҢ ВАКЫТЫҢ ҖИТМӘГӘН ИКӘН, СИНЕҢ МӘЙДАНЫҢ ТҮГЕЛ ИКӘН – СӨЙЛӘМӘ, ТИК ТОР! ТЫҢЛА!**

Күз уңындагы кешенең кимчелеге барыбер табыла. **ТИК ТОРГАН, ХӘРӘКӘТЛӘНМӘГӘН КЕШЕ ГЕНӘ ЯЛГЫШМЫЙ.**

ЕГЕТ СҮЗЕ БЕР БУЛА! Буш вәгъдәләр бирергә яратмыйм. Холкыма туры килми. Әйткәнсең икән – үтә.

Мин ихлас! **ҮЗЕМНЕ ХАКЛЫ ДИП САНАГАНДА, БЕРКЕМ СҮЗЕНӘ ДӘ КАРАМЫЙМ.** Һәм... еш кына хаксыз булып чыгам.

Миндә ниндидер комплекслар юк. Беркайчан югалып калмыйм. Без яшь чакта шабашка дигән әйбер бар иде. Читкә китеп эшләү ягъни. Студент чакта мин дә киттем шабашкага. Университетта укыганда мин нәрсә беләм инде?! Балта остасы баласы түгелмен. Кәгазь-китап арасында үскән кеше мин. Балта да пычкы инде ул вакытта. Нишләп мин башкалар кебек кенә эшли алмыйммыни дип кереп китәсең инде. Өйрәнәсең шунда. Аннары инде син бер атнадан алар белән тигез. Бөтен җирдә дә шулай ул. **ЮГАЛЫП КАЛСАҢ, МӘЛҖЕРӘП ТОРСАҢ, БЕРНИ БАРЫП ЧЫКМЫЙ.** Мин андый җебегәннәрне яратмыйм. Эшлисең икән, җимертеп эшлә. Минем картәнә әйтә иде: эшләгәндә йөрәгең җилкенсен, ашаганда колагың селкенсен, дип.

Хәзер әдәбият ишеген шакучылар арасында кызлар гына диярлек. Ир-егетләрнең тавышы бу хорда югалып та кала. Чөнки алар бүген берән-сәрән генә. Һәм без бу хәлне табигый дип кабул итәбез. Минемчә, татар вазгыятенә туры да килеп тора. **СОҢГЫ ЧИКТӘ ХАТЫН-КЫЗЛАР ҺӘРВАКЫТ ДИЛБЕГӘНЕ ҮЗ КУЛЫНА АЛА.**

Бөек хатын-кыз Мөхлисә Бубыйның гыйбрәтле сүзләре искә төшә: «Балаларыбызга яхшы тәрбия биреп, милләтебезне оҗмахлы кылучы да без; аларны тәрбиясез куеп, милләтебезне җәһәннәмгә тәмугка кертүче дә без – хатыннар». Һәр татар хатын-кызы өчен шигар булырлык сүзләр! Тәрбия дигәндә, Мөхлисә ханым, әлбәттә, иң беренче нәүбәттә милли һәм дини тәрбияне күздә тоткан. Бүген безгә нәкъ менә шул тәрбия җитми дә инде. Милләтебезгә килгән бөтен бәла-казаларның сәбәбе шунда. **МИЛЛӘТ ЯЗМЫШЫ – ХАТЫННАР КУЛЫНДА.**

ҖИҢЕЛӘСЕҢ ИКӘН, ЕГЕТ БУЛЫП КАЛЫРГА КИРӘК! Минем белән дә андый хәлләр булды, күп җиңелдем. Әмма бүтәннәргә рәнҗеп, каргап йөрмәдем. Димәк, тәкъдирең шулай язылган.


Эльмира ЗАКИРОВА
әзерләде.

– Нәнә, сиңа укытучы шалтыратмадымы? – дип сорый улым бер көнне. Андый сорау һәрбер әнине сагайтадыр. Мәктәптән сыйныф җитәкчесе юктан гына шалтыратмый. Димәк, нидер булган дип, ун секунд эчендә әллә ниләр уйлап бетердем. Сугышкан? Тәрәзә ваткан? Улым нәрсә эшләде икән? Моңарчы бернигә дә зарланганнары юк иде. «Бишле»гә генә укый, өстәвенә, сыйныфларында староста... Ходаем, 5 нче сыйныфка күчү белән проблемалар башланыр микәнни? Иң беренче чиратта начарын уйлыйсың бит...

СОҢГА



Алсу
ШАКИРОВА



Бәйләнә...

Соңгы арада эш белән мавыгуымны, балаларымның вакытларын еш кына үзләре генә уздыруларын уйлап, үземне битәрләп тә алдым. Туктале, җиргә төшәргә кирәк... Укытучы шалтыратмады бит.

– Юк, улым. Нәрсә дип шалтыратырга тиеш иде? – дип, берни булмаган кебек тыныч тавыш белән кызыксынырга тырышам.

– Юк, берни түгел, болай гына...

Болай гына түгел икәнен аңладым инде, улым, дим эчтән генә. Әйтергә теләмәде... Бераздан бүлмәсенә кереп, янәдән тел төбен тикшереп карарга булдым. Нәтиҗәсез. Нишләптер күңелем тыныч түгел, улымнан сәбәбен беләсем килә. Куркытасы да килми. Үз теләге белән ачылсын иде, дим.

Икенче көнне бала бөтенләй боеккан. «Нәрсә булды, улым?» – дип соравыма күзләре мөлдерәмә тулып чыкты:

– Әнә, параллель сыйныфтагы бер малай... Бәйләнә... Полициягә әйтәм, укытучыларга сөйлим, ди...

Полиция сүзе мине айнытып җибәрде. Болай калдырырга ярамый, димәк!

Егет кешегә җитмеш төрле һөнәр дә аз дип, улыбызны ике спорт төренә бирдек. Мәктәптә укып кайтканнан соң көрәшкә бара, аннан кайтып сәгать ярым эчендә өй эшләрен әзерләп, яңадан тренировкага – футболга китә. Көн саен кичке тугызынчы яртыда гына өйгә кайта, улымны бөтенләй күрмим: ял көннәрендә йә уен, йә тагын берәр тренировка, йә ярыш... Баланы «кулдан ычкындырмас» өчен, бер спорт төрен генә сайларга булдык. Тәрбияләргә, сөйләшеп утырырга вакыт күбрәк калыр кебек иде.

Футболдан китүен киттек, ләкин улымның графигында үзебез өчен дип «бушаткан» вакытка башкалар дәгъва кыла башлады. Дәресләрен әзерләгәннән соң урамга дуслары янына чыгарга да вакыты кала моның. Үзебезнең йортта яшәүче малайлар белән генә түгел, кайвакыт сыйныфташ дуслары белән өй тирәсендәге мәйданчыкларда уйнап кайта.

– Хәтерлисеңме, Данис белән уйнарга чыктым бер көнне. Су алырга дип акча да алып киттем әле. Кибеткә кергәч, су гына түгел, бер шоколад та алдым. Кассага акчаны түләп чыгып барганда безнең мәктәптә параллель сыйныфта укучы бер малай яныма килеп басты. «Нигә шоколад урладың?» дип сорады, – дип сөйләп китте улым.

Мондый хәлгә бер дә очрамаган бала сүзсез калган. Мин аны сатып алдым, күрәсең бит кассадан килгәнне, дип әйтеп караган. «Мин үзем күрдем, син суга гына акча түләдең, шоколадны урладың», – дип, үз сүзендә тора ди теге малай да. Әле җитмәсә, махсус кычкырып сөйләшә, узып баручы кешеләр миңа карап китәләр, ди. Ни кызганыч, акланыр өчен кулында чегы да юк икән. Читенсенүдән, кассага барып чегын сорарга да кыймаган. Дусты Данис улымны акларга, якларга тырышкан: «Мин үзем күрдем, ник бәйләнәсең, сатып алды ул аны», – дип әйтсә дә, теге малай үз сүзендә тора. «Минем әти МВДда зур җитәкче, сиңа «балигъ булмаганнар» статьясын «тегәчәкләр», мәктәптә директорга чакырачаклар, сине классташларың карак дип йөртәчәк», – дип, психологик алымнар белән улыбызны куркытып бетергән. «Бу вакыйгалар шулкадәр тиз булды, мин берни уйларга да өлгермәдем, җавап та таба алмадым, үземнең хаклы икәнемне белсәм дә...» – дип тәмамлады ул сөйләвен.

Әйе, гомерендә беренче тапкыр мондый хәлгә калган бала өчен бу чын мәгънәсендә стресс була. Улым шул малайдан шикләнеп йөри. Чынмы, юкмы, укытучыларга сөйләп ышандырыр, классташлары, дуслары алдында

КАЛМАСКА ИДЕ...



Фото: Анна Арахамия

оятка калдырыр дип курка башлаган. Берничә көн проблемасын эчендә йөрткәч, ниһаять, миңа сөйләргә хәл иткән.

Мыскыллау

Мондый хәлгә калучылар бер без генә түгел. Яшьтәшләр, параллель сыйныфларда укучы балалар, төрле яшьтәге укучылар арасында еш очрый мондый куркытулар. Алар бер-берсенең холкын белеп, кемне «кысарга» кирәклеген, кемне нинди очракта «эләктерергә» мөмкинлеген чамалап, сизеп торалар, бер-берсен өйрәнәләр. Әнә шундый үткен бер төркем балалар, икенче бер укучыны түбәнсетеп, аның турында дусларына, укытучыларына сөйлибез дип куркытып яшиләр. Бала укытучыдан, әтиәнисе реакциясеннән, бигрәк тә полициядә эш ачудан курка, үз-үзен яклый алмый. Шул сәбәпле, мыскыл итүгә бирешергә мәҗбүр була. Озак вакыт дәвам итсә генә әти-әниләр бу хакта сизенә башларга мөмкин: бала акчаны ешрак сорый (аны мәҗбүр итәләр, кысалар), сезнең укытучы белән элемтәгә керүегездән курка, үз-үзен тотышы үзгәрә, кискен тавышлардан куркып кала, хәтта машина сигналын ишетеп тә сискәнергә мөмкин.

Укучы балалар арасындагы мондый мөнәсәбәтләрнең термины бар – буллинг дип атала ул. Инглиз теленнән тәрҗемә итсәк, куркыту, мыскыллау дигәнне аңлата. Күп очракта ул көч кулланып та түгел, нәкъ менә психикага йогынты ясап, көлеп, мыскыллап эшләнә.

– Төрле холыклы балалар бар. Бу очракларда берсе – корбан, икенчесе аучы ролендә дип тә күз алдына китерергә мөмкин. Йомшаграк баланы шул рәвешле куркыту «травля» дип атала. Ул туры контакт аша да, интернет аша да булырга мөмкин, – ди Казан шәһәренең 62 нче мәктәбендә биш ел укыту һәм тәрбия эшләре буенча директор урынбасары вазыйфасын башкарган Разих Рәдиф улы Камалов. – Гадәттә, мондый мөнәсәбәтләр 7-8 нче сыйныф укучылары арасында ук сизелә инде. Ләкин соңгы елларда бу яшь үзгәрә – 5-6 нчы сыйныф укучылары арасында ук сизелә башлады. Табигать кануннары буенча, кызлар психологик һәм физик яктан иртәрәк өлгерә. Шуңа күрә аларны бу чорда аеруча игътибарда тотарга кирәк.

Улы Инсаф – 6 нчы сыйныфта укучы тагын бер танышым – үз тарихы белән бүлешә. Бергә укучы сыйныфташлары ватсапта махсус төркем булдырып, Инсафның фотоларын төрле фотошоп чаралары ярдәмендә

PRESSA

Безнең белән ачыктан-ачык сөйләшмәгән булса, белмим, нәрсәгә барып җитәр иде.

ямьсезләп, мыскыл итә торган начар сүзләр язып, тән әгъзалары ясап, бу малайдан көләләр. Ул төркемдә барлык классташлары утыра. Инсафны шул дәрәҗәгә җиткергәннәр ки, ул мәктәпкә барудан баш тарта, елый, бик тирән стресс кичерә. Бу хәл турында бала әти-әнисенә әйтергә кыймый, туктарлар әле дип өметләнә. Ләкин сыйныфташлары туктамый. Инсафка карата бер-бер артлы мыскыл итүләр китә, аннан бөтен дуслары көлә. Интернет яисә аралашу мессенджерлары аша мыскыл итү – шулай ук буллингның бер төре. Бала мәктәпкә йөрми башлагач кына әнисе нәрсәдер булганын аңлап ала. Инсафны бу хәлгә калдыручы сыйныфташлары – өч кыз. Танышым төркемнең исемен, администраторларын, алар ясаган сурәтләрне саклап, сыйныф җитәкчесенә күрсәтә. Ә ул... шакката! Дәрестә тыныч кына утыручы иң тәртипле кызларны яңа яктан ача укытучы.

Шунысын да исәптә тотарга кирәк, бу мыскыллауны күреп торган калган балаларга да аның йогынтысы бар. Хәтта алар да стресс кичерергә мөмкин. Чөнки балада иртәгә бу төркемдә аннан көлмәсләр, аны какмаслар дигән ышаныч юк, күбесе корбан роленнән курка, оештыручыларга баш иярга мәҗбүр була. Укытучыга әйтеп, әләкче булудан да куркалар.

Бер утырып сөйләшү...

Белгечләр фикеренчә, минем бала моны эшли алмый дип уйлап, әти-әниләр нык ялгыша. Сезнең тәртипле улыгыз йә «бишкә» генә укучы кызыгыз кайсыдыр балага карата шундый «травля» алып бармый дип ышанып бетәргә ярамый. Хәтта бала бик яхшы хәлле гаиләдә тәрбияләнсә дә, әти-әнисе кайда, кем булып эшләсә дә... Чөнки баланың үзен ничек тотуы гаилә хәленә бәйле түгел, әти-әнинең үз баласын никадәр яхшы белүеннән, аңа игътибарлы булуыннан тора. Еш кына буллингны оештыручы бала үзе дә психик яктан ярдәмгә мохтаҗ була. Чөнки ул да гаиләдә яисә башка бер төркем тарафыннан үзенә карата агрессия кичергән булырга мөмкин. Аннары бөтен ачуын үзеннән көчсезрәк башка балага юнәлтә, аны мыскыллый башлый.

– Шунысы кызык, баланың нинди юлда йөргәнен әти-әни күп очракта сизми. Мәктәптән шалтыратып, проблема барын әйткәч кенә алар сагаеп кала. Анда да ышанмаска мөмкиннәр әле... Шуннан соң гына гаиләдә балага карата игътибар арта, аның өчен борчыла башлыйлар, тәртибенә ныклап тотыналар. Ләкин әти-әниләр кайвакыт соңга кала... – ди укытучы.

Гадәти эш көнен күз алдына китерегез әле. Иртән сез – эшкә, бала мәктәпкә китә, кич белән соң гына очрашасыз. Ул төрле түгәрәкләрдән сездән дә соңрак кайтырга мөмкин. Өй эшләрен эшли дә, телефонда утырып, йокларга ята. Бәлки, сез балагызны гел телефон тотып утырган килеш кенә күрәсездер... Ягъни көн дәвамында сез баланың эмоцияләрен, хисләрен күрмисез. Кулында телефон булганда ул гел бертөрле. Ә шатланганда нинди ул? Әчке бер борчуы булса үзен ничек тота? Күзләре ни турыда сөйли? Бу сорауларга ачык җавап бирә алсагыз, сезгә, бәлки, борчылырга урын юктыр. «Еламаган балага имезлек каптырмыйлар», дибез. Тормышыгызда бар да бертөрле генә: тыныч, салмак, проблемаларсыз гына барса, әлбәттә, баланың да бар да әйбәт дип уйлап, ялгышабыз. Балага игътибар кирәк. Сездән игътибар җитмәсә, ул аны урамнан, төрле төркемнәрдән эзли. Ә ул кеше кем булыр – билгесез...

– Яшүсмерләр белән килеп чыккан бик күп проблемаларны 5-6 нчы сыйныфта укыган чакта бер утырып сөйләшү хәл итәр иде. Әнә шул вакытта баланы кулдан ычкындырсагыз, ике-өч елдан соң тыңлата алмаячаксыз. Чөнки егетләрдә ул яшьтә «мин» дигән әйбер барлыкка килә. «Өйрәтмәгез, мин үзем беләм», – дип, бүлмә ишеген шапылдатып ябып кереп китәчәк ул. Ни өченме? Чөнки аның белән моңа кадәр сөйләшмәгәннәр, аны ишетмәгәннәр. Хәзер аңа моның кирәге юк, – дип дәвам итә Разих Камалов.

Улыбыз бу хәлләрне сөйләгәннән соң кич утырып сөйләштек. Шундый очракта нишләргә кирәклеген яхшылап аңлаттык. Безнең киңәшләрне истә тотып, улыбыз икенче көнне үк теге малайның шантажына чик куйды. «Мин барысын да әти-әниемә сөйләдем. Алар синең укытучың белән сөйләштеләр. Тиздән директорга мине түгел, синең әти-әниеңне чакырачаклар», – дип әйтте. «Карарбыз әле», – дип янап киткән теге малай шуннан соң башка бәйләнмәгән...

Чикнең теге ягы

Конфликтка нокта куелды дип санарга иртәрәк әле барыбер. Бу очракта минем урындагы әти-әни битараф калырга тиешме? Безнең улыбыз яшендәге теге малайның

ИГЪТИБАР ИТЕГЕЗ

- Бала кем белән аралаша? Аның дуслары кем? Сезнең 5 нче сыйныфта укучы балагыз 8 нче, 11 нче сыйныф егетләре белән аралаша икән, бу – борчылыр өчен беренче сәбәп. Ул анда дуслар тапкан, аларга ышана, аларны авторитет дип күрә, аларга охшарга тырыша. Зуррак малайлардан өйрәнеп, ул үзе буллинг кылырга мөмкин.
- Балагызның телефонын алып, үзе күреп торганда тикшереп карагыз. Әгәр дә ул очып килеп кулыгыздан тартып алса, сезгә чатларны күрсәтергә теләмәсә, телефонында сез белмәгән пароль торса, димәк, анда ниндидер тыелган аралашулар бара, ул моны яшерергә тели, сезнең реакциядән курка.
- Баланың үз-үзен тотышы үзгәрә: ул мәктәпкә бармаска сәбәп эзли, нидәндер курка, еш авырый башларга да мөмкин. Җыелышка баруыгызны теләми, укытучы шалтыратыр дип шикләнә, сезнең телефоннан сыйныф җитәкчесе белән язышканнарыгызны укый.

начар юлдан барганын белә торып, эндәшми калсам, әти-әнисенә әйтүне таләп итмәсәм, ул баланың гомере ничек тәмамланыр? Ике-өч елдан моның өчен үкенергә туры килмәсме? Икенче яктан, аның әти-әнисе минем сүзләргә ышанырмы? Ничек исбат итәргә? Ул, беренче чиратта, үз баласына ышаначак бит. «Минем улым алай эшли алмый», – дигән җавап ишетәсем шиксез. Гариза язып, баланың тормышын бозарга да кул бармый. Монда әти-әниләрнең «солидарность» дигән әйбере дә роль уйный. Барыбыз да бала тәрбиялибез бит. Булмас, димә... Әйе, әти-әни нәрсәнедер игътибарсыз калдырган, вакыты җитмәгән, вакытында сизмәгән. Иртәгә синең балаң мондый юлга басмас дип ышанып бетеп тә булмый.

– Әти-әни мәктәп белән һәрвакыт тандемда эшләргә тиеш. Мәктәпләрдә бу юнәлештә программалар эшли, тәрбия чаралары уздырыла, төрле рәсми оешмалар белән берлектә аңлату эшләре алып барыла. Бала сыйныф җитәкчесе карамагына эләгүгә үк ул аны күзәтә, өйрәнә башлый, мәктәп коллективы, сыйныфташлары белән үзен ничек тотуын, кайсы яктан ачылуын сездән яхшырак белә. Өйдәге бала белән мәктәптәге бала бик нык аерылырга мөмкин. Шуңа күрә балагыз турында икенче фикер ишетергә әзер булыгыз. Мондый очракларны, баланың сәламәтлегенә, тормышына зыян килмәгәндә, һәр мәктәп тыныч кына хәл итә. Ләкин зыян килү чиге төрле баланыкы төрлечә бит, – дип фикер йөртә әңгәмәдәшем.

Утырып сөйләшү – бала өчен дә, әти-әниләр өчен дә, мәктәп өчен дә иң кулай чишелеш. Ә инде балалар арасындагы мөнәсәбәтләр кулда тотарлык булмаганда, берничек тә йогынты ясый алмаган очракта Балигъ булмаган балалар белән эшләү комиссиясе эш ачарга мәҗбүр була. Баланың кемгәдер зыян китерүе расланса, бу инде кире кайтып булмый торган, баланың тормышында эз калдыра торган бер чик. Инспекторлар баланы учетка алганнан соң, ул инде сызыкның теге ягында кала. Бу якка чыгарга теләге дә калмый... Кемнең сабыры кайда өзеләсен, кайсы очрак фаҗигагә китереп җиткерәсен алдан белеп булмый. Шунысы куркыта...



Илсөяр ГАРИФУЛЛИНА, Республиканың балигъ булмаган балалар белән эшләү һәм аларның хокукларын яклау комиссиясенең секретаре

– Республикада яшүсмерләр арасындагы бу күренешкә системалы рәвештә профилактик эш алып барыла. Кызганыч, буллинг төрле сыйныф укучыларына хас. Хәтта башлангыч классларда да булырга мөмкин ул. Бу тема буенча мәктәпләрдә аңлату эшләре алып барыла, җыелышларда сөйләнә, онлайн җыелышлар оештырыла. Иң беренче чиратта, зыян күргән бала үзен мыскыл итүләрен яшермәскә тиеш. Әлбәттә, үз әти-әнисенә ачылса, киңәшләшсә, яхшырак. Ләкин кайбер гаиләдәге мөнәсәбәтләр баланы ачылудан чикли: ул курка, үз эченә йомыла. Бу очракта хәлне мәктәптәге белгеч-психологка, ышаныч телефоны белгечләренә, ышанган кешесенә җиткерергә кирәк. Әти-әни, иң беренче чиратта, мәктәп белән элемтәгә керергә тиеш. Дәшми калу аркасында буллинг зур проблемага әйләнергә мөмкин. Баласы мыскыл итүгә дучар булган әти-әни төрле инстанцияләргә гариза белән мөрәҗәгать итәргә хокуклы. Вакытында тиешле игътибар булмаса, ситуациянең зуррак дәрәҗәгә барып җитүе бар. Балигъ булмаганнар белән эшләү комиссиясе бу очракны үз контроленә алырга мәҗбүр була. Әгәр дә баланың тәртибендә хокук бозу составы ачыкланса, полиция хезмәткәрләре аны хисапка алырга мөмкин. Беренче чиратта һәр очрак игътибар белән тикшерелә, һәм закон нигезендә карар кабул ителә. Иң мөһиме – дәшми калырга ярамый! Бала белән бу турыда ешрак сөйләшегез.

киңәш

Балага ничек ярдәм итәргә?

- Балагызны гаепли башламагыз, үзегезне кулда тотыгыз. «Үзең гаепле, нигә моңа юл куйдың, чүпрәк булма», – дигән сүзләр кулланырга ярамый. Сезгә сөйләгәне, ачылганы өчен мактагыз, ярдәм итәчәгегезне аңлатыгыз.
- Мондый очраклар турында әти-әнигә, укытучыга сөйләү – дөрес, ул әләкләү түгел, дип әйтегез.
- Көчле һәм нык булырга, котыртуларга бирешмәскә өйрәтегез.
- Үзе үч алудан тыегыз. Бу – яңа проблемалар гына тудырачак.
- Кемнедер мыскыл итүләрен күргән очракта олыларга ярдәм сорап мөрәҗәгать итәргә, укытучыга җиткерергә кушыгыз.

Балагызны өйрәнегез

- Баланы яхшырак аңлар өчен, гаиләдә традицияләр булдырыгыз. Көн саен кич гаилә белән чәй эчү, 20 минут булса да берәр кызык уен уйнап, уртак шөгыль табыгыз. Башыгызга китап куеп, төрле күнегүләр эшләүдә ярышу кебек кенә уен булса да, сез анда балагызның эмоцияләрен күрәчәксез. «Крокодил» уены да ачылырга ярдәм итә. Үзегез дә хисләрегезне күрсәтүдән тыелмагыз. Сөенегез, көлегез, ачуланыгыз, бирешегез, үзегездән көлегез, көлдерегез. Сездән күреп, бала да эмоцияләренә ирек бирсен. Шулай итеп сез аның төрле ситуациягә карата хисләрен билгеләргә өйрәнәсез.
- Укытучылар, сыйныф җитәкчесе белән сөйләшеп торыгыз. Балада нинди генә үзгәреш сизсәгез дә, мәктәп белән элемтәдә тору яхшы булыр. Бәлки, берәр күңелсез хәл килеп чыккандыр, ә укытучы сезне борчырга теләмәгән. Бәләкәй проблеманы вакытында хәл итү, бала белән утырып сөйләшү аны киләчәктә зур хаталардан саклап калачак.

Килен һәм кайнана... Ике арадагы мөнәсәбәтләрнең матурлыгы, ныклыгы, якынлыгы күбрәк кемнең зирәклегенә, акылына, тырышлыгына бәйләнгән? Иреңнең әнисе үзеңнекеннән тары ярмасы кадәр генә ким булырга тиеш, диелгән динебездә. Ә менә сез моңа ничек ирештегез? Нинди сынаулар, нинди юллар аша уздыгыз? Сөйләгез әле! Башкаларга – бигрәк тә яшьләргә гыйбрәт, сабак, үрнәк итеп сөйләгез.
«Сөембикә» журналы «Килен һәм кайнана» дигән хатлар конкурсы игълан итә. Ул ел дәвамында барачак һәм аларның иң эчтәлеклеләре журнал битләрендә урын алачак. Сездән хатлар көтеп калабыз!

ӘНЕКИ



Вакыт узып, кайбер вакыйгалар синнән ераклашкан, артта калган саен, аларга башкача карый башлыйсың, күп очракта өр-яңадан бәя бирәсең. Кайсысы турында уйлап: «Дөрес эшләгән булганмын!» – дип шатланасың, ә кайберләрен үзгәртү теләге дә туа – ялгышларың өчен көрсенәсең. Ләкин аккан сулар кире кайтмаган кебек, вакыйгаларның тәгәрмәчен дә кирегә бора алмыйсың... Минем соңгы вакытта уйларымда гел кайнанам Мөнәвәрә менә. Вафатына инде дүрт ел үтсә дә (90 яшен тутырырга ике ай гына калганда китеп барды ул), һаман да аны юксынам, озын, йокысыз төннәремдә аның белән серләшәм. Ул исән чакта булган, аңа бәйле вакыйгалар бер-бер артлы күз алдыннан кичә...



Саимә САБИРОВА

Сокланам каенеләремә – аларның әниләренә яки әтиләренә каршы әйткәннәрен хәтерләмим.

Мин аларга килен булып төшкәндә, әнекигә 47 яшь иде – 1924 елның 5 сентябрендә Әтнә районының Югары Көек авылында туган ул. Әнеки мине күзли, мин – аны. Әкренләп шулай бер-беребезгә ияләшәбез. Ул бар эшкә җитез, тик утыра белми. Кайнанамның үз гомерендә көндез ятып ял иткәнен хәтерләмим. Яшь чакта, әлбәттә, андый мөмкинлеге дә булмагандыр, ә олыгайгач – көндез ятуны, гомумән, ялкаулыкка саный иде. «Чирле булмасаң, ничек ятып тормак кирәк», – дия иде.

Намазга соң басты кайнанам. Соң дию бик үк дөрес булмас – Аллаһ тарафыннан сәгате шул чакта суккандыр. Ике урындыкны каракаршы куеп, берсенә Коръәннән үзе күчергән намаз сүрәләре язган дәфтәрен салып, икенчесенә үзе утырып, намаз укый иде. Аннан соң, догаларны ятлагач, намазын тиешле дәрәҗәдә үтәде.

Кайнанамның әнисен – Факия абыстайны да яхшы хәтерлим. Искитмәле карчык иде! Ул бездән аерым яшәде, көн саен оныклары аның хәлен белергә төшә: кызлар идән юа, малайлар су ташый, кар көри, хуҗалыктагы вак-төяк эшне башкара. Авылның кендек әбисе дә, абыстае да иде Факия әби. Чисталыгы белән дә аерылып тора. Күлмәк-ыштанны кайнанам барысына да үзе тегә. Әнисенә дә. Факия әби, бүгенге көн күзлегеннән карасак, модница булган инде. Күлмәкнең биле – билдә, беләзектәге төймә кысып торырга, изү ачык булырга тиеш түгел. Бу таләпләр үтәлмәсә, күлмәк киредән сүтелә, киселә, ялгана, тиешле формага китерелә... Ә кайнанам киемгә таләпчән түгел, үзе турында шаяртып: «Мин шалапут инде», – дип әйтергә ярата. Үзенә алган киемнең беркайчан да гаебен тапканын хәтерләмим.

Без тормышка яңа аяк баскан чак: тегесе җитми, монысы кирәк... Беренче ел Күлле Кимедә яши башлаганда, тәрәзәбездә пәрдә урынына бала чүпрәкләре эленеп торды, чәйнек ролен кәстрүл үтәде. Яшь гаиләдә акчага кытлык булуы аңлашыла инде, ләкин ул чорда сатуда да тормыш кирәк-яраклары юк дәрәҗәсендә иде бит. Каенсеңлем Мөкәррәмә Казанда эшли, әле кияүдә түгел, кулында акчасы бар – әнисенә гел матур-матур киемнәр алып кайта. Ул алып кайткан эчке күлмәкләрне әнекием шыпырт кына миңа да бүләк иткәли. Юмартлыгы чиксез иде аның. Кайнанам туры сүзле дә иде. Кыек-мыеклап тормый: кирәген битеңә бәреп әйтә, артыңнан сөйләп йөрми.

Килен булып төшкән чаклар әле дә исемдә. Ирем Галимҗан – алты бала арасында олысы. Әнекинең кайнана булу тәҗрибәсе дә миннән башланды. Ул нәрсә кушса, мин шуны эшлим. Кайнанам белән бәрәңге әрчибез: мин берне әрчегәнче, ул өчкә җитешә. Оешмаган дип уйламагыз, мин дә «җеннәре белән эшләгән» Гөлбану кызы, ләкин әнекигә җитә алмыйм.

Бер вакыйганы искә алыйм әле. Каенем Фоат армиягә китәргә тиеш. Кич белән мәҗлес билгеләнгән. Әнекием мунчага әзерләнә, ә миңа өч җаймә токмач кисәргә кушып калдырды. Мин 16 яшьтән өйдән чыгып киткән бала, кая инде токмач кисә белү?! Кияүгә чыкканда да 20 яшь кенә иде әле... Дөрес, әнинең токмач кискәнен күргәнем бар анысы, ә үзем тотынып эшләп караган эш түгел. Тик: «Мин кисә белмим», – дип әйтә алмыйм бит инде... Өч зу-у-ур җаймәне матур итеп яхшылап кистем һәм кайнанамның мактавын көтеп, янына бастым. Әнекием токмач янына килде дә, аптырап: «Ә-ә, сездә шулай кисәләрмени?» – диде. Кунада калын-калын, киң-киң токмачлар җәелешеп ята иде. Бу хәлләргә инде илле елга якын вакыт узды, әмма ул һаман да күңелемдә саклана. Юк, ачуланмады әнекием, әрләмәде, мине – яшь киленне кимсетмәде. Шул токмачларны салып аш пешердек. Кич белән өйгә яшьләр җыелды. Мин читтән генә кунакларның аш ашауларын күзәтәм. Солдатны озату мәҗлесенә килгән егетләр кашыктан асылынып төшкән токмачны башта авыз белән эләктереп алалар да аннан соң шупырып-шупырып эчкә тарталар... Мин хәзер үземне шул вакыттагы кайнанам урынына куеп карыйм. Йөземә ризасызлык чыгар иде, әле киленгә берәр сүз әйтеп үпкәләтеп тә куяр идем... Хәер, юктыр, мин дә аны кабатларга тырышам лабаса. Үзем алты ел килен белән яшәү дәверендә киленем белән сүзгә килмәдем – аңлашып яшәргә тырыштым.

Кайнатам иртә гүр иясе булды. Әнекигә ул вакытта нибары 50 яшь. Алты баланың бары берсе генә башлы-күзле. Иң кечкенәсенә – 11 яшь тирәсе. Тормыш авыр дип әйтү генә аз. Чарасызлык, сагыну, юксыну, әйтелмичә калган сүзләр... Өстәл янына утырган саен, озак еллар гел бер сүзне кабатлады: «Өстәл түгәрәк түгел, атагыз булса иде...» Сагынды, бик сагынды ул кайнатамны: «Ияреп чыктым мин аңа, ятрактканмындыр инде...»

Кайнатам вафатыннан соң аның сугыш вакытында төшкән фотосы табылды: күрше авылда берәүдә саклаган булып чыкты. Мин, кош тоткандай, очып өйгә кайтып кердем – фоторәсемне әнекинең кулына тоттырдым. Иренең фронт еллары турындагы бердәнбер истәлек иде ул. Әнеки фотоны башта сыйпады, аннан үбеп куйды һәм күзләреннән яше агып төште...

Икмәк белән бәрәңгегә өстенлек бирсә дә, ризыкны төрләндерә белә иде әнеки. Шунысы игътибарга лаек: һәр баланың теләге исәпкә алына. Нурия ит ашамый, Динар гөбәдиянең йомырка кушмаганын ярата, кабартманың да уртасы тишексез булырга тиеш, кемдер суган яратмый... Шуңа да зур мичкә табалар һәрвакыт аерым тамгалар белән керә иде. Ә оныклар – алары бөтенләй башка! Улым Рөстәм – көтеп алынган, бабайны күреп калган беренче онык. Аның һәр теләге кичекмәстән

Мөгаен, кайнанамның сабырлыгы миңа да сеңгәндер.


Әнинең 80 яшьлек тантанасына 81 роза.

үтәлә иде. Кешелекле, ярдәмчел итеп тәрбияләде ул оныкларын. Бер очрак бик истә. Шәһәрдән кайткан оныкларның берсе сугышырга гына тора. Әби тәрбияләгән Илнур шуңа ниндидер тәмле әйбер суза. Ничек сузуын күрсәгез! Битен көрпә белән каплап... Капламас иде – тырналудан курка. Әмма курыкса да, шәһәр кунагын барыбер өлешсез калдырмый. Өлеш дигәннән, тагын бер гомергә онытылмаслык булып хәтергә уелып калган очрак: аш-су бүлгәндә, әнеки миңа ике өлеш бирә, чөнки бала көтәм – аның өчен дә ашарга тиешмен. И-и, күңелем була иде инде! Күбрәк өлеш тигәнгә түгел, билгеле, мине шулай кайгыртканына.

Мунча яксак, аерым яшәгән каенсеңлесе Хаҗирәне һәм әнисен дә онытмый иде әнеки. Ике бала авыл буйлап ике тарафка аларны чакырырга йөгерә. Мич ризыгы, хуш ис таратып торган себеркеле мунча, мунчадан соң тирләп-пешеп күмер самавыры янында чәй эчүләр... Бер генә тапкыр булса да кайтарасы иде шул рәхәт мизгелләрне!

Ул-кызларына теләге гел бер булды аның: «Балалар ачысы күрергә язмасын!» Аллага шөкер, теләге кабул булды: бүген барыбыз да исәнимин, нык тормышлы. Әнекинең һәр баласы тормышта үз урынын тапты. Барысы да диярлек югары белем алды. Үсеп җиттеләр дә, илебезнең төрле якларына таралдылар. Аннан китте ярыша-ярыша әнине хөрмәтләү! Ел саен көздән язга кадәр кунакта йөри иде ул. Ләкин «ямьле булса да торган җир, сагындыра туган ил». Мәскәүдә кызы Фирданиядә кунакта булганда, тәрәзәдән гел машиналарны күзәтә икән әнеки. «Фоат машинасына охшаганнары да бар», – ди икән. Фоат – уртанчы улы, төп йортта калды – әткәй дә шулай теләгән иде. Хатыны Раушания белән кайткан-киткән һәрбер кешегә хөрмәт күрсәтеп яшәделәр. Җәй буе йорт тулы төрле яшьтәге бала-чага, чыр-чу... Түзгәннәренә рәхмәт! Кайнанама аерым рәхмәт, чөнки ул да көне буе оныклары белән әвәрә килә. Килендәшем Раушания белән сүзгә килмәде алар: киңәшләшеп яшәделәр. Менә шул килене белән улын сагынып, әнекием Мәскәүдә тәрәзәдән тәрәзәгә йөри инде: машиналарны да аларныкына охшата. Һәр баласы әнекиемнең хәлен даими белешеп торды – арага чүп салмады. Күгәрчен сөтен телим, дип әйтсә, анысын да табарлар иде.

Гомер узган саен, тормыш кыйммәтләре үзгәрә. Яшь чакта үтә дә дөрес дип саналган нәрсәләр бәһасен югалта. Бүгенге көн күзлегеннән караганда, мин дә күп кенә әйберләргә башкача мөнәсәбәттә булыр идем, юкка-барга игътибар итмәс, үпкәләмәс идем. Каенсеңлем Мөкәррәмә сөйли: «Әнине кунакка алып киләбез. Ул яраткан ризыкларны пешерәм, концертларга, театрларга алып барам. Ипи белән чәй эчәргә ярата иде әни, ә мин алдына торт куям, ашамаса үпкәлим. Хәзер менә үзем чәйне ипи белән эчәм... Эчсен иде шул чакта әни чәен ипи белән дип искә төшерәм. Юк бит, әнине сыйлау теләге зур булган... Менә әнине алып китәргә дип Фоат абый килә. И-и, шул чакта әнинең куанганнары! Ә мин тагын үпкәлим: «Юк инде, җибәрмим, мин дә бит синең балаң», – дим. Кызымның үз тормышы әнә. Гел чакырып тора. Барам һәм бер кич тә кунмыйча кире кайтам. Үз өемә, үз җәннәтемә... Әни дә шулай булгандыр. Кайтарасы калган икән әнине Фоат абый белән».

Шагыйрьләрнең, язучыларның әниләр турындагы әсәрләренең дә күбесе көрсенү, вөҗдан газабы кичерү белән сугарылган бит. Алар да бу әсәрләр аша күңел тынычлыгы эзли, мәңгелеккә киткән әниләреннән гафу итүне сорый кебек:

Кайталмадык вакытында,
Көткәнең белеп тордык.
Сиңа ашыгасы иде,
Ә без һаман дөнья кудык.

Бәлки, безнең дә кадерле кешебезне үзебез дә аңламыйча үпкәләткән чакларыбыз булгандыр. Шуларны барлыйм, шулар өчен күңелемнән мин дә әнекидән гафу сорыйм...

Әтнә районы,
Югары Көек авылы.

Фото: гаилә архивыннан


Арткы рәттә сулдан-уңга: уллары Фоат, Рәфкать, Галимҗан; кияүләре Габделәхәт, Харис, Рафаэль. Алгы рәттә сулдан-уңга: киленнәре Саимә, Резеда, Раушания; кызлары Мөкәррәмә, Нурия, Фирдания.

БЕР-БЕРЕҢӘ ЮЛ КУЮ



Сәйдә абыстай АППАКОВА

Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим!

Безнең чорда гаилә корган яшь парларга иң еш әйтелгән нәсыйхәтләр, мөгаен, «Телеңне тешлә», «Телеңне озынайтма», «Сабыр төбе – сары алтын, син дә сабыр бул», «Бер-берегезгә юл куегыз, авыр булса, ошамаса да артка ташлагыз» кебек халкыбыз телендә күп еллар кабатланучы гыйбарәләр иде. Без шуларны ишетеп үстек, һәм олыларның никахыбызның озын гомерле булуын ихластан кайгыртуын шушы гыйбарәләр аша аңладык. Ни кызганыч, хәзергеләр моның ни икәнен аңлап та бетерми бугай. Әйтик, юл куюны бара торган сукмагыңнан, тротуардан бер-береңә бәрелешмичә, юл куеп узу дип кенә аңлыйлар, күрәсең. Берничә мәҗлестә бу хакта аңлатуымны сорадылар.

Чыннан да, нәрсәдән гыйбарәт соң ул юл кую? Гади генә әйткәндә, телеңә хуҗа булып, бик авыр булса да, дәшми кала белү. Ягъни бер-береңне аңламаган чакта сабырлык күрсәтү, эндәшмичә калу. Эшне, сүзне тавыш-гаугага илтеп җиткермичә, кычкырмыйча гына, берең әйткәнне икенчең аңлый белү. Менә болар бер-береңә юл кую була. Конфликтны тыныч аңлашу, сабырлык белән уздыру.

Әгәр ир яки хатын бала вакытында ук тиешле тәрбия алган булса, ягъни әти-әнисе тарафыннан әдәп-әхлак кагыйдәләре төшендерелгән, үзара мөнәсәбәтләрне дөрес, ипле итеп корырга күнектерелгән булса, бу очракта яшьләргә бер-берсенең холкына ияләнеп китәргә дә, бер-берсенең холык-фигылен аңларга да җиңелрәк. Гаиләсендә ислам тәрбиясе алып үскән яшь парларда «табак-савыт сирәк шалтырый», ягъни тавыш чыгарырлык сәбәпләр булмый. Низаг-фәлән, аңлашылмаучылык чыккан очракта да, ул озакка бармый, кичерелә, гафу ителә. Тыныч тормыш өчен һич кирәге булмаган вак-төяк сүзләргә, җитешсезлекләргә игътибар итмичә, сүз үстермичә дип тә әйтә аны халык. Шулай яшәсәләр генә никахлары озын гомерле, нык була.

Гаиләдә тавыш чыккан хәлдә дә, күтәренеп, әти-әни йортына әйләнеп кайтмыйсың. Никахыңны җимереп, аерылышуны максат итеп яшәмисең. Бергә торырга, ничек тә алга таба тату яшәүнең бер жаен табып, әлеге дә баягы бер-береңә юл куеп яшәргә тырышасын. Ире ачуланганда хатын эндәшми калса, хатын тузынганда ире сабырлык күрсәтсә – менә бу инде бер-беренә юл кую дип санала.

Балаларыбыз башлы-күзле булып, үзләре гаилә коргач, әй тырышабыз аларның үз фатирлары, яхшы эшләре булуына, бай булуларына. «Кызым яки улым! Безнең әти-әни вазыйфасы үтәлде. Торырга тырыш! Тормыш булгач төрлесе була, уткәрә торган бул. Юл куярга гадәтлән. Юк-барга хәтереңне калдырып, үпкәләп тә йөрмә. Мәгълүм мәкальдәгечә: тау шуганда чананы үзең тартып менгәндә генә тау шууның ләззәте була. Тормышта да бер-береңә терәк булып, иңне-иңгә куеп хезмәт иткәндә генә, олысын-кечесен хөрмәт итеп яшәгәндә генә никахыгызның гомере озын була», – дип үгетләргә кирәген дә беләбез. Күрәсең, бер-беренә игътибар, гаилә тынычлыгы өчен икесе дә бер үк дәрәҗәдә җаваплы булуы хакында һаман исләренә төшереп, үгет-нәсыйхәтне кабатлап торырга кирәк.

Әссәламегаләйкем үә рахмәтуллаһи үә бәрәкәтүүһ!

«СИН АЛАРГА ҖАН ӨРГӘНСЕҢ...»



Фото: Илдар Еникиев

Киштәләрдән күпме Китап
Торган кебек сине алкышлап.
Син аларга җан өргәнсең,
Күз нурларың белән нәкышлап.



Зәлия
АХУНОВА

Башкортстанның танылган шагыйре Марис Нәзировның «Күз нурларың белән» дигән бу шигыре Зәйнәп Биишева исемендәге Башкортстан «Китап» нәшриятында озак еллар татар китабы секторын җитәкләгән нәширә, җәмәгать эшлеклесе Динә МОРЗАКАЕВАга багышланган. Ул – Башкортстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, Вәзих Исхаков һәм Мифтахетдин Акмулла исемендәге премияләр лауреаты, Бөтендөнья татар конгрессының «Татар милләтенә күрсәткән олы хезмәтләр өчен» медале иясе. Үзе дә кызыклы җыентыклар төзүче, Башкортстандагы татар мәктәпләре өчен сыйныфтан тыш уку китаплары авторы. Нәшрият тарихы, татарча нәшер ителгән басмалар хакында хезмәтләре дә бу өлкәдә яңа сүз, яңа баскыч. Вакытлы матбугаттагы язмалары да күбрәк мәдәният, китап нәшер итү турында.

Динә апа, сез Башкортстанның күренекле шәхесләре белән данлыклы Чакмагыш районы кызы. Татар теленә, әдәбиятына мәхәббәтне сездә кем тәрбияләде?

– Мин Иске Үзмәш дигән авылда туып-үстем. Халыкта аны Качелга дип йөртәләр: елга башы кайчыдай кисешкән ерымнарга бәйләп, киек казлар оя коруга ишарәләп шулай аталган, диләр. Россия буенча сибелгән татар авылларының берсе ул, язмышы да шуларга охшаш. Ясак татары Үзмәш бабабыз нигез салган, мәдрәсәле, ике мәчетле авыл булган, халкы игенчелек, терлекчелек, һөнәрчелек белән шөгыльләнгән.

Татар теленә, әдәбиятка мәхәббәтне махсус тәрбияләү кирәк тә булмады кебек без үскәндә. Зур гына, нык кына татар авылы: ана теле безнең аңга, зиһенгә сулаган һава, эчкән судай табигый сеңде. Әни – без инәй дидек – Тукай әйткәнчә, үз ана телебездә көйләде бишек җырын, ана телебездә телем ачылган. Инәй уй-фикерен шигъри юлларда белдерергә, гыйбрәтле парчалар сөйләргә әвәс иде. Бик тә иманлы Галимә картинәйне муллаттәй, ягъни мулла түтәй дип йөрткәннәр. Ул – авылның кендек әбисе, күп сабыйлар дөньяга аның кулында аваз салган. Мөнәҗәтләр көйләгәне, догалар өйрәткәне, аларны татарча тәфсирләгәне хәтердә. Әтием Гайнелбаян – безнең якта күбрәк әтәй диләр – үзе дә китап, газета-журналлар укырга яратты, безне дә мавыктырды. Балта остасы иде: йортны да үзе бурап салды, өй җиһазлары, тәрәзә яңаклары – кашагалары, ишекләр, арба-чаналар ясый иде. «Зингер» машинабызда кичләрен кием-салым теккәне дә истә. Бөек Ватан сугышында катнашкан, ике тапкыр яраланган. Җыйнак кына китап шкафыбызда – китаплар, дәреслекләр. «Кызыл таң», үзебезнең районның «Коммунизмга» («Игенче»), «Башкортстан пионеры» газеталарына, «Азат хатын» («Сөембикә») журналына даими язылабыз. Урамда яшьтәшләр белән аралашу да – ана телебездә. Авыл башлангыч мәктәбендә укыту да – ана телендә, хәзергечә ата-ана ихтыяры дигән шарт та юк. Хәер, барыбер татарча укуны сайлар иде алар... Митрә-Әюп урта мәктәбендә дә ана теле һәм татар әдәбияты, хәзергечә кысрыкланмый, тулы сәгатьләрдә өйрәнелде.

Зәйнәп Биишева исемендәге Башкортстан «Китап» нәшриятында кырык елга якын хезмәт иттегез, Динә апа. Үткән гасырның туксанынчы елларында нәшриятта өр-яңа бүлек – татар китаплары секторын оештырдыгыз. Бу сектор оешкач, татар телендә иҗат итүче әдипләр сезне кулъязмалар белән күмделәрме?

– Татарча китаплар Уфада XIX гасырда дөнья күрә башлый, шул исәптән, революциядән соң – безнең дәүләт нәшриятында да. Әмма соңрак, сәясәт аркасындамы, казна исәбенә татар китабы басу озак елларга туктатылган. Замана таләбе буларак, үзгәреш чорында бу мәсьәлә янә кискен күтәрелде. Нәтиҗәдә, халык ихтыяҗын исәпкә алып, татар телендә китап нәшер итүне җайга салырга карар ителде. Беренче карлыгачыбыз – талантлы шагыйрь, журналист, җәмәгать эшлеклесе Марис Нәзировның «Янә утларга керәм» дигән шигырьләр җыентыгы булды. 1994 ел иде бу.

Була бит шулай: ниндидер вакыйганы якынайтырга тырышып йөрисең, көтеп аласың да, ахырда аңа әле тулы әзерлек житмәгәне ачыклана... Башкортстан «Китап» нәшриятында татар китаплары секторы оешкач та шундыйрак хәл туды: нәшрият карамагында ана телебездә бернинди дә әзер кулъязма юк иде. Әдипләребезгә мөрәҗәгать итеп, тәүге кулъязмаларны үзебез соратып алдык.

Әлбәттә, секторны ачу Башкортстандагы татар әдипләре, гомумән, республикада яшәүче милләттәшләребез өчен ифрат әһәмиятле, олы сөенечле вакыйга булды. Олуг язучыларыбыз да, башлап каләм тибрәтүчеләр дә рухи күтәренкелек кичерделәр, бер-берсен котладылар. Күпләр әсәрләрен нәкъ менә татар телендә күрергә теләкләрен белдерде – кулъязмалар ишәйде, Башкортстан язучылар берлегендә Татар әдипләре берләшмәсе булдырылып, ана телебездәге әдәби иҗат шунда тикшерелә, бәяләнә башлады.

Халык яңадан-яңа басмаларны сөенеп кабул итте: чыгарган китапларыбыз Башкортстанда татар әдәбиятының исән калуын гына түгел, үсешен, яшәргә һәм яшәрергә омтылышын дәлилләде.

Нәширлек, мөхәррилек вазыйфасы нидән гыйбарәт?

– Уфага килгәч, 1973 елда Башкортстан китап нәшриятына кече мөхәррир булып эшкә урнаштым. Андагы рухлану, канатлану! Танылган әдипләрнең үзләре белән бергә эшләү, әдәбият казанының уртасында кайнау! Хезмәттәшләрем кем диегез – Башкортстанның булачак халык язучысы Ногман Мусин, халык шагыйре Равил Шаммас! Ул чакта ук иҗаты белән халык игътибарын яулаган Нурия Измайлова белән берничә ел янәшә утырдык, ахирәтләр булдык.

Ә мөхәррир – кулъязманы иң беренче тәфсилләп укучы гына түгел, ул – әдипнең аркадашы, хөкемдары, тәнкыйтьчесе, киңәшчесе. Зәркәнче кыйммәтле асылташны да, гадирәген дә зәвыклы йөзек кашы итеп балкыткан шикелле, мөхәррир дә кулъязманы ил йөзенә, кеше күзенә чыгарырлык сәнгать әсәре – китап итеп эшләп җиткерә. Монда камил тел, һөнәри осталык кына түгел, кешелеклелек сыйфатлары да зур әһәмияткә ия: булачак басманы камилләштергәндә авторның дәрәҗәсен төшерми, күңелен сүрелдерми генә кимчелекләрне күрсәтә белергә дә кирәк.

Хуш, менә ул күз нурларын түгеп, зиһен көчен җигеп, кат-кат укып, җитешмәгән җирләрен үзгәртеп-төзәтеп, тышлык һәм башка сурәтләрне әзерләтеп, «Җыярга!» – дигән фәрман биреп, кулъязманы басмаханәгә озата. Тылсымчы әмере белән эшләнгән могҗиза кебек, шул сүз гамәлгә ашырылып, битләргә салынган корректура килгәч, аны кабат тикшереп: «Басарга!» – дип кул куя. Ниһаять, нәшрият мөхәрриренең җаваплы, бер карашка хәтта ялкыткыч хезмәтендә иң тантаналы, иң ләззәтле мәл килеп җитә – әле генә басылган өр-яңа китапның тәүге данәсе өстәленә килеп ята. Мөхәррир, бер яктан чиксез горурлык һәм канәгатьлек белән, икенче яктан яңа туган китапның хәзер нәшрияттан чыгып, үзенчәлекле үз язмышы белән китәчәгенә бераз моңсуланып,

Башкортстандагы татар китабының киләчәге милләтебезнең киләчәгенә бәйле.

басманы кулына ала. Инде һәр җөмләсе, һәр нокта-өтере таныш, җанга кадерлегә әверелгән, типография буявының исләре аңкып торган, җилеме әле кибеп тә өлгермәгән китапны кабат җентекләп күздән кичереп, тәвәккәлләп, иң алгы биткә: «Дөньяга чыгарырга!» – дигән сүзләрне яза: аны укучыга җиткерергә фатиха бирә. Шушы боерык имзалануга, серле бер хикмәт белән бар гавәмгә хәбәр тарала: «Сөенче, китап чыкты!», «Сөенче, китап чыкты!»...

Бигрәкләр дә тәмле итеп сөйләдегез! Эшегезне яратып башкаруыгыз һәр сүзегездән сизелә. Шуңа сезне «милләт китабының кендек әбисе» дип олылыйлар да инде! Ничә татар китабына «кендек әбисе» булдыгыз икән?

– Мөхәррир буларак, дөньяга чыгарга фатиха биргән китапларымның төгәл исәбен санамадым, шулай да ярты меңнән артканнардыр дип уйлыйм. Алдарак әйтелгәнчә, нәшриятта кырык еллап хезмәт ителде, тәүге ике дистә елда дәреслекләр редакциясендә эшләдем. Ул чорда да Башкортстандагы татар мәктәпләре өчен кайсыбер уку кулланмалары чыга иде.

Лаеклы ялга киткәч тә һөнәри шөгылемнән читләшмәдем: китаплар шәхси нәшриятларда да басыла бит. Башкортстан дивар календаренең тәүге чыгарылышын төзүче-авторларның берсе идем, шул шөгыльгә әлегәчә тугрылык саклыйм. Аннан «Ихлас» мәчетенең яңа басмасы – «Ихлас-Шәриф» мәҗмугасының мөхәррире булып киттем.

Тик хикмәт санда гына түгелдер, сыйфат мөһимрәктер. Республикабызда татар телендә китаплар нәшир итүне тергезүдә катнашу, шул илһамлы чишмә башында булу, халык шагыйрьләре Наҗар Нәҗми, Әнгам Атнабаев кебек бөекләребез белән аралашу, бихисап яшь талантларның тәүге китаплары чыгу шатлыгын уртаклашу – язмыш бүләгедер. Күренекле шагыйрә, әдибә, популяр җырлар авторы Дилә апа Булгакова белән мөнәсәбәтләребез исә дуслыкка әйләнде: ике дистәдән артык китабын дөньяга чыгарырга бергәләп әзерләдек.

Үзегез кайсы татар язучыларын яратып укыдыгыз?

– Кечкенәдән шигърияткә ныграк үз күрдем, Такташның «Мокамай», «Алсу»ларын укып аеруча әсәрләнә идем. Авыл китапханәсенең өч-дүрт киштәсенә иданнән түшәмгәчә тезелгән китапларны, артык сайланып тормыйча, йотлыгып укыганым истә. Инәй: «Йокла, укыма инде төн уртасында», – дип кисәтсә, юрган астына чумып, китапны кесә фонаре яктысында укып ята идем...

Өйдәге китаплардан ул чакта иң күп кулланганым – «Йорт эшләре» китабы булгандыр. Аш төрләндерергә дә, апамның кызына күлмәкләр тегәргә дә, бәйләм серләренә дә шуннан өйрәндем, агроном-техник белемле әтәйгә бакча үстерү киңәшләре дә әйтеп куя идем хәтта...

Лаеклы ялга чыккач, сез яңа сыйфатта – җәмәгать эшлеклесе буларак ачылдыгыз: Башкортстанның «Сәхибҗамал» оешмасын милләттәшләребез арасында танытуга ирештегез...

– Җәмәгать эше бөтенләй ят түгел иде миңа: нәшриятта башта комсомол әйдәүчесе, аннары һөнәри берлек оешмасы рәисе булдым. «Сәхибҗамал», әлбәттә, күпкә киңрәк мохит. Оешмабыз халкыбызның асыл кызы, төрки дөньясының тәүге актрисасы, Татарстанда һәм Башкортстанда милли театр сәнгатенә нигез салучы талантлы режиссер Сәхибҗамал Гыйззәтуллина-Волжская исемен йөртә: бу инде үзе аның әгъзалары алдына югары бурычлар куя. Безнең берлек нинди дә булса күрсәтмәләр нигезендә түгел, ә Башкортстан җирлегендә яшәүче гүзәл затларның теләге, ихтыяры белән булдырылган. Үз җирлегебездә халкыбызның күркәм йолаларын, гореф-гадәтләрен саклау, милләттәшләребезнең үзаңын үстерү – көнүзәк мәсьәләләребез. Оешмабызның үзгә бер сыйфаты – бирегә башлыча иҗатка хирыс хатын-кызлар туплана, районнардагы бүлекчәләрне дә башлыча танылган каләм ияләре, матбугат, мәдәният алдынгылары җитәкли. Уфада «Нур» татар драма театрында уздырган кичәләребезгә дә башкаланың үзеннән генә түгел, республикабыз районнарыннан да туган телдә аралашуга сусаган, шигъри сүзне тансыклаган тамашачылар килә. Быел март ахырында Габдулла Кариев исемендәге Татар дәүләт яшь тамашачы театрында узган әдәби кичәдә янә Казанны шаулатып алды шагыйрәләребез. «Сөембикә», «Мәдәни җомга», «Казан утлары» редакцияләрендә, Татарстан дәүләт телерадиокомпаниясендә, Бөтендөнья татар конгрессында, Татарстан Язучылар берлегендә очрашулар мәдәни аралашуга чикләр булмавын янә куәтләп, күңелләрдә онытылмас хатирә булып калды.

Оешмабыз быел үзенең 20 еллыгын күпсанлы чаралар белән билгеләде. 2001 елда Уфа сәнгать институтында китапханә мөдире булып эшләгән киң карашлы, тирән белемле Гөлҗиһан Янһүдина нигез сала аңа. Бүген «Сәхибҗамал»ны мәгариф ветераны, Россиянең халык мәгарифе отличнигы Флүсә Назаргулова җитәкли. Яшәгән төбәге, нәсел-заты, мөлкәт-байлыгы нинди булуга карамастан, хатын-кызларның теләк-омтылышлары нигездә охшаш: мәхәббәтле гаилә кору, хәләле белән аңлашып тату гомер кичерү, балаларын дөньяда лаеклы урынын табарлык итеп тәрбияләп үстерү, эшеннән, тормышыннан ямь табып, сөеп-сөелеп, бәхетле яшәү... Барча хатын-кызларга да нәкъ шуларга ирешергә язса икән!

Инде тагын китап турында. Сез кайчандыр тергезеп җибәргән татар китабы секторының бүгенге хәлләре ничек? Башкортстанда татар китабының киләчәге бармы?

– Эшнең дәвамлысы – иң хәерлесе, диләр. Шөкер, татар китабы секторы хезмәтен дәвам итә, һәр елны күпмедер санда ана телебездә әдәби китаплар, уку кулланмалары дөнья күрә. Башкортстандагы татар китабының киләчәге милләтебезнең киләчәгенә бәйле. Китап – милләтнең рухи коды, милләтебез сау булса, китабы да яшәр!

ТАТМЕДИА

ТАТМЕДИА ГАЗЕТА-ЖУРНАЛЛАРЫ ҺӘМ ОТКРЫТКАЛАРЫ — МАРКЕТПЛЕЙСЛАРДА

WILDBERRIES



KazanExpress




OZON



Я Маркет







АО «ТАТМЕДИА». Адрес: 420066
г. Казань, ул. Декабристов, 2.
ГРН 1071690057834

16+
Реклама

СЕЗ – РЕСПУБЛИКАНЫҢ ЙӨЗЕ

Без аларның һәммәсен яраттык. Якын иттек. Язмышларын йөрәк аша үткәрдек... Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Татар телен саклау һәм үстерү комиссиясе белән бергәләп уздырган «Татар гаиләсе / үрнәк алыгыз» бәйгесендә катнашу өчен республика авылларыннан сайлап алган гаиләләр турында әйтүебез. Матур гаиләләр! Аларда халкыбызның гореф-гадәтләре, дине һәм иң мөһиме – Туган тел саклана!

Ел дәвамында барган конкурс инде менә төгәлләнде. Кырыктан артык гаилә арасыннан жюри иң-иңнәрен барлады. Унбер гаилә җиңүче дип табылды: Фазлыевлар (Балтач районы, Бөрбаш авылы), Шәфигуллин-Фәтхуллиннар (Кукмара районы, Зур Сәрдек авылы), Миңгалиевләр (Кайбыч районы, Борындык авылы), Шәфыйковлар (Азнакай районы, Үчәлле авыллы), Хисамиевлар (Саба районы, Тенеки авылы), Галәветдиновлар (Нурлат районы, Кәкре Атау авылы), Шәвәлиевләр (Арча районы, Пөшәңгәр авылы), Баһавиевлар (Биектау районы, Мәмдәл авылы), Мостафиннар (Аксубай районы, Иске Ибрай авылы), Шаһиевлар (Лаеш районы, Державино авылы).

Татарстан Милли китапханәсенең концертлар залы сәхнәсенә аларның барысы да күтәрелде. Күбесе – бер түбә астында өч буын яшәүчеләр. Ир-атлар – нигез хуҗалары, хатын-кызлар – төп нигез киленнәре...

Дипломнар тапшырыр алдыннан, Татарстан Дәүләт Советы Рәисе урынбасары, Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Татар телен саклау һәм үстерү комиссиясе рәисе Марат Әхмәтов: «Сез – республиканың йөзе, – диде. – Һәр гаилә – зур дәүләтнең игелекле, сәламәт бер күзәнәге. Ул күзәнәкләр рухи яктан сау икән, дәүләт көчле һәм үсешкә сәләтле була. Комиссия үз эшчәнлеген башлаганда, телне кайда саклап була, кем белән эшләргә дигән сорауга җавап эзләде һәм иң элек гаиләгә тукталды. Сезнең кебек гаиләләрне «Сөембикә» журналы аша эзләп тапканбыз икән, үзебезнең максатка ирешкәнбез. Халкыбыз, республикабыз сездәй гаиләләргә бик бай. Шуңа күрә тормышыбыз матур, шуңа күрә киләчәккә ышанычыбыз зур».

Җиңүче гаиләләрне «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесе Айдар Сәлимгәрәев, «Татмедиа» акционерлык җәмгыяте генераль директоры Шамил Садыйков («Татмедиа» җәмгыятенең махсус бүләген милли басмаларны, татар китабын яшәтүгә үз өлешен керткән өчен Әгерҗедән Закировлар гаиләсенә тапшырды), Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты Римма Ратникова, Бөтендөнья татар конгрессы каршындагы «Ак калфак» татар хатын-кызлары иҗтимагый оешмасы рәисе Кадрия Идрисова, Бөтенроссия «Татар гаиләсе» фонды директоры Миләүшә Гайфуллина һәм Татарстан Диния нәзарәтенең баш казые Җәлил хәзрәт Фазлыевлар котлады.

Гаиләләрнең һәрберсе акчалата бүләк тә алды.

Фото: Анна Арахамия





























PRESSA


Разил ВӘЛИЕВ

Хаксызлыкны күреп ярсыйм, шашам, / Матурлыкны күреп тезләнәм. Йә дөньяны үзгәртәм мин бүген, / Йә булмаса / Үзем үзгәрәм... Разил абый Вәлиевне шигырь юлларыннан ук таныгансыздыр, мөгаен: кыю, кайнар, хисле! Танылган язучы, шагыйрь, драматург, популяр җырлар авторы... Күренекле дәүләт эшлеклесе, җәмәгать эшлеклесе, халкыбыз язмышы өчен борчылып, янып йөргән зур шәхес, милләтпәрвәр... «Разилнең һәрвакыт төпле фикере, саллы сүзе бар. Ул бөтен җаны-тәне белән халык язмышы өчен янып яши», – ди аның турында Минтимер Шәймиев. Илһам Шакиров аны «моңлы, җырлы, уйлы егет» дип, Мөхәммәт Мәһдиев «яшьлек җырчысы» дип атаган... Бүген Разил Вәлиевнең 75 яшьлек юбилей көннәрендә аның иҗатын үзгәрәк, җылырак итеп ачарга булдык: шигърият битенә юбилярның җырга әйләнеп киткән шигырьләрен сайладык. Сез яратып җырлый, яратып тыңлый торганнарын! Һәркайсы үз моңы, үз аһәңнәре белән чиртсен әле күңел кылларын!..

САГЫШЛАРНЫ ТАРАТЫРГА... МӘҢГЕГӘ ЯРАТЫРГА...

Ядкарь

Күптән инде, күптән очрашкан юк,
Хәтерлимсез бергә чакларны?
Күңелләрдә йөргән татлы сагыш –
Шул чакларның моңлы ядкаре.

Уртак иде хисләр, айлы кичләр, –
Без кертмәдек анда ятларны.
Күңелләрдә йөргән дуслык хисе –
Шул чакларның моңлы ядкаре.

Бергә откан өмет тулы җырны
Йөрәк инде мең кат ятлады.
Үткәннәрдән бары шул җыр калды,
Ул җыр безгә яшьлек ядкаре.

Яшьлегем канатында

Язлар белән син килерсең төсле,
Мин язларга шундый ышанам.
Язлар җитсә, ташый мәхәббәтем,
Минем күңел язга охшаган.

Язлар үтәр, сүнмәс безнең хисләр,
Мин бит сиңа шундый ышанам.
Ялгыз җанда күз җилләре исә,
Ялгыз җаннар көзгә охшаган.

Очып килдем синең янга
Яшьлегем пар канатында.
Сагышларны таратырга,
Мәңгегә яратырга,
Мәңгегә яратырга.

Дулкын

Чем-кара карлыгачлары.
Гөнаһсыз иде яры.
Ник шунда гына калмады,
Ник дулкын китте ары?

Тарсынып язмыш ярларын,
Ул диңгезгә юл алды.
Тау-дулкыннар арасына
Кереп күздән югалды.

Күз яшьле акчарлаклары...
Күренми инде яры.
Зәңгәр күк һәм зәңгәр диңгез,
Йолдызлар монда бары.

Бар иде гөлләр, таллары...
Ник китте икән ары?
Елга ярын сагынып елый
Диңгезнең дулкыннары.

Таң җыры

Уңда юллар, сулда юллар.
Юлларга кемнәр чыгар?
Таңда егет җырлап узса,
Кыз күңеле ничек чыдар?

Егет китәр еракларга,
Эзләрен яңгыр юар.
Кыз көн саен чиләк асып,
Авыл башына чыгар.

Көтмә, дип үртәр кызлары,
Аның күңеле чуар.
Яңгыр түгел, күз яшьләре
Кызның иренен юар.

Уңда юллар, сулда юллар...
Кайтмыйча ничек чыдар?!
Таңда егет җырлап кайтыр,
Кыз йөгереп каршы чыгар.

Зинһар өчен, кермә төшләремә

Зинһар өчен, кермә төшләремә...
Мин бит сине күптән онызттым.
Җәй җилләре күптән,
күптән агарттылар,
Тараттылар сагыш болытын.

Зинһар өчен, кермә төшләремә,
Уянам да никтер боегам.
Әйтерсең лә су алмакчы булам
Күптән кипкән сусыз коедан.

Зинһар өчен, кермә төшләремә,
Таң атуга төшләр өзелә.
Көннәремне, елларымны алдың,
Таңнарымны калдыр үземә.

Зинһар өчен, кермә төшләремә...
Үртәмәче, көлмә еректан.
Сине түгел, мин бит яшьлегемне
Шулай сагынам, шулай яратам.

Зинһар өчен, кермә төшләремә...
Минем хәлгә кемнәр төшенә? –
Сөям хәзер бары, бары хыялымда,
Яшим хәзер бары төшемдә.

Мин бит синсез торалмам

Саубуллашмый китеп бардың,
Югалдың рәшәләрдә.
Телсез калдым, белмәдем мин
Ни диеп дәшәргә дә.

Син үпкәләп китеп бардың,
Юатырга соңардым.
Соңарганнар, минем кебек,
Югалтадыр сыңарын.

Еламыйча китеп бардың,
Синсез ничек яшәрмен?
Минем күңелләргә тулган
Синең дә күз яшьләрең.

Саубуллашмый китеп бардың,
Кайтып кер исәнләшеп.
Мин бит бары сине көтеп,
Җан асрыйм, исән яшим.

Син югалган юлга карап,
Сагышларга уралам.
Сагышларыма уралам,
Мин бит синсез торалмам.

Бергә узыйк Казан урамын

Мин сагынам назлы язларыңны...
Язларда мин хыял корамын.
Язларда мин мәхәббәтем эзләп,
Мең урадым Казан урамын.

Мин сагынам озын кышларыңны...
Күңелемә кучә бураның.
Бураннарда сине эзли-эзли
Мең урадым Казан урамын.

Мин яратам җылы җәйләреңне...
Мин җәйләрдән яңгыр сорадым.
Сагышларым яңгыр юмасмы дип,
Мең урадым Казан урамын.

Мин яратам моңлы көзләреңне...
Көзләрдән мин бәхет сорадым.
Икебезгә уртак бәхет эзләп,
Мең урадым Казан урамын.

Мин Казанда сине эзләп таптым,
Мин Казанда бәхет юрадым.
Бергә узыйк язмыш урамнарын,
Бергә узыйк Казан урамын!

Төсле җыр

Нигә күк һәрвакыт зәп-зәңгәр,
гел зәңгәр?
Сагышлы зәңгәрлек
сибелә күзләрдән?
Сөйсәң син әгәр дә, –
Сагыш бар зәңгәрдә.
Зәңгәр күк, зәңгәр күз, зәңгәр моң...
Мәхәббәт сагыштан тора ул.

Нигә таң көн саен алсу гел, гел алсу?
Таңнар да нигә соң һәрвакыт ямансу?
Сөйсәң син әгәр дә, –
Таң – алтын мәгарә.
Алсу күк, алсу йөз, алсу моң...
Мәхәббәт шатлыктан тора ул.

Зәңгәр күк, алсу таң, якты көн,
кара төн...
Син мине, ахрысы, мәңгегә караттың.
Төсләрне тараттың...
Мин сине яраттым.
Сөюем – бәхеткә илткән юл...
Сагышлы шатлыктан тора ул.

Кышкы учак

Тагын бер ел иңләп узды
Язмышым урамнарын.
Кайгыларны адаштыра
Яңа ел бураннары.

Тагын бер ел шаулап узды,
Туздырып ап-ак карны.
Ак кар булып уйнап оча
Яңа ел шатлыклары.

Тагын бер ел узды җирдән,
Тик хәтер булып калды.
Аклык булып җиргә ята
Яңа ел болытлары.

Тагын бер ел гөрләп узды –
Сиздем гомер узганын.
Бәхет кебек балкый күктә
Яңа ел йолдызлары.

Хатлар көтәм авылдан

Җырлар оттым авылымда
Чишмәләр тавышыннан.
Кайда минем көмеш чишмәм,
Очрашып кавышырга?

Кайда минем урманнарым,
Кайда соң болыннарым?
Нинди җилләр тарый икән
Талларның толымнарын?

Ала алмыйм күзләремне
Авылым якларыннан.
Хатлар көтәм, сәлам көтәм
Бәхетле чакларымнан.

Таңнар атса, кичләр җитсә,
Чишмәләрне сагынам.
Сагышларым басылыр күк,
Хатлар килсә авылдан.

Сагынам

Су буенда үскән өянкеләр
Синең кебек ак шәл ябынган.
Синең чәчең төсле ак җил тузгый, –
Мин кышларда сине сагынам.

Карашыңдай җылы, аяз көннәр,
Җилләр исә синең ягыңнан.
Гөрләвекләр булып кайтыр идем...
Мин җәйләрдә сине сагынам.

Синең сагыш әллә кучкән инде? –
Урманнарга сары кабынган.
Күзләремдә яшьме, яңгырмы ул? –
Мин көзләрдә сине сагынам.

Офыкларга карап, һәр көн саен
Сине уйлыйм, сиңа табынам.
Бөтенләйгә тиздән кайтырмын күк, –
Сине, әнкәй, сине сагынам.

Чаба поезд, чаба...

Чаба поезд, чаба
Туган якка таба, –
Каршы ала горур имәннәр.
Бозып яшьлек антын,
Туган якка кайта
«Хуш мәңгегә, сау бул!» дигәннәр.

Чаба поезд, чаба
Туган якка таба, –
Түземнәрем узды чамадан.
Авылыма кайтсам,
Дусларымны тапсам,
Яши башлармын күк яңадан.

Чаба поезд, чаба
Туган якка таба, –
Йөрәк ярсый, күңел ашкына.
Әйтерсең лә бүген,
Ак каеннар түгел,
Балачагым чыккан каршыма.



Уфадан башта бер кочак хикәяләр килеп төште. Укыган берсен, ошатып, монысы – сайтка, монысы – журналга дип сайлый, бүлгәли дә башладык. Һәм иң элек яңа авторыбыз әсәрләрен сайт укучыларына тәкъдим иттек. Яраттылар! Ниндидер җылылык, шаянлык, рәхәтлек бөркелә, чып-чын хатын-кыз холкы чагыла ул хикәяләрдә, арада фэнтези, тарихи темаларга язылганнары да бар.

Прозаик, журналист, шагыйрә Миләүшә Каһарманова – Башкортстанның Бөрйән районы Яңа Усман авылы кызы. Чиләбе өлкәсендә туган, Бөрйәндә үскән. Башкорт дәүләт университетын тәмамлаган. «Вечерняя Уфа» газетасында эшләгән. Бүгенге көндә ул «Һәнәк» журналында баш мөхәррир вазыйфаларын башкара. Ә «Сөембикә» журналында Миләүшә Каһармpraнованың дебюты бүген.



Миләүшә
КАҺАРМАНОВА

КӨНДӘШЛӘР

(хикәя)

Ике гасырдан артык утырып, яртылаш җиргә сеңгән таш келәт бүген дә хуҗаларына хезмәт итә. Анда һаман да дөньялыкта кирәкле булган мал-мөлкәтне, кулланылудан чыгып та, ташларга ярамаган иске нәрсәләрне саклыйлар. Төп йортка кайтып төшкән һәрберсе, аннан кала, бу затка бәйләнеше булган туган-тумача берәр җаен табып, монда кереп чыгуны әллә ни күрә. Үзе бер музей булган келәттә, чынлап та, нәрсә генә юк?! Ә асылда һәрберсе шунда – агач киштәләрнең иң түрендә утырган җиз самавырны – ыру тарихында яшәгән гыйбрәтле вә соклангыч риваятьнең бердәнбер тере шаһитын күреп калырга керә. Җиз самавыр, үз дәверен яшәп үткәргән, бер колагы өзелеп чыккач, кабаттан эретеп ябыштырылган, кайчандыр ялтыр булган йөзе дә тоныкланып калган, урыны-урыны белән тут алган ядкарь, килүчеләргә дә, озак текәлеп торучыларга да, сыйпап-сыпырып караучыларга да илтифатсыз гына утыра бирә. Монда түгел аның уйлары да, җаны да, бу заманның әлеге көнендә аның тик шушы боек гәүдәсе генә тора. Ә күңеле аның теге заманда – бәхетле дә, михнәтле дә үз дәверендә. Сөләйманы янында, Канифәсе белән Кинҗәбикәсе түрендә...

Иренең икенче хатын алырга ниятләвен ишеткән Канифәнең кулыннан сөтле чиләге төшеп китә язды. Чиләк тоткасын тотып калса да, агы ярыйсы чайпалып, итәген чылатты. Башыннан яшен тизлеге белән «Нигә? Ни өчен?» дигән сораулар үтсә дә, бичә асылы алдарак бәреп чыкты:

– Кемне?

Шулай диде дә телен тешләде. Бу сорау үзе үк ризалык билгесе иде. «Нәрсәгә сиңа икенче хатын?» дип чәрелдәп елап яки һичьюгы аркылы төшеп карышу урынына... кызыксынып тора. Кызыксынды да шул. Сөләйманы, яшьли генә ярәшкән, җандай күргән ире, аның янына кемне тиң итеп куя ала икәнне белергә теләве бөтен башка уй-теләк-хисләрен таптап алга йөгереп үткән дә киткән иде шул.

– Гаделгәрәй агайның Кинҗәбикәсен.

– Кин... җә-бикәне?..

– Әйе, – ир хатынының югалып калган, хәтта купшы авызы ачылып киткән сылу йөзенә төбәлеп карады да, өстәп куйды, – синең ризалыксыз түгел инде.

– Ә-ә-ә... – Канифә аны ишетмәгән кебек өйгә атлады. Иренә аңлаешлы итеп нидер әйтер дә, киңәшләшер хәлдә дә түгел иде хатын.

Алдагы көннәрдә дә иренең ниятенә каршы чыгар сүз дә, дәлил дә тапмады Канифә. Аны телсез һәм чарасыз иткәне – уртак балалары юк. Укымышлы, абруйлы, хәлле Сөләйманга – якынтирәдә бердәй булган, көрәшләрдә бил бирмәгән, кирәк җирдә сүз дә әйтә, эшен дә башкара белгән мәртәбәле, гайрәтле иргә дүрт хатын алганда да гөнаһ түгел икәнен дә аңлый. Заманында үзе дә бит, кайдадыр Зәйнулла ишан мәдрәсәсендә укып кайткан бу сөлек кебек белемле егеткә бер күрүдә гашыйк булды. Сөләйман да аның нечкә сынын, шомырт кара күзләренең иркә карашын,

йөзен ача биреп яшерен елмаеп үтүләрен сизмәде түгел. Чибәр кызның уңай карашын сиземләде дә, яучылап, алып та куйды. Бер көн дә үкенгәне юк шуннан алып. Ире иркәләп-сөеп, саклап-тәрбияләп кенә тора. Үзе дә аны, бер көн күрмәсә дә, сагынып өлгерә. Яшәүләренә җиде елдан артса да, аралары һаман да кайнар әле. Барысы да бар, бөтен нәрсә җитеш кебек. Тик нигәдер балага гына уза алмый. Шунлыктан, иренең икенче хатын дип авыз ачканын да кире кагар хокукы юк. Әмма йөрәген үтә дә яндырган бер нәрсә бар монда. Ире күз салган кыз – авылда бер дигән чибәркәй. Уртача гына көн иткән Гаделгәрәйнең иркә Кинҗәбикәсе. Үткәндә елгада кер чайкаганда гына кызлар арасында сылулыгы, нәфислеге һәм әллә нинди бер илһамлы терелеге белән аерылып торган кыз баланы: «Бу, ни, җиткән икән, кем бәхетенә үскәндер», – дип күзәтә биреп торган иде. Ә ул менә кем бәхетенә булмакчы! Димәк, Сөләйман да күреп-шәйләп йөргән сылукайны... Шушы уйларыннан үзалдына үзе кабынып янып киткәндәй була Канифә. Бар син, бүлешеп кара иреңне!

Бүлеште... Олы хатын буларак, тарантаста ире белән парлап утырып барып, кыз йортында никах укытып, мәһәр салып, аяк астына ак мендәрләр ташлап каршы алып, башлап йөреп ихата эчендәге бәләкәй өйгә күчерешеп, урнаштырышып бирде әле. Йола кушканның барысын да үтәде. Артык түшәлеп тә китмәде, әмма ирен кимсетерлек, аның күңеленә хуш килмәслек бер караш, бер ым да күрсәтмәде. Ире куенына яшь кәләш алган төнне түгелеп елап үткәрсә дә, ул иртәнге чәйгә зур йортка килеп кергәндә, өстәл ашъяулыгына тәгам-ризыгын тезеп чәйгә көтә иде инде.

Сөләйман, бернәрсә дә булмагандай, аяк чалып каршыга утырды да, нидер дип сүз башламакчы иде, олы хатынының кызарып шешенгән йөзен шәйләп алды.

– Ни булды сиңа, Канифә?

Канифә, эндәшмәстән, үҗәтләнеп чәй ясый иде дә соң, сатлыкҗан яшьләре «чуп-чуп» итеп касәсенә тамды.

– Йә-йә... – иренең шушы йомшак сүзе таман гына булды, хатын кулбашына салган сөлгесе белән битен каплап шыңшып җибәрде. Ахырда, Сөләйман торып килеп, хатыны янына утырды. Иңбашыннан сөйде. Алай да тынычланмагач, кечкенә бала шикелле итеп күтәреп алып алдына утыртты да, күкрәгенә кысты:

– Елама, Канифәм... Син минем монда, йөрәгемдә генәсең. Елама, матурым... Синең өчен берни дә үзгәрмәячәк. Йә, алайтмә... Син бит акыллы хатын.

Ярсуы басылып, тынычлангач, иренең түшенә сарылып утыра бирде Канифә. Тик артык онытыла алмады. Сизгер борыны иренең иңбашы, муен тирәсендә ят исне тойды. Әчкелтем-ширбәтле бер хуш ис иде ул. Чит хатын исе...

– Мин чәйне кайнарлатам. Бар син теге... көндәшемне алып кер...

Шулай итеп, тыныч кына яшәп киттеләр. Моңача ничә буын ата-бабалар шулай гомер иткәнне бер Канифә генә үзгәртә алмый иде.

Сөләйман әйткән сүзендә торды. Яшь хатыны булса да, Канифәсенә карашын үзгәртмәде. Элеккечә калды. Шаштырып-очындырып та җибәрми, тезгенне каты гына тота, әмма иркә-назга сусатмый, игътибарсыз да калдырмый иде. Киңәшләшергә дә һәрвакыттагыча аны чакыра, табын артында да гаилә мәсьәләләрен аңа төбәп аңлата, күрсәтмәләрне, боерык-әмерләрне дә аның җаваплылыгына сала. Ә иркә Кинҗәбикәгә балага караган кебегрәк көлемсерәп карый. Тегесе инде шундук башларын кыйшайтып назланып китә, керфекләрен төшереп җибәргән була. Сизми каламы инде Канифә? Әмма сер бирми. Ире алдында бу тәтәй курчактан күпкә мөһимрәк, дәрәҗәсе югарырак икәнне белдереп, әңгәмәне дәвам итә:

– Ярый, шулайтербез. Әйткәнеңчә әзерләп куярмын барысын да.

Сөләйман да аның бәһасен төшермәскә икәнне белә. Карашына ясалма җитдилек биреп, яшь хатынына катырак эндәшкән була:

– Олы көндәшеңне тыңла. Кушканнарын төгәл үтә.

Тегесе, көндәшенә сиздермәстән, күз кырые белән генә шаян караш ата:

– Йә.

Шәһәр базарында ашлык, агач сатып, сәүдә итеп, атна ятып кайткан ирне хатыннары тәрәзәдән тәрәзәгә йөреп көтеп алды. Кая барганда да бүләксез кайтмасына өйрәнгән, аннан бигрәк, үзара да бүлешәселәре килмәгән ирләренең читтә тагын берәрсенә күз салып куюыннан курkып борчылган хатыннарның күңеле тыныч түгел. Һәрберсе үз йортында утырса да, күзләре – зур урам капкасында.

Алты почмаклы өй тәңгәленә якынлашып килгән пар атлар җигелгән тарантасны ялчы булып йөргән үсмер егет капка ачып каршы алып тора. Ике хатын ике яктан чыгып баскан. Олысы сабыр булырга тырышып, шәле белән түшен капшый. Яше талпынып очардай булып боргалана.

Сөләйман бер бәйләмне – бер хатынына, икенче төенчекне икенче хатынына тоттырды, бер төргәкне – берсенә, икенчене икенчесенә сузды. Шулай итеп, арбасындагын таратып бетереп барганда, төргәкләр астыннан һуш китәрлек ялтыр самавыр килеп чыкты. Хатыннары «аһ!» итеп калды.

– Самавыр алдым бит мин сезгә! – ир бу купшы бүләкне алып өскә күтәрде. – Карагыз, нинди шәп! Күрдем дә, бу нәрсәне, хакына карамый, бичәкәйләремә алып кайтыйм әле дидем, – дип кулын аска төшерүе булды, ике хатын ике яктан самавырның колакларын эләктереп тә алды. Берсе бер якка тартты. Икенчесе – үзенә. Өлкәне дәрәҗәсен белеп, кинәт тартып, йолкып алмакчы иде, яше, җиңәргә тырышып, ике куллап чат ябышты. Бахыр самавыр аптыраган ирнең күз алдында әле бу, әле теге якка чайкалды. Бичәләрне туктатырлык түгел иде, алар әр-тавышсыз гына самавырны тарткалый торгач, аның бер колагы аерылып китте дә, Кинҗәбикә самавыр кочаклап артына ауды. Шул вакыт ирнең дә югалып калуын ачу алыштырды:

– Ы-ых! Албастылар! – аның кулындагы камчы һавада сызгыруга, бичәләре ике якка торып качты. Бары сыңар колаклы җиз самавыр гына чирәме кибә башлаган ихатада аунап калды. Баягы киштәдә утырган җиз самавырның



бу гаиләгә килеп кергән көне иде бу. Канифә белән Кинҗәбикәгә бүләк булып килгән көне. Самавыр тарихының башланган көне...

Кинҗәбикә кыз бала тапкач, Канифә сер бирмим дисә дә, шул бәләкәй өйгә тартылды да торды. Ахырда көндәшен бишеге-ние белән олы йортка күчереп алды, анысы хәзер үз өенә йокларга гына чыгып йөри башлады. Яшь хатын баланы карап җиткерми кебек тоелды олысына. Шуңа бәбине күбрәк үзе бакты. Урындык түрендәге көймәле бишектән чак кына өн чыкканда да көндәшеннән алда ул барып җитте һәм тиз генә баланы алып такмаклый да башлады:

– Ә-әй, безнең Сәлимәкәй уянган бит... Безнең алтын балабыз да соң! Безнең купшыкаебыз...

Көндәшенең икенче кызына кендек әби дә булып куйды Канифә. Анысын да биләүләп-тирбәтеп, сылап-сыйпап үстереп баралар иде, йә Ходай (!) үзе авырга калды...

– Көндәшем, – диде ул кызчыкларны мунча кертеп алып чыгып, майлап-биләүләп утырган бер кичне, – әллә мин йөкле инде...

Бәләкәчен имезергә дип сыңар түшен чыгарган Кинҗәбикә, баласына имчәген каптырырга онытып, аңа төбәлде:

– Әстәгый! – аннан төзәтә куйды. – Әлхәмделилләһ!

Канифә кыюсыз гына дәвам итте:

– Нигә бу билем ката да куя, дисәм... Эчем дә үскән сыман. Син берәр нәрсә сизмисеңме миндә?

– Сизәм дә ул. Әле мунчада да дәшәргә уйладым да, йә ошатмассың, дидем. – Кинҗәбикә күкрәгеннән сыгып чыгарган сөткә чәчрәп киткән сабыеның түбәсендәге йомшак җиренә өрде. Канифә аның бу бәбәй имезгән илаһи мәлен күзәтеп утырды да, хыялланып, әйтеп куйды:

– Бирсәче Ходай миңа да шундыйны...

Бирде. Бер-бер артлы өч кыз бирде аңа да Ходай. Берничә елдан биш кызның чыр-чуыннан йорт кына түгел, ихата гүләп торды. Бар иде шәп чаклар! Өй алдындагы чирәмдә ашъяулык җәеп җибәреп ризыкланган, түшәкләрдә балаларны аунатып уйнаткан, түрдәге асыл ирне ике яктан сылап-сыйпап сыйлаган, эретеп ябыштырылганнан соң бер колагы чак кына кәкрерәк күренгән ялтыр җиз самавырны пар бөркетеп җырлаткан, дөнья хәл-әхвәлләрен дустанә сөйләшеп көн иткән чаклары... бар иде.

Уйламаган җирдән буталыш китте. Илгә басып кереп, таптап килгән яңа хакимлек – Совет власте, аларның ирен кабул итмәде. Аларның, типсә тимер өзәрдәй, бер учы белән куй муенын сындырырдай көчле, Коръәнне яттан белгән укымышлы, зур шәһәрләрдә урыс-мишәр белән сәүдә итә алган асыл ирләрен, тамаклары мәңге ашка туймаган, бер аршын җирне дә эш итеп тотына белмәгән, әлепне таяктан аермаган, моңача мәңге көнлекче булып йөргәннәр дошман итте. Дошман итеп кенә дә калмады, сөргенгә сөрделәр.

Язмышлары хәл ителеп, иртәгә озатылалар дигән кичне Сөләйманнарга бер егет белән урта яшьләрдәге ир килеп керде. Төенчекләрен төйнәү, кием-салым барлау белән булган хатыннарын чакырып алды Сөләйман.

– Шушы егеткә Сәлимәне биреп китәм. Бу – минем балалык дусым Абдрахман, Абдулла – аның улы, – диде.

Канифә авызын гына каплады, Кинҗәбикә еларга тотынды:

– 14 яшьлек баламны... Юк, калдырмыйк!

Тик Сөләйман бу эшне хәл иткән һәм кире уйлыйсы түгел иде:

– Кая алып китәрләрен дә белмибез. Кайда, нәрсә көтә? Ичмасам, бер балабыз монда калсын. Кызымны какмый-сукмый карармын, диде Абдрахман, мин аңа ышанам.

– Ни күрсәк тә, бергә күрер идек әле... – диде Кинҗәбикә чигенәсе килмичә дә, ире өзеп әйтте:

– Булды. Тәмам. Әзерләгез кызны, никахны үзем укыйм.

Ике хатын, зар елашып, өлкән балаларын җиде ят кешеләрнең чанасына утыртты да җибәрде. Төн карасында яшереп кенә кылынды бу эш. Ә иртәнчәккә аларның үзләрен ике чана итеп төяп алып чыгып киттеләр. Эт күрмәгәнне күреп, михнәт шулпалары эчә-эчә, ачыгып-туңып, ай буе йөрделәр юлда. Барып егылган җирләре Иркутск өлкәсенең бер калачыгы иде.

Кайгы-михнәттән болай да хәлсезләнгән хатыннарны тагын да аптыраткан аяусыз бер хәл көтә иде монда. Лагерь начальнигы Сөләйманга хатыннарының берсен аерырга кушты. «Совет властенда күп хатынлылык юк», – диде ул. Ир каушап калды. Хатыннарына алмаш-тилмәш бакты. Урысча аңламаган тегеләре бер ноктага карап тора бирде. Аңлатып әйткән иде дә, һаман күзләрен киң ачып төбәлеп торуларын дәвам иттеләр. Бу хәбәр аларның башларына да, аңнарына да сыймый иде! Ахырда начальник иртәгәгә кадәр мәсьәләне хәл итәргә кушып, барысын бергә кыйгайган иске йортка кертте.

Күптән хуҗасыз торган өйне җыештырып, мичен төтәтә-төтәтә ягып, балаларның тамагын ялгатып алгач, хатыннар ирләре янына килеп утырды. Өчесе дә үзалдына төбәлеп тынып калды. Күпмедер вакыттан соң Канифә телгә килде:

– Мине аер, Сөләйман.

Сөләйман соңгы көннәрдә яртылаш картаеп калган, хәсрәтеннән каралып каткан йөзен күтәрде:

– Нишләп сине?

– Кинҗәбикә яшь. Аңа ялгыз авыр булачак...

– Син дә аннан җиде яшькә генә олы. Син дә бичә кеше.

– Мин бит катырак... Мин түзә алырмын ул.

Ир хатыннарына тагын да алмаш-тилмәш карап алды.

– Берегезне дә аермыйм. Сез минем хәләл бичәләрем.

Кинҗәбикә түгелеп елап ук җибәрде:

– Мин бер көн дә яши алмам синсез... Елгага төшәм дә батам...

– Чү! Юкны сөйләмә! Әнә, балаларны уятасың, – Канифә, усал шыбырдап, аны тыйды. Аннан иренә эндәште. – Нишлибез алайса?

– Сине икенче җиргә күчерергә кирәк булыр, Канифә. Балалар монда калыр. Тик талаклап аермыйм. Син минем хатыным булып каласың һәм онытма, мин теге дөньяга китмичә, сиңа миннән ирек юк.

Аннан бу сөйләшүне Канифә йомгаклап куйды:



Рәсем: Наталья Васильева

– Ярый, Сөләйман, шулай булыр.

Сөләйман күмер шахтасында эшләде. Таң карасыннан китте, төн җиткәч, хәлсез булып, тешләрен елтыратып кайтып керде. Кинҗәбикәне урам себерүче итеп куйдылар. Кызлар аңа ярдәмләшеп янында йөрде. Канифәне шәһәрнең икенче очындагы хатын-кызлар барагына алып барып тыктылар. Ул тимер юллары сакчысы булып китте. Ял туры килү белән көндәше, балалары янына йөгерде, әллә нигә бер – тансыкка гына ирен дә туры китерде. Сагынышып күрештеләр, җан өзешеп, аерылыштылар. Бер мәлгә генә теге җиз самавыр тирәли җыелдылар да тагын бүленешеп киттеләр. Шулай елдан артык яшәгәч, Канифә авырга калды. Инде хәлне яшереп булмый башлагач, Сөләйман аны җитәкләп алып әлеге начальникка керде.

– Иптәш начальник, хатыным төнге каравылда йөрерлек хәлдә түгел. Зинһар, аны минем яныма кире кайтарыгыз, – диде.

Начальник берчә инде корсагы бүлтәеп чыккан хатынга, берчә иргә бакты:

– Син бу хатынны аерган идең түгелме соң?

– Мин аеру беләнмени... Аллаһы Тәгалә аермагач, – дип әйтте дә куйды Сөләйман.

Кулындагы тәмәкесен борхытып, ни дип җавапларга белмәде начальник та. Бу мәсьәләдә ул да көчсез иде.

– Нишләтәсең... Аласың инде кире. Бу хәлдә синең хатының кемгә кирәк?

Кайтып җиткәнче иренең беләгенә асылынып, сөенеченнән елый-көлә килде Канифә. Ә өйдә аны зык кубып көндәше белән кызлары каршы алды. Ике бичәсенең кочаклашып елашканнарын күреп, Сөләйманның да күзләренә яшь тулды.

Бәла тагын да көтмәгәндә килде хатыннарга. Беркөн Сөләйман киткән җиреннән кайтмады. Икенче көнне Канифә белән Кинҗәбикә кара таңнан урамда торалар иде инде. Алар кебек ирләрен көтеп ала алмый сагаеп завод юлын күзәткән хатын-кыз да аз түгел. Ике көнлек билгесезлектән соң шахта җимерелгән дә эшчеләрен баскан дигән дәшһәтле хәбәр таралды. Көндәшләр бу яңалыкны кабул итмәде. Аларның пәһлеван ирләренә нидер булуы мөмкин түгел иде. Бернидән дә курыкмаган, хәтта әллә нинди начальникларның да йөзенә туры карап сөйләшә алган, берүзе биш кешенең нормасын үтәп йөргән ирләренә ни булсын?.. Җитәр-җитмәс кенә ашларын кырык җылытып, ирләренең алмаш кием-салымын кырык тотып карап-салып, ни утырып ашый, ни йоклый алмый йөрешкәндә, Сөләйманның алыптай гәүдәсен кертеп, идән уртасына сузып салып киттеләр...

Канифә ирен ничек итеп җирләгәнен дә, ничек җеназалар укытып-тәрбияләп куйганын да яхшылап



хәтерләми. Бөтен бу мәшәкатьләрне үзе оештырса да, нечкә генә иңнәрендә күтәреп чыкса да, аңы томаланган хәлдә башкарган иде. Ә Кинҗәбикә кисеп аударган кебек Сөләйманның өстенә егылган булса, шуннан тора алмый ятты да калды. Аяклары тыңламас булды хатынның. Шулай итеп, Канифә кулындагы дүрт кыз бала, 3 яшьлек кенә улы һәм түшәктә яткан көндәше белән торып калды.

Әмма афәт ялгыз килмәгән булып чыкты. Шул яз шәһәрдә көчле кызылча чире таралып, бер-бер артлы кызларның икесен алып китте. Бердәнбер уллары, салкын тидерүдән мантый алмый, сызылып кына җан бирде.

– Әй Ходаем... Сөләйманыбызның төс кенәсен калдыр инде... Алма инде, Ходаем, улыбызны... – дип баланың ике ягында шыңшыган хатыннарның зарын нишләптер ишетмәде күктәге. Алай дисәң, ил буенча андый зар булганнар аз түгел иде шул ул заманда.

Тагын ике елдан Канифәгә ярлыкау килде. Гаебе акланган булып чыктымы? Һәрхәлдә, хатын үзенең һәм, гомумән, аларның һәм үзләре кебек шушында михнәт чиккән меңәрләгән халыкның нәрсәдә гаепле икәнен дә төшенә алмый иде ул. Шулай да аңа кайтырга рөхсәт булды. Аякка басып эшләп йөргән Кинҗәбикәгә бу кәгазь юк иде әле. Хатыннар утырып киңәшләштеләр дә, Канифә булган акчаларын төйнәп тотып, ике кызын ияртеп юлга чыкты. Ә Кинҗәбикә, буылып елап, поезд артыннан йөгерә торгач, сөрлегеп, егылып ятып калды...

Сәлимә кызлары килен булган йортка кайтып төште Канифәләр. Сөләйманның балалык дусты булган Абдрахман аларны бер почмакка сыендырды. Сәлимәләре Кинҗәбикә кебек сылу хатын рәвешенә кереп, туптай ике бала анасы булып яшәп ята иде. Аңа карап бер сөенде, тегендә калган көндәшен уйлап бер көенде хатын. Тик берни эшләр чарасы юк.

Кайткач та колхозга эшкә чыкты. Үсмер кызлары да кул астына керде. Җайлап, сәманнән өй салдылар. Савым кәҗәсе сатып алдылар. Тиенләп акча җыйдылар. Аларның нәрсәгә җыйганнарын белгән Абдрахман да, кияүләре Абдулла да хәлләреннән килгәнчә кушылды. Тагын ике ел дигәндә, ярыйсы хак җыелып, Кинҗәбикәгә җибәрелде. Ул бу акчага «вульный» кәгазе сатып алып, көндәше иптәшкә дип калдырган җиз самавырны кочаклап, канатланып кайту ягына очты. Тагын ничәдер көннән көндәшләр сәмән өй идәнендә бергәләп чәй эчә, Сөләйманнарын искә алып, хатирәләрен яңартып, елашып-җырлашып, сөйләшеп туя алмыйлар иде.

Яшь үк булмасалар да, олы да түгел иде әле хатыннар. Икесе дә төс ташламаган. Язмышларына үч иткән шикелле, һаман сылулыкларын да, йөз-төс нәфислекләрен дә саклаган иделәр. Күз карашларында да очкын, чәм бар. Өзә басып, очкын салып йөриләр әле. Кайбер ирләр, уфтанып: «Хатын сайлый белгән бит бу Сөләйман», – дип, юкка гына әйтеп куймый иде шул...

Җил капкаларын яучылар да аз какмады. Бигрәк тә Кинҗәбикәне соратты бер адәм. Өзмәде дә куймады. Тамчы тама-тама таш тишә дигәндәй, димче әби Канифәне дә көндәшен үгетләргә күндерде.

– Көндәшем, икәүләшеп утырып картаймыйк инде. Яхшы гына ир сората, дөньясы төгәл... Кызлар минем белән калыр, күрше авыл гына, килеп йөрерсең, – дип әйтә-әйтә ризалатып куйды. Теге ир, беркөн килеп, арбасына төяп алып китте Кинҗәбикәне. Йөрәгеннән әллә нәрсәсен өзеп биреп җибәргәндәй булса да, шулай кирәк, яшәү дәвам итә дип уйлап юанды Канифә. Икесенең берсе бәхетле була алырга тиештер инде.

Ай чамасы үткәч, таң алдыннан хатынның ишеген сак кына кемдер какты. Канифә ишек ярыгына авызын терәп шыбырдады:

– Кем ул?

Тыштан җавап юк.

– Кем, дим? Хәзер уклау тотып чыгам!

– Мин, көндәшем, ач. – Келәне күтәреп җибәрсә, тупсада Кинҗәбикә утыра. Канифә аның янына чүгәләде:

– Ни булды? Нишләп болай?

Кинҗәбикә аңа карамый гына авыр көрсенде:

– Кайттым... менә. Яши алмыйм аның белән. Җаным да, тәнем дә тартмый... Кума мине. Күз алдымда Сөләйман тик тора... Аның кебеге юк та, булмас та.

Хатыннар тынып калды. Сызылып таң атып килә иде.

– Сөләйман мине кичерә алыр микән?.. Ничек уйлыйсың? – утыра торгач, шундый сорау бирде Кинҗәбикә.

Канифә башын борып, аның кызарган йөзенә бакты. Юл буена тыела алмый елап килгәндер инде. Елак кына бит аның яшь көндәше.

– Кичерер, нигә кичермәсен. Бу дөньяда кичерми торган хәл юк... – аннан, тегесенең чыланып, чигәсенә ябышкан чәчләрен сыпырып куйды да елмаеп өстәде, – үзем сөйләшермен Сөләйман белән, мин үгетләп башын бутадым, кичерә күр безне, дип әйтермен.

Кинҗәбикә олы көндәшенең иңенә терәлде.

...Канифә белән Кинҗәбикә әбине авылда күпләр апалы-сеңелле дип уйлады. Алар язмышын белмәгән яшь буын, гомер буе бергә яшәгән, бөтен җиргә дә парлашып йөргән бу ике карчыкны бер-берсенә нәрсә бәйләгәнен дә төшенмәде. Кызларыннан таралган буыннар чылбырында да алар тарихы бер риваять кенә булып калды. Онык-туруннары кайчак кем кемнең картәнисе икәнлекне ачыкламакчы булып сорашканда да, карчыклар өзеп кенә җавап бирмәде.

– Картәниегез кемебез булганда да, картәтиегез Сөләйман иде. Дөньяда бер дигән ир иде!

– И-ий, безнең Сөләйман ул нинди иде! Килеп керсә, түбәсе өрлеккә тиеп торыр иде...

– Икебезне ике беләгенә утыртып күтәреп алыр иде...

– Аның кебек азаматлар юк шул хәзер...

– Э-эй, безнең Сөләйман иде... мирдә берәү иде...

...Шуларның барысын да хәтерли җиз самавыр. Бернәрсәсен дә, бер көнен дә, бер генә мәлен дә онытмаган. Җиде ят җирләр куенында ятып калган Сөләйманын, мондагы зиратта янәшә генә җирләнгән көндәшләрен сагына... Асылда, таш келәттә аның коры гәүдәсе генә тоткын булып утыра. Ә җаны күптән икенче дөньядагы, бәхетле дөньядагы хуҗалары янында.



Айдар
ХӘЛИМ

Шагыйрь, язучы, драматург, журналист, күренекле җәмәгать эшлеклесе Айдар Хәлим турында «җан тетрәндерерлек, җан җылытырлык әсәрләр тудыручы», диләр. Һәм нинди генә жанрда иҗат итсә дә, ул шагыйрь булып кала. «Мин әдәбиятка шагыйрь булып килеп кердем һәм гомер буе төп хезмәтем шагыйрьлек булды», – ди ул үзе турында. Саҗидә Сөләйманова аны җир һәм күкләр масштабында фикер йөртә, дип бәяли. Прозасы да, публицистикасы да җаннарны шигырь кебек айкый. Айдар Хәлим диюгә, «Өч аяклы ат», «Татар вакыты», «Татар моңы», «Хунвейбин», «Кыйбла», «Казыктагы тальян»нары искә төшә... Барысы да әдәбиятыбыз тарихына кереп калырлык әсәрләр. Бу көннәрдә үзенең 80 яшьлек юбилеен билгеләп үтүче Айдар абый Хәлимне гомер бәйрәме белән котлыйбыз! Матур иҗаты белән халкыбызны сөендереп торсын! Бүген исә аның кечкенә новеллаларын тәкъдим итәбез.

Мәгъшук

Башкортстан Үзәк китапханәсенең библиография бүлегенең уку залына бик укымышлы бер яһүд карты йөри. Лео Натанович Мищевский. Аңа 86 яшь. Ул анда сәгатьләр буе китап укый, сирәк басмаларны актара. Без беләбез: китаплар аңа никадәр генә якын булмасын, алар бары сәбәп кенә. Төп сәбәп – бүлек китапханәчесе Илирә ханымда. Ул аңа үлепләр дә гашыйк. Аларның яшь аралары әллә ни «күп тә» түгел: 46 гына ел. Нишлисең, мәхәббәт алдында картлыгы да, яшьлеге дә кулларын күтәрә.

– Лео Натанович, сезгә яһүдә апалар беткәнмени? – дип сораганнар кызлар бер тапкыр аннан.

– Бетмәгән, – дип җавап биргән барлык җитдилеге белән Лео Натанович. – Белмәсәгез, белегез: дөньяда иң бөек хатыннар – татар хатыннары... Мин бит татар кияве. Минем вафат булган хатыным да татар иде...

Менә ни өчен 86 яшь өстендәге Лео Натанович, бәйрәмнәр җитсә, өендә утырып, Илирәгә затлы-татлы котлаулар сырлый, аннан шакмаклы тукыма капчыгына катыргы савытлы конфет салып, китапханәгә юнәлә. Кызлар аны мондый тантаналы очракларда китапханә чарлагындагы күгәрчен оясына алып менеп, чәй дә эчерәләр. Күп сөйләнми мәгъшук. Ул бары тик Илирәгә карап кына утыра да, керфек очына шатлык яше элеп, шакмаклы капчыгын җилфердәтә-җилфердәтә өенә кайтып китә.

Кызлар, әлбәттә, картның мондый юләрлегеннән шырык-шырык көләләр. Әмма үзе юкта гына. Үзе булганда – ләм-мим. Үзе булганда – Илирә һәм Лео Натановичны бер җан итеп зурлыйлар. «Җизни, җизни!» – дип янында сикергәләп йөриләр.

Менә бүген дә Лео Натанович Илирәсенә хат язып китергән. Чын интеллигент, яһүд интеллигенты буларак, өч телдә язган: татар, иврит һәм француз телләрендә. «Нигә урыс телендә язмадыгыз?» – дигән сорауга ул бик җитди итеп «Оныткanмын», – дип кенә җавап бирә.

Илирә ханым хатны университетның чит телләр факультеты укытучыларыннан иврит һәм француз телләреннән тәрҗемә иттерде. Татарчасы белән тәңгәл булып чыкмады хатлар. Ай-һай, зур иде алардагы мәгънә аермалары. Татарчасында ул бары тик тәүфыйклы песи булып кыланса, теге хатларында, аеруча францучасында – чып-чын шайтан иде.

Менә нәрсә язган иде бит ул хатларында:

«Сөекле мадемуазель Илирә Мәкъсүтовна! Сезнең белән якын араларда берәр аулак кына урында очрашасым, яшьлегемә кайтасым килә. Моның өчен Сездән бер генә аваз, бер генә телефон чылтырамасы да җитә. Түземсезлек белән көтәм. Синең – Лео Натанович».

Прыйнцыйпсыз кабак

Зәйтүнә бакча сатып алды. Кечкенә йорты да бар. Күршесе Исраилнең дә, үзе кебек, тол икәнен белде.

Эшли Исраил бакчасында, көне-төне эшли. Зәйтүнә дә эшли, әмма ул күбрәк каш астыннан Исраилне күзәтә биреп эшли. Ошый аңа бу ир. Алар аңа бер-берсенә пар килгән кебек күренәләр, тот та никах укыт: болардан да бәхетлерәкләр булмас, билләһи!.. Кыскасы, күз салды Зәйтүнә күршесенә. Тик карамый аңа күршесе. Әллә үзе шундый йомык, әллә йөрәге сүнгән. Исраил күз карашы белән шул җансыз көрәгенә кадалып ала да, тере әрвах сыман, аңа игътибар да итми: эшли дә эшли. Янында әллә бер кашык су белән йотарлык хатын, әллә туң бүрәнә йөреп ята!..

Тагын шунысы кызык: Зәйтүнә дә, Исраил да кабак ярата булып чыкты. Әмма хатынның кабагы, менә өченче ел инде орлыктан тишелеп чыгып, бер-ике буынга сикерә дә, чәчкә дә атмыйча кибә дә корый, корый да кибә. Ә Исраилнең кабаклары биш чатлы сары йолдыз булып чәчкә атып утыра да, кочакка да сыймаслык алтын казан булып саргая...

Әйе, менә ел да кабак чәчеп, Исраил белән Зәйтүнә ял көннәрендә генә күрешә салып, бер-берсе белән «Исәнмесез-саумысыз!»дан ары узмыйча, ут күршеләр булып яшәп яталар. Хатын ирнең игътибарын җәлеп итәр өчен, кайчагында үтә күренмәле челтәрле коймага килеп, үрмәле гөл



кебек сырпалана да, күршесе анда да карашын куе каш асларыннан күтәрмәгәч, көянтәләрен асып, бөгелә-сыгыла, ерактагы чишмәгә суга китә. Юк, бу Мыштымгали бәгыренә ут кабарлык эсседә дә «Су эчермәссез микән?» дип сорамый. Җебегән авыз, таш маңгай!..

Быел Исраилнең бер кабак үрентесе, тимер челтәр аша шуышып чыгып, Зәйтүнә территориясендә «йомырка салды». Хатын теге бакчаның аргы башыннан бу бакчаның бирге башына юлланган кабакка сулар сипте, һич арттырмыйча әйткәндә, аны бала кебек иркәләп үстерде. Зәйтүнәнең кабакка өметләре зурдан иде. Менә көз җитәр, күршесе, учма чәчләрен сыдырып ташлап, бәләкәй арбасын тартып, аңа кабагын алырга керер. У-у, менә анда сөйләшә белер Зәйтүнә!.. Шундук танышып китәрләр. Бәлки, Исраил аны тәрәзәләре зәңгәр капкачлы җыйнак кына өенә дә чакырыр, чөкердәшеп чәй дә эчәрләр...

Көтте бу көнне Зәйтүнә, кияү көткән кәләш кебек көтте. Ул Исраил өчен тәмле ашлар, гайрәтле эчемлекләр, иркә сүзләр хәстәрләде. Планнар корды.

Алтын сентябрьнең алтын бер көнендә Зәйтүнә бакчасында алтын булып кабак өлгергән мәлдә Исраил бакчасында сары чыпчык кебек сары күлмәкле хатын пәйда булды. Ул Исраил бакчасындагы кабак сабагы буйлап килде-килде дә, үтә күренмәле челтәр каршына туктады һәм Зәйтүнә бакчасы башында алтын казан кебек агарып яткан кабакны күреп, кычкырып җибәрде:

– Исраилкәем! Әнә, синең кабакларың кайларда ята! Алып чыгаеммы?

Исраил нәрсәдер мыгырданды – ишетелмәде. Зәйтүнә тын алырга өлгермәде, ике тәгәрмәчле күн калтырчасын җилтерәтеп, Сары Сандугач килеп тә керде:

– Исәнмесез!..

– Исән-ме-се...з... – диде Зәйтүнә авыз чите белән генә.

– Кабакларын әйтер идем!.. Нәкъ тавыклар кебек күршегә күкәй салалар!.. – Сары Сандугач аңа-моңа карамыйча елмайды, аннан кабакны шартлатып тамырыннан өзде һәм мизгел эчендә күн калтырчага салып та куйды. – Нинди зур! Су сибеп үстергәннәр диярсең!

Сары Сандугач капкага юнәлде.

Зәйтүнәнең елыйсы килеп китте.

– Үстергән идек шул!.. – диде ул ишетелерлек итеп. – Су сибеп үстергән идек!..

Урамнан калтырчаның чикылдап тәгәрәгәне ишетелде.

– Шар күз!.. – диде үрсәләнеп Зәйтүнә. – Тамагыңа тормасмы!..

Керде дә мендәренә капланды.

Җилтәрзә аша Исраилнең тавышы ишетелде:

– Юк белән йөрисең, сеңлем... Күрше хакы дигән нәрсә бар... Бар, кире кертеп бир...

«Сеңлем» сүзен ишеткәч, Зәйтүнә елавыннан шып туктады.

– Бирмим! – диде Сары Сандугач. – Эш, абый, күршедә түгел, прынцыпта! Прынцыпта, аңлыйсыңмы?.. Ул мәхәббәтсез кабак аңарга безнең бакчадан сикергән бит!..

Мирзанов әфәнде

Мирзанов. Нияз иде аның исеме. Әтисе – 20–30 нчы елларның шактый танылган шагыйре Бәхтияр Мирзанов.

Нияз агай – безнең Уралсиб дигән нефть кудыру оешмасының юристы. Бик ачык, яратып сөйләшә торган кеше.

– Әти 41 яшьтә үлде. Сәяси яктан бер дә юнәлеше булмаган. Ташкындагы юнычкы сыман төрле тарафка ташланган... – дип сөйләде ул миңа, атасына бернинди ташлама ясамыйча коридор башындагы ышыкта тәмәке тартканда. – Аңа карап, тормышымны мин дә юньләрәтле кора алмадым. Ул башта укыткан. Аннан рабнабор буенча авыл хуҗалыгы институтын тәмамлаган. Ленинградта аспирантурада укыган. Мин исә 1942 елда авиатехникумны тәмамлап, 1947 елга кадәр армиядә хезмәт иттем. Стәрлетамакта йортыбыз бар иде. Өйне 50 меңгә саттык та, әни, апа һәм мин Ташкентка чыгып сыздык. Анда килгәч, акча реформасы булып, безнең 50 меңебез чәйлеккә торып калды. Фатир юк. Эш юк. Кая барсам, куалар. Өйләнәм маржага. Аны 6 яшьлек малаем белән ташлап китәм. Стәрлетамакка кайтып, яңадан өйләнәм...

Моннан ике ай чамасы элек булыр – ишектә кыңгырау. Ачсам. Ике егет басып тора. «Я – ваш сын Валерий, – ди боларның берсе. – Тот самый, которого вы не видели 19 лет».

Миңа тамчы да охшамаган бу. Гомумән алганда, «минеке түгел». Малайның, ничектер, эченнән тышында чагыла торган җаны юк. Бер атна кунак булып, бер җылы сүз дә әйтмәде бу миңа. Кая ул «әти» дигән сүзне ишетү!..

Каян, ничек итеп мине тапкан, диген!

Исемә төшә. Моннан биш-алты ай элек безгә бер кыз кергән иде:

– Вы Мирзанов? – ди бу.

– Тот самый.

Һәм бернәрсә әйтмичә чыгып йөгерә. Мин – аның артыннан. Әле улым килгәннән һәм ул сөйләгәннән соң аңлашылды – ул Себердә хезмәт иткәндә танышканнар да, бу кыз, кайтып барышлый Уфа аша үтәм, дигән һәм, туктап, улым сөйләгән мәгълүматлар буенча мине справочный аша эзләп тапкан. Һәм адресны аңа җибәргән. Улым миннән ике генә сорау сорады:

– Син әнине яраттыңмы?

– Шулай дип уйла, – дидем.

– Ул чакта нигә аерылдың? Ул сөйләгән сәбәпләр хакмы?

– Шулай дип уйла, – дидем мин.

Ул бездә тормыш корып китә алмады. Менә шулай, туган, җиңелчә кавышу җиңелчәдән аерылуга, балаларның – атага, атаның балага җиңелчә каравына һәм бергә яшәү хакына илегә алмавына китерә...

Менә сиңа әфәнде! – дидем мин таң калып. – Әфәнде тәк, әфәнде!..

БУ ЯШЬЛӘРГӘ НИ ҖИТМИ?



Марат КӘБИРОВ, язучы

– Нәрсә җитми соң сезгә?!.

Бу сүзне безнең балалар бик еш ишетә торгандыр. Гадәттә, аны бераз шелтә белән кулланабыз. «Өстең бөтен, тамагың тук, нәрсә теләсәң – шул бар. Тагын ни җитми соң сиңа?» – дигән мәгънәдә. Кәеф булганда үзебезнең яшь чакны да искә төшереп китәбез. «Без сезнең кебек чакта... Ачлы-туклы килеш... Абыйлардан калган фуфайка белән... Бер караңгыдан икенчесенә...»

Чынлап та элекке белән чагыштырсаң, бүгенге яшьләр, нигездә, җитеш тормышта яши. Ләкин бу – чагыштырсаң гына шулай. Бүгенге яшьләрнең үз яшьлеге, үз ихтыяҗы.

Әлбәттә, күп нәрсә җитми аларга. Ә иң беренче чиратта, сабыйлыктан чыгу белән, өлкәннәрнең игътибары, аңлавы җитми. Кеше баласы турында сүз дә юк инде, без үз балаларыбызны да аңлый алмыйбыз. Заманы шул: кешенең дәрәҗәсе кесә калынлыгы, матди хәле белән бәяләнә. Ә без, адәм рәтенә керергә тырышып, шул мөлкәт артыннан чабабыз. Яшәр урын, ашар ризык кирәк, кием кирәк... Үзебезнең тормыш бераз җайлангач, балалар чиратка баса... Укытырга кирәк, затлы кием кирәк, айпад кирәк... Аннан, балаларга машина кирәк, фатир кирәк... Без, әлбәттә, яхшы кешеләр инде. Бөтен гомер буена шул балаларны кайгыртып яшибез, алар турында хәстәрлек күрәбез. Тик... балаларның үзләрен генә күрмибез... Баксаң, аларга бүтән берни дә түгел, ә нәкъ үз вакытында безнең: «Хәлең ничек, балам?» – диюебез кирәк булган икән...

Канат җитми аларга. Яшьлек беркадәр романтик булырга, йолдызларга карарга, хыял диңгезендә йөзәргә тиеш. Тормыш хыял артыннан бара. Башта оча торган келәмнәр булган, аннан самолетлар барлыкка килгән. Кешелек йолдызларга карап хыялланган һәм Гагаринны тудырган. Бүген әнә шул җитми. Яшьләр туганда ук җиргә карап туа. Хыяллары да җирдән, эстрада яки кино «йолдыз»ларыннан ерак китә алмый. Романтика, булган очракта да, ниндидер «прагматик романтика» ул.

Ә канаты булган яшьләргә иркенлек җитми. Канат җәеп, күтәрелеп китәр мөмкинлекләре юк. Мөмкинлекләрне беркемнең дә алдына алтын тәлинкә белән китереп куймыйлар, әлбәттә, аны һәркем үзе даулап ала. Алар да яулый алыр иде, тик бүген канатлыларның күтәрелүе беркемгә дә кирәк түгел. Әйтик, бүгенге чорның даһи бер егете су белән йөри торган автомобиль уйлап тапты ди. Аның бу ачышын күтәреп алырлар, иртәгәдән үк куллана башларлар дип уйлыйсызмы? Юк инде. Киресенчә, ачыш та, даһи үзе дә басымга дучар ителәчәк. Чөнки бу нефть һәм газга нигезләнгән җәмгыятьнең астын-өскә әйләндерә һәм күпләрне табышсыз калдыра. Нәтиҗәдә, егетнең даһилыгы аның бәхетсезлегенә әверелә.

Мәскәүдәге бер яңалыклар агентлыгы хуҗасы зарлана:

– Яшьләр үз эшләрен интернетка куялар да, күп тавыш җыйсалар, очынып китәләр: күтәрүне сорыйлар, яңа тәкъдимнәр белән күмәләр.

– Шулай булгач, яхшы ич инде, – дим. – Үсәләр. Танылалар.

– Ә безгә йолдызлар кирәкми. Без бары тик яңалыклар эшлибез.

Бу абзыйга синең талантың да, шәхес буларак үсүең дә, омтылышың да кирәкми. Аңа кушканны эшләп, биргәнгә канәгать була торган хезмәтче кирәк. Шундый хезмәтчеләр кадерле чак.

Ә яшьләрнең хезмәтче буласы килми. Аларның үз юлларын табып, үз эшләрен эшләп уңыш яулыйсы килә. Бу дөньяда үз эзләрен калдырасы килә. Әмма лабиринттагы тәҗрибә күсесе шикелле яктылыкка чыгу юлын таба алмыйлар.


Бүгенге яшьләргә, бигрәк тә талантлыларына, үз урынын табу күпкә кыенрак. Алар моны үзләре дә белә. Шуңа йолдызларга карамыйлар, зур хыяллар белән вакланмыйлар. Һәм аларны гаепләп тә булмый. Чөнки безнең буын аларга талантларны кадерсезли торган, канатлыларны сантыйга саный торган уртакуллар җәмгыяте, соры кешеләр диктатурасы калдырып китә.

ЗӨЛФӘТ ҺӘМ ФИРАЯ



Филисә ХӘКИМОВА

Шагыйрь... һәм Сакчы фәрештә! Шагыйрьләр өчен монысы, мөгаен, иң зур бәхеттер.



Шагыйрь Зөлфәт эзләреннән әнә шул ерак, урау юлларны урап килүем. Шул былбыллы чытырманлыклардан чыга алмыйча әле сокланып, әле адашып йөрүләрем. Гаҗәп инде, элгәре сулдан уңга «ерып» барам да чыгып җиттем дигәндә, борылып, тагын эчкә узам. Ә анда вакыт, тарих чоңгыллары, борынгы учаклар, шау йолдызлы күкләр, ак буранлы кышлар, очсызкырыйсыз Галәм, Дөнья гамьнәре, җанның өзгәләнүтетрәнүләре.

Җирнең йөрәгенә юл – әфәтле,
Кеше йөрәгенә юл – ерак!

* * *

...1968 ел. Туган-үскән җирләрдән кубып күченүләрдән, кадерле кешеләремне югалтудан, сагыну-сагышлардан күңелемнең тулган айдай мөлдерәмә тулган чагы. Әнә мине җаныннан артык күреп яраткан Чибәр апам да истәлекләренең берсендә: «Филисә авылны бик нык сагына», – дип язып куйган. Сагыну... Ә байтак еллар үткәч, мин күренекле шагыйребез Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, Республиканың Муса Җәлил, Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премияләре лауреаты Зөлфәтнең «Коргылды» шигырендә үз халәтемә юлыгып, «аһ»лар итеп үрсәләндем.

Әнкәемнең үзе идең бит син...
Син карыйсың һаман мөлдерәп.
Күкрәгемә кулым куям –
Бушлык!
Синдә калган бугай бу йөрәк...

Шагыйрь дә сагына... Нинди өзгәләнү белән сагына әле! Һәм бу тойгы, кичерешләрнең көчен, зурлыгын исбатлап:

Сагынуга дәва юк икән – дип, тагын бер кат җаннарны айкый.

Болары чак кына соңрак. Минем әлегә Казан көзеннән үзгә бер ямь, җылы эзләгән көннәрем. Шулчак «Татарстан яшьләре» газетасындагы кечкенә генә бер игъланга тап булам да, бар кыюлыгымны җыеп, әдәби түгәрәк утырышына киләм. Түгәрәкнең җитәкчесе Шамил абый Маннапов, мине генә көтеп торган диярсең, шундый бер якынлык, җылылык белән каршы ала. Шактый иртә килгән булып чыктым. Хәл-әхвәл сорашырга, сөйләшергә дә өлгердек. Шамил абый инде башкаларга мине: «Бу – безнең Филисә», – дип таныштыра торды. Биредә миңа иҗаты белән таныш, танылган шагыйрьләр дә, әлегә әдәбиятта беренче адымнарын ясарга җыенучылар да бар. ...Һәм менә иң соңгы булып, гафу үтенеп, ялкынланып, балкып Зөлфәт килеп керә! Күңелләр түгәрәкләнер өчен менә тагын кем җитмәгән икән?!

Равил Фәйзуллин, Рәдиф Гатауллин, Зөлфәт – алар бит безнең яшьлекнең кумирлары! Без бит аларның шигырьләрен дога урынына ятладык. Ә бүген үзләрен күрү, ишетү... һәм кыенсынып кына үз «шигырьләреңне» уку:

Равил Фәйзуллин, Рәдиф Гатауллин, Зөлфәт – алар бит безнең яшьлекнең кумирлары!

Әллә каян йөгереп килде
Дулкыннары игеннәрнең.
Ә кем үпте?!
Абайламый калдым,
Сусаганын күреп иреннәрнең.
(«Туган як җилләре...»)

* * *

Икенче бер очрашу, күңелгә гаҗәеп соклanулар белән уелганы – Тукай клубында уза торган кичәләр алдыннан иде. Тагын иртәләгәнмен. Уйладым да, «Чаян» журналы редакциясенә керергә җөрьәт иттем. Яшь аермасы аз булса да, Зөлфәт сеңелләренә генә түгел, миңа да абыйкай кебек. Аның миңа булган мөгамәләсе шулай туганнарча, олыларча. Ул шуның белән аерата якын, үз иде.

Зөлфәт бу юлы «Чаян»ның борынгы журналларын күрсәтеп хәйран калдыра. Минем әле моңарчы «Коръән хәрефләре» белән язылган газета-журналларны күргәнем юк. Шагыйрь аның кайсы битен ачса да, шаулатып укый. Мин дә үземә гаҗәеп бер яңа дөнья ачам, әсәрләнеп тыңлыйм. Шул вакыт ишектә ике яшь чибәр ханым күренә. Берсе – озата килгәне, дусты – бик тиз генә чыгып та китә. Ә икенчесе... Икенчесе – күзнең явын алырлыгы, үзен бер сүз белән танытып өлгерә. Аның беренче сүзе: «Зөлфәт!» – иде. Икенчесе дә, өченчесе дә – Зөлфәт! Кыскасы, ул бу исемне үтә дә бер ягымлылык белән бар килешләрдә төрләндереп чыкты кебек.
Мин исә шаккатып, бу чибәр ханымны баштан-аяк күзәтәм: ул җилкәсенә таратып салган озын кара чәчләр, тәненә сыланып торган затлы кара күлмәк, аягында биек үкчәле кара туфли. Ай нуры балкыган түгәрәк ак йөз, җылы, йомшак елмаю. Алай гынамы әле, шул тәнгә сыланып торган күлмәк аркылы айдай тулып, түгәрәкләнеп килүче углан да «елмая» иде бугай.
Ә иңнәрендә – ап-ак нәфис шәл. «Бәлкем, җирдәге фәрештәләрнең канатлары шул рәвешледер?! Шагыйрь хатыны нәкъ шулай булырга тиешледер!» Минем соклanулы йөрәк авазы шулай ди.

Сиздермичә генә күзләп киләм: әнә алар, парлашып (гафу, өчәүләшеп!), мәрмәр баскычлардан атлыйлар. Ә алда аларга тагын «Гомер» дигән, «Шигърият» дигән биек-биек баскычлар ялганыр. Һәм йөрәкләрдә яшәешнең иң бөек шигъри фәлсәфәсе уелып калыр:

Гомер бер генә,
Сөю – мәңгелек.

* * *

Казан телестудиясендә эшләгән заманнар. Телевидение гел утка бастыра: хәзер, бүген... «Шигърият» тапшыруын атналык программага кертер өчен Зөлфәтнең

Ходай Тәгалә бу икәвенә шундый игелекле миссия йөкләгән, күрәсең.



Зөлфәт һәм Фирая. «Яшь ленинчы» редакциясендә эшләгән еллары.

шигырьләре кирәк. Әлбәттә, ашыгыч! Эзләп өйләренә китәм. Бәхетемә, Фирая ханым кайткан һәм балык кыздырырга әзерләнеп йөри. Тиз генә максатымны әйтеп чыгып китәргә җыенам. Мине дә өйдә дүрт күзләп көтәләр. Фирая ханым гына авыз да ачтырмый: «Хәзер Зөлфәт тә кайтып җитәр. Ашамыйча китү юк». Уңайсызланып булса да утырам. Өйгә шундый тәмле ис тарала, авыздан сулар килә. Хикмәт, ә мин бит, гомумән, балык ашамыйм диярлек. Аннан әле бер таба ризыкка ничә кеше кайтасы бар. «Алайса, күңел өчен генә, аштан олы булмаска гына бер кисәк балык, бер генә телем бәрәңге», – дим. Фирая ханым, ахрысы, мине ишетми дә, салуы – салу, кыставы – кыстау. Ә мин үземә шаккатам – бу кадәр тәмле балыкны гомеремдә дә ашаганым булмаган ич! Алай гынамы, бөтен тәнемә, җаныма әйтеп бетергесез бер рәхәтлек тарала: «Әллә соң бу яшерен хыялларымның чынга ашып баруымы?!» Нәкъ шулай!

Фирая ханым, чыннан да, шәфкать фәрештәләре затыннандыр. Ул тәгамнең тылсымлы тәме, ул шигъри кичнең яме әлегәчә хәтердән югалып торганы юк. Уйласаң, шундый ашларны бу гаилә кемнәр белән генә бүлешмәде, алар кояшына кемнәр генә җылынмады. Килми торсалар, үзләре эзләп таптылар. Мин белгән, мин сокланган, мин рәхмәтле булган Зөлфәт белән Фирая ханым – шундыйлар. Хәер, каян килеп мин генә булыйм, ди?!

* * *

«Сөембикә»дә эшләгән дәверләр. Зөлфәткә «хан заманында» ук язылган, эссега тартым, кыска гына бер язмамны укырга бирергә уйладым. Бәлкем, «Сөембикә»гә тәкъдим итәрмен дип, шагыйрь фикерен дә ишетәсем килгән иде.

...Калдырып чыкканга ярты көн узды, Зөлфәттән хәбәр-хәтер ишетелми. Гадәттә, ул җавапны тиз тота. Ошамады микәнни соң, алай булырга тиеш түгел кебек иде. Күңел дә төшеп китте. «Тау»га үзем барырга булдым. «Чаян» редакциясе коридорның теге башында гына лабаса. Ишек ачык. Алай да шакып керәм. Иң элек күзем өстәлгә төшә. Кәгазьләрем алдында ята. Әлегә сүзнең яхшысы да, яманы да юк. Инде нигә укытканыма үкенә башлаган идем. Ниһаять, Зөлфәт телгә килде.

– Ышанасыңмы, унбер мәртәбә укып чыктым. Унбер мәртәбә!

Мин тагын да аптырап калдым. Әмма сорау бирергә кыймадым. Алай да күңелемнән: «Бу – шагыйрьнең югары бәясе булса кирәк», – дип фаразладым.

Ул аны әле торып-торып тагын әллә ничә кабатлады.

...Ә без аның кайбер шигырьләрен йөз дә бер кат укыганбыздыр! Санамадык кына...

Аңлар өчен ил шатлыгын
Кайгыларын, язмышын –
Тик бер тапкыр тыңлау җитә
Шул сандугач тавышын.

(«Йөрәк»)

* * *

Бер елны хастаханәдә ятам. Рәхмәт яугырлары, көнозын кеше өзелеп тормады. «Инде кич, бүгенгә, мөгаен, килүчеләр юктыр», – дип уйларга өлгермәдем, «Сезне аста бер пар көтә», – дип ишек шакыйлар. Бу караңгыда, бу суыкта... Төшсәм, хәйраннар булдым: Фирая ханым белән Зөлфәт!

– Хәлегезне дә белик, дидек. Зөлфәтнең яңа җыентыгы чыкты, үз кулы белән тапшырсын, дидем.

Бу – гомере буе бар дөньяны тигезли, бар кешене кайгырта торган, һичкайчан күчтәнәчсез, бүләксез йөри белмәс, без гаҗәпләнеп туя алмаган Фирая ханым инде!

– Сез Зөлфәтнең иҗатын яратасыз. Күңелегез күтәрелеп китәр дип уйладык.

Зөлфәт исә сүзсез генә зәңгәр күзләрен мөлдерәтеп, баш каккалап, җөпләп тора. Әллә соң ул шушы мәлдә шигырь яза идеме?! Мәсәлән, менә мондыен:

Сәерсенмә,
калын пәрдә
Тойсаң карашымда.
Тынлык дәшә күңелемне –
Сәбәп бары шунда.

...Күренеп тора – инде икесе дә арыган, талчыккан. Ә үзләре, күңелләре һаман башка күңелләрне, башка җаннарны аялауда, җылытуда. Ходай Тәгалә бу икәвенә шундый игелекле миссия йөкләгән, күрәсең.

...Мин аларны ихлас рәхмәтләр белән озатып калам. Ә алар кат-кат, тизрәк сәламәтләнүемне теләп, парлашып китеп баралар. Һәм әлеге кич – авырту-борчулар-

ны гына түгел, дөньяларны оныттырырлык Шигырь киче булыр. Без, минем янга төн кунарга килгән Алма апам белән, алмаш-тилмәш, таңгача шигырьләр укырбыз.

Миннән башка кем юксыныр сезне,
Миннән башка кемнәр шәйләсен –
Төнге күлнең суларына сеңеп,
Тибрәп калган торна шәүләсен!

(«Соңгы кәрван»)

* * *

«Суслонгер» дигән тәмугның
Газапларыннан
Сау котылган ул абзыкай
Сөйләшми... Тынган.
..

Шул абзый пычкы игәүли
Һәм
Пычкы елый...

Аның белән бергә минем җаным да елый... Чатнама суык кыш. Бүгенлек кенә утын кисәсе. Әйтергә генә җиңел. Мин әле бала гына. Пычкының икенче башыннан тартырга кеше юк. Пычкы муртайган каен арасында кысылып кала да елый, кысылып кала да елый... Һәм шартлап сына. Урында яткан әбекәмә аны ничекләр итеп әйтәсе?!

Куанычын җыры иткән кеше
Әрнүен җыр итеп җырлаган...
Тыңлаганда йөрәк ярылыр күк! –
Җыр чыгарган –
Ничек чыдаган?!

(«Борынгы шул учак янында...»)

* * *

Упкын сыман шахтага мин төшәм,
Урап төшәм
Җирнең җанына.
Туктыйк, Кәбир кияү!
...Минем куллар
Җирнең йөрәгенә кагыла.

(«Ишетелми ләкин кайтаваз»)

Исең-ушың китәрлек юллар! Нинди сүз-сурәтләр!

«Тыңлаганда йөрәк ярылыр күк!» Без дә туктыйбыз. Әмма уй-хисләрнең ак җилкәнле көймәләре безне әле бик озак шул гаҗәеп шигърият диңгезендә йөздерә, рух өрә, савыктыра.

* * *

...Ходай сулыш өргәч җан кергән бит
Безгә –
сынга –
үзле балчыкка!
Бәлки... тагын сулыш өрер Ходай?
«Җитте...» – димә, йөрәк, ашыкма!

Шагыйрь авырып китте. Табигый ки, Сакчы фәрештәсе утка-суга төшә. «Ашыгыч ярдәм»нең дә ярдәме юк дәрәҗәсендә. Ә хастаханәләрдә урын юклыктан зарланалар. Уйладык та, без сәламәтлек саклау министрының үзенә мөрәҗәгать итәргә булдык. Әле алай да берәр көн коридорда ятар, диделәр. Берничә көннән соң без хәл белергә бардык. Аны инде палатага күчергәннәр. Башта күзләре йомык хәлдә күргәч, йөрәкләр чымырдап китте. Тумбочка өстендә берничә бит ак кәгазь, каләм дә шагыйрьнең илһамлы минутларын көтә иде, күрәсең. (*Фирая ханым безнең кәгазь-каләм алып килүебезне сораса да, үзе инде күптән барысына да өлгергән булып чыкты.*)

Без дә, сүз катарга кыймыйча, шактый гына янында басып тордык. Ә баксаң, Аның җаныннан нинди хикмәтле шигырьләр ургылган:

Сәер теләк туа күңелдә...
Күңел – сәер...
Булмый һаман ярап! –
Үзебезне бер күрәсе килә
Җиһан булып чиксезлектән карап!

(«Сәер теләк»)

* * *

Шигъри сүзнең туган төне –
Ике сулыш арасы!
Булыр ул җанның дәвасы
Һәм төзәлмәс ярасы.

(«Шигырьнең туган төне»)

* * *

Күтәрсен биек талпыныш
Вакытлар агышында, –
Туктыйсы йөрәк туктасын
Иң биек очышында.

(«Ахыр»)

...Мин ул төнне гаҗәеп төш күрәм. Көз. Авылыбызның иске мәчете ишегалдында йөзьяшәр тупыллар алтын-сары яфрак очыра. Без бәләкәй чакта шул өем-өем яфраклар астына күмелеп качышлы уйный идек... Үткәннәрне сагынып, шул хатирәләрне яңартып, карашым белән кояш төшкән агач ябалдашлары аша мәчет тәрәзәләрен иңлим. Һәм имәнеп китәм: икенче катта, урта тәрәзә төбендә, яшь ярымнар тирәсендәге бөдрә чәчле, зәңгәр күзле малай нәүмиз бер елмаю белән миңа текәлеп карап тора. Менә-менә ике күзеннән ике бөртек көмеш яше тәгәрәп төшәргә торган бу баланың нәни шагыйрь икәнен танып алам. Гаҗәпләнүдән, кызганудан йөрәгемә тикле туктап калгандай була. Һәм үземнең: «Йә Раббым, зинһар өчен, бу балага хәерле гомер бирә күр!» – дигән теләгемнән уянып китәм. Шушы төш әле дә өн булып сискәндереп, торып-торып искә төшә!

...Менә шулай, ап-ак буранлы кышта озын, озак хәтер сәфәреннән кайтып киләм. Әлегә уйлар да, хис-тойгылар да шигъри кимәлдә һәм нәкъ Зөлфәтчә –

Гомер нинди кыска!
Нинди озын!

Фото: гаилә архивыннан



Бөтендөнья татар конгрессының мәгълүмат хезмәте һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә идарәсе җитәкчесе Гөлназ Шәйхи Фатыймалар җыя. Кызыл төсле, өсте кара тимгелле бу чуар бөҗәкләрне ул «Фатыймалар», ди. Аның туган ягында – Әтнәдә шулай дип йөртәләр. Ә сездә, мөгаен, аны башкача атыйлардыр: Кояш корты, Алтын капка, Камка, Камка бабай, Камка түти, Камка кош, Алтын камка, Әфләтүн, Камилә, Тутый кош, Тәти кош, Камкавуч, Пытекай, Тимеркапка, Тәти тавык, Тәктәли бабай, Ислан бабай, Патый, Чуар таракан, Сөтле сыер...

Фото: Анна Арахамия

«ФАТЫЙМА, ТИМЕР КАПКАҢ АЧ, АЧ!»

– Вьетнамга ялга барып төштек. Аэропортка аяк басуга ук, дьюти-фриның бер киштәсендә җырлый торган Фатыйманы күреп алдым. Шунда ук яраттым! Аны кочаклап, кассага чиратка барып та бастым. Кызлар: «Нишлисең, кайтканда алырсың!» – диләр. «Ә аңарчы бетсә?» – дим. Уенын-чынын кушып: «Синнән кала башка берәүгә дә кирәкмәс ул», – дип кулымнан җитәкләп диярлек алып чыктылар. Ялым ял булмады... Кире кайтканда, аэропортта шунда ук теге Фатыйманы эзләп киттем. Торган! Көткән мине!

Фатыйма, оч-оч,
Олы капкаң ач-ач,
Киявең килә, кач-кач!

Балачакта бу юлларны кайсыбыз кабатламаган! Синең аңа әйткән сүзләреңне тыңлагандай кулыңда йөреп торуы, тәнеңне сизелер-сизелмәс рәхәт кенә кытыклавы, аннан, канатларын җәеп очып китүе... Артыннан сөенеп карап калуың... Балачакның иң матур, иң самими мизгелләре!

– Кайда гына күрсәм дә, Фатыймалар мине хәзер дә балачакка алып кайта, – ди Гөлназ. – Әбиле, әниле чакларыма... Әбибабайларга бай идем. Әти ягыннан әбиемнең кызлары булмаган, ул өч ир бала табып үстергән. Оныклары да миңа кадәр гел ир малайлар туган. Шуңадыр, бик ярата иде ул мине. Ә әни ягыннан әбибабаларымның беренче оныгы идем. Кадерләп, иркәләп үстерделәр алар мине... Бөҗәкләрдән бик курка идем кечкенә чакта. Бөтенесеннән дә. Хәтта чебеннән дә! Нәрсә булса да килеп кунса, шунда ук чәрелдәп елый башлыйм. Разия әбинең: «Кызым, Фатыймалардан курыкма! Алар бәхетле кешегә генә куна!» – дип әйткәне истә. Бәхетнең әле нәрсә икәнен аңламасам да, елаудан туктый идем. Әби ул чакта күбрәк мине юатыр, тынычландырыр өчен генә әйткәндер, мөгаен, әмма Фатыймалар, чынлап та, үземә бәхет китерде дип саныйм... Алардан күптән курыкмыйм инде – җәйләрен рәхәтләнеп кулыма алам, бакчамда очратсам, сөенәм...

Егерме еллар элек җыя башлый Гөлназ Фатыймаларны. Беренчесен Түбән Новгородка сәяхәткә барган җирдән алып кайта. Агачтан эшләнгән ул. Беренчесе янына икенчесе өстәлә, өченчесе... Алар күбәйгәч, йокы бүлмәсендәге киштәгә генә сыймый башлагач, Фатыймалар өчен аерым шкаф сатып ала. Хәзер өйләренә кем генә керсә дә, иң элек шушы шкаф янына туктала. Бик теләсә дә, узып китә алмый – Фатыймаларның яраттыру сере бар!

– Өйдә Фатыймаларым күбәйгәч, мин алар белән чын-чынлап кызыксына башладым. Без генә түгел, бу бөҗәкләрне бөтен халыклар да аерып куя, үзгә бер ярату белән ярата бит. Фатыймалар үләннәрдәге, агачлардагы бетләрне ашый – уңышны коткара, кешеләр аңа шуңа рәхмәтле. Кеп-кечкенә бер Фатыйма көнозынына йөзгә якын бетне юк итә. Күз алдына китерәсезме?! Үз гомерендә биш меңгә кадәр бетне ашый ул. Бик ач чакта, хәтта колорадо коңгызының күкәйләре дә аның өчен ризыкка әйләнә. Күп илләрдә Фатыйманы уңыш символы дип саныйлар, «Әгәр аңа зыян салсаң, үзеңә күңелсезлекләр килүен көт», – дигән хорафатка бик ышаналар. Германиядә, Австриядә, Швейцариядә, Латин Америкасы илләрендә аңа изгеләр исеме кушып атыйлар. Чехиядә, Словакиядә, Белоруссиядә һәм Украинада «кояш» дип йөртәләр. Күп илләрдә аңа хәтта һәйкәлләр куялар. Берсендә Парижда командировкада булганда, кибет витринасында чуеннан коелган йөз килограммлы Фатыйманы күреп шаккаткан идем. Янынн китә алмыйча бик озак басып тордым. Юлдашларым көлешәләр: «Алып кайтам дип кенә әйтә күрмә!» – диләр.

Гөлназ кызыл төс ярата, шуңа күрә аңа Фатыймаларның да кызыллары күбрәк ошый. Табигатьтә тагын Фатыймаларның сары, кара











һәм ак төслеләре очрый. Хәтта зәңгәр төслеләре дә бар! Тик алары Австралиядә генә яши.

Фатыйманың өстендәге тимгелләренә карап, аның яшен белеп була, диләр. Юк, белеп булмый. Гөлназ әнә: «Унөч тимгел санаганым бар», – ди. Чынлыкта, Фатыймалар иң күп дигәндә, ике ел гына яши. Ә әни Фатыймалар, гомумән, күкәй салуга ук, күзләрен йома...

Ә менә һава торышын элек-электән чынлап та Фатыймаларга карап та ачыклаганнар: әгәр ул учыңнан очып китсә, кояшлы, аяз көнгә юраганнар. Киресенчә, учка сыенса, көннең бозылуын, яңгыр явуын көткәннәр.

Фатыймалар җылы ярата. Ә сез аларның, кошлар кебек, көзен җылы якка очып киткәннәрен беләсезме? Башка чакта аерым-аерым гына көн иткән Фатыймалар, көннәр салкынга авышса, бер көч булып җыелалар да кояш артыннан ияреләр. Иң гаҗәбе – нәкъ очып киткән урыннарына язын кире әйләнеп кайталар. Монысының серен галимнәр дә белми... Шул ук вакытта кайберләре кышларга үзебездә генә кала. Туган якны аеруча яратканнарымы икән?!

И-и, бу Фатыймалар турында әллә нинди кызыклар бар. Әлегә яңадан Гөлназның коллекциясенә әйләнеп кайтыйк әле.

Аның шундый мавыгуын белгәч, бөтен дуслары да диярлек Гөлназга Фатыймалар бүләк итә башлый. Менә бу Фатыймалар төшкән чынаякны Прагадан «Азатлык» радиосы хәбәрчесе Наил Алан җибәргән. Мин дә хәтерлим: «Гөлназ! Мин сиңа Әсмабикә алдым, танышлар Казанга кайта, алар тапшырыр», – дип язган иде ул Фейсбукта. Наил – Teләчедән, аларда бу бөҗәкне Әсмабикә, диләр. Көтмәгәндә китеп барды шул Наил, үзе юк, ә бүләге әнә аны хәтерләтеп шкафта тора... Акча янчыгы тышына Фатыйманы дусты Зөлфирә – «Татарстан–Яңа гасыр» телевидениесе режиссеры Зөлфирә Рамазан махсус чиктергән. Коллекциядәге соңгы Фатыйма да аңардан: туган көненә Фатыймалы шкатулка бүләк иткән. Ә иң күп Фатыймалар якын дусты Ләйсәнәдән («Татарлар» тапшыруы җитәкчесе Ләйсәнә Садретдинова) – ул гел юлда, командировкада: кая гына барса да, Фатыймалы бүләксез кайтмый. Әйе, Гөлназга бүләк сайлыйсы җиңел...

Әмма коллекциянең төп өлеше, әлбәттә, аның үз табышлары.

– Мин аларны бөтен җирдән эзлим һәм бөтен җирдә күрәм! Косметика сатыла торган кибетләрдә, бижутерия бүлекләрендә, сувенир киштәләрендә... Менә бу бала имезлеген Казан даруханәләренең берсеннән алган идем. Уенчыклар кибетендә еш очратам. Төркиядән кадәр күтәреп кайткан зур йомшак уенчыгым бар. Багажга сыймады, аэропорт буйлап култык астыма кыстырып йөрдем... Курчак кебек ясалган Фатыйманы исә Уфадан алган идем. Анысын аерым яратам... Фатыйма төшкән нәрсә генә очратсам да, яныннан тыныч кына узып китә алмыйм инде. Италиядә бер кибетнең витринасында менә бу тоз һәм борыч савытын күрдем шулай. Ә аларда – сиеста: өч сәгатьлек төшке ял. «Хәзер китсәм, яңадан тапмыйм», – дип, кибет яныннан барыбер кузгалмадым... Фатыймалы бу будильникны исә Германиянең Берлин шәһәреннән алган идем. «Европа татарлары альянсы» катнашында Сабантуй узды анда. Кайтканнан бирле йөри – әле бер тапкыр да туктаганы юк... Әлбәттә, командировкага барганда вакыт гел тыгыз – иркенләп кибет карап йөри алмыйсың. Австриядә ярты көн генә булдык: канцтовар кибетенә керергә генә өлгердем. Ә анда мине байлык көткән! Фатыймалы ручка, карандаш, блокнот, открытка, кәгазь... Бөтенесен җыйдым! Әмма коллекциям күбрәк сәяхәтләрдә йөргәндә байый. Миңа киемсалым да кирәкми, башкасы да, иң беренче чиратта Фатыймалар турында уйлыйм, аларны эзлим. Яңа Фатыйма белән кайтсам, күңел була инде, ә берни дә тапмасам, нидер җитми кала. Андый чакта, кайтып, ишектән керүгә: «Сезгә яңа дус булмады бу юлы, артмадыгыз инде», – дим. Әйе, мин алар белән сөйләшәм дә...

Ни генә юк Гөлназның коллекциясендә! Фатыйма рәсеме төшкән савыт-саба, уен кораллары, ачкыч савыты, сумка, уенчык тузан суырткыч, чын зажигалка, үлчәү, нәкъ Фатыйма рәвешендә ясалган чәйнек... Суыткычка ябыштырырга магнитлар, ачкычка асарга брелоклар. Брошкалар. («Әле беркөнне алтын алка күрдем. Тагып йөреп булмас инде аны, әмма барыбер аласым килеп тора».) Кәгазенә Фатыйма рәсеме төшерелгән конфетлар. («Алар күп иде, әмма энемнең улы Азат бик ялынып сорагач, бирми булдыра алмадым».) Фатыйма кебек итеп эшләнгән чын пирожное! («Күгәрмәсен өчен ничек аны киптергәнемне белсәң!») Алар нинди генә материаллардан ясалмаган: агачтан, күннән, «папье-маше»дан, Италиянең Этна янартавыннан чыккан лава кыйпылчыкларыннан, тау хрусталеннән, Сваровски ташларыннан... Ә Гөлназ өчен иң кыйммәтле Фатыйма – энесенең кызы Алиянең үз куллары белән пластилиннан ясаганы. Шундый матур ул! Чын Фатыйма – күзләренә кадәр бар.

– Эштән бик арып кайткан көннәр бар. Андый чакта иң элек Фатыймаларым янында туктыйм. Алар мине тынычландыра, күзем дә, күңелем дә ял итә. Югыйсә алар торган шкафта бернәрсә дә үзгәрмәгән, гел шул килеш, әмма миңа аларны көн дә бер ачып карарга кирәк. Коллекциямдә озак вакыт бернәрсә дә артмаса, Фатыймаларның яңалары кайтмаса, эчем поша башлый, андый вакытларда урыннарын булса да алыштырып куям. Миндә ирлехатынлы Фатыймалар да бар, Италиядән алган идем. Әмма аларны күбрәк барыбер хатын-кызга охшатам. Шундый ук назлылар, сөйкемлеләр, иркәләр...

Гөлнур ХӘСӘНШИНА

ҖЫР БӘЙРӘМЕ

«Татар җыры-2021» фестивале «Казан Экспо» халыкара күргәзмәләр үзәгенең Илһам Шакиров исемендәге концерт залында узды. Бәйрәмгә Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов хәләл җефете Гөлсинә ханым белән килде. Кичәне Гөлназ Сәфәрова һәм Искәндәр Хәйруллин алып барды.

Концерт алдыннан узган матбугат конференциясендә «Барс Медиа» җитәкчесе Камил Гәрәев, Радик Юльякшин, Зөлфәт Хәким, «Караш» төркеме солистлары журналистларның сорауларына җавап бирделәр. «Быелгы фестивальгә татар сәхнәсенең иң популяр җырчыларын керттек. Тамаша үзгәрә, яңа башкаручылар белән тулылана. Фестиваль ике ел өчен генә түгел, өч ел өчен», — дип сөйләде Камил Гәрәев. Шунысын да әйтергә кирәк, пандемия сәбәпле, узган ел «Татар җыры» фестивале уздырылмады. Оештыручылар ике елныкын бергә уздырабыз, дип игълан иттеләр.

Үзенең 22 еллык тарихында «Татар җыры» берничә музыкаль чорның, татар эстрадасы музыкасын яратучылар буынының тере тарихына, татар һәм башкорт җырчыларының музыкаль олимпка күтәрелү майданчыгына әверелде. Шушы зур милли проект аша 500 дән артык лауреат узды, 1250 дән артык җыр яңгырады. Фестиваль музыкаль талантларны үстерү мәйданчыгына әверелде, берничә буын профессиональ артистлар тәрбияләде. Башкаручылар Татарстан Республикасында, Россиянең күп кенә төбәкләрендә, шул исәптән, Мәскәүдә һәм Санкт–Петербургта меңләгән концертлар бирделәр.

Ике дистәдән артык вакыт эчендә татар халкының милли казанышына әйләнгән 2021 елдагы Гала-концерт фестиваль тарихында беренче тапкыр берьюлы ике ел – 2020 һәм 2021 еллар нәтиҗәләре буенча үтте.

Җыр бәйрәме тамашачы күңеленә гаҗәеп куелышы, соңгы ике елдагы матур җырлары, татар эстрадасының иң якты йолдызлары, шулай ук илкүләм танылган башкаручыларның чыгышы белән истә калды. Тамашачылар өчен шулай ук «Яңа йолдыз» телевизион вокал конкурсының 1 нче һәм 2 нче сезонында финалга узган җырчыларның чыгышы да сюрприз булды. Зур сәхнәне ул көнне Салават, Зөлфәт Хәким, Гүзәл Уразова, Ришат Төхвәтуллин, Әнвәр Нургалиев, Айдар Галимов, Зәйнәб Фәрхетдинова, Иркә, Элвин Грей, Динә Гарипова, Эльмира Кәлимуллина, Риф Зарипов, Филүс Каһиров, Данир Сабиров кебек җырчылар бизәде.

РЕКЛАМА ХОКУКЫНДА





Фото: Барс Медиа компанияләре төркеме









УЛЫМ, ГАЗИЗЕМ... ЯКИ ЯШӘҮ ӨЧЕН КӨРӘШ



Гөлнур
САФИУЛЛИНА

Яман шеш кичергәннән соң балага узу? Сәламәт бала тудыру? Исән калу?! Табиблар ул чакта сүзләрнең йомшаграгын сайлап та тормый. «Сезнең алда өч юл, – ди алар. – Йә сез исән каласыз – балагыз үлә; йә сез үләсез – балагыз исән кала; йә икегез дә үләсез. Могҗиза коткарса гына». Ә ул барыбер тәвәккәлли!.. Тугыз ай буе нинди утлар эчендә янды икән?! Ничә тапкыр үлеп, ничә тапкыр яңадан терелде икән?!
Ә могҗиза... Ул була!
Әнисе Тәслия ханымның батырлыгы турында Россия Фәннәр Академиясе Көнчыгышны өйрәнү институтының фәнни хезмәткәре, сәясәт фәннәре кандидаты, 2005–2007 елларда Бөтендөнья татар яшьләре форумы җитәкчесе, «Мин татарча сөйләшәм» проектын башлап җибәрүчеләрнең берсе, режиссер Илшат СӘЕТОВ сөйли. Безнең әңгәмәне Илшатның әнисенең сеңлесе Тәнзилә апа тулыландыра.



Улым туганнан соң Җир шарында миннән дә бәхетле тагын берәр кеше булдымы икән?!

Илшат: Мин, әлбәттә, әнинең кайчандыр онкология кичергәнен белә идем. Бер күкрәге булмавын да... Әнинең язмышын күбрәк апа яки абый, аннан әби сөйләде. Ватык телефон аша җыелган кыйпылчыклар гына иде алар... «Үләчәксең», дип әйтеп торганда, мондый адымга кем генә бара алыр иде икән?! Баласыз, берүзең яшәсәң дә яшәү бит әле ул... Төрле сценарийларны күз алдына китергәндер. Өметләнеп көткән баласы үлсә... Үзе үлеп, бала әбисе кулына гына калса... Бернидән курыкмыйча тәвәккәлләүчеләрне азарт кеше, диләр. Юк, әни андый түгел иде. Киресенчә, бик сак иде ул. Аның очрагында «риск» сүзе туры килми, язмыш белән көрәшү дөресрәктер... Бер яктан, ул: «Хәзер операциядән соң инде кияүгә чыкмыйм», – дип уйлагандыр. Улым яки кызым үземә иптәш булыр, дигәндер. Бала табу – чиргә каршы тора алуын, җиңелмәвен күрсәтү өчен дә кирәк булгандыр, аңа көч биргәндер дип тә уйлыйм. Мәрьям әби каршы булса, әни мине тудыра алмас иде. Дөрес, ул үзе дә шактый үҗәт иде. Бертуганнарының – Ландыш абыйның, Тәнзилә апаның әнине ул чакта хуплавын яхшы беләм.

Операция вакытында ялгыш лимфа төерләренә кагылганлыктан, әнинең уң кулы эшләми иде. Мин анысын хәтерләмим, әмма кулы башта хәрәкәтләнә торган булган аның, әмма берсендә Казаннан кайтканда ул авариягә очрады. Рульдә шофер йоклап киткән... Миңа 6–7 яшьләр тирәсе бу. Әни нәрсәдер алып кайтырга вәгъдә иткән иде, шуңа күрә аны бик көттем ул көнне. Көтә-көтә йоклап киткәнмен. Төнлә өйдәге ыгы-зыгыга уяндым, башта нәрсә булуын аңламадым да... Авариядә әнинең сул кулы сына, уңы аңарчы да начар хәрәкәтләнгәнгә күрә табиблар анысына игътибар да итми. Аннары инде соң була – кулы бөтенләй эшләми башлый. Бу хәлләрдән соң әбигә инфаркт булды. Без барыбыз да Тәнзилә апа кулына калдык ул чакта. Ә аның үз гаиләсе, эше дә бар...

Тәнзилә апа: апам Тәслия Арслан кызы 1949 елның 5 сентябрендә Азнакай районы Яхшыбай авылында гаиләдә беренче бала булып дөньяга килә. Әтиебез 1942 елдан 1948 елга кадәр ике сугышта катнашып, култык таяклары белән авылга кайтып төшә. Әниебез Мәрьямне – 18 яшьлек кызны, бухгалтерлар курсын тәмамлагач, колхозга бухгалтер итеп җибәргән булалар. Әтиебез, кайтыр алдыннан, ап-ак битле, зур кара күзле, озын кара ике толымлы бер кызны төшендә күрә. Кайтып, колхозга эш сорарга баргач, идарәдә аягыннан чак егылмый – өстәл артында төшендәге кыз утыра! Алар шул елны ук өйләнешәләр. Бер елдан соң апа туа.

Апа мәктәптә гел «бишле»гә генә укыды. Аның кебек матур язучыны мин белмим. Үзе пөхтә, тәртип ярата. Без гаиләдә өчебез дә эшләп үстек. Әмма абый белән мин шукланырга да өлгерәбез, ә апа әти-әни сүзеннән беркайчан да тайпылмый иде. Өйдәге барлык эш аның өстендә: идәннәрне чип-чиста итеп юа, ашарга пешерә. Ә аның кискән токмачлары! Үзе бер шедевр!

8 нче сыйныфка барганда апа озын буйлы, сылу кыз булып җитеште. Мин гомерем буе аңа сокланып яшәдем: әни ягына охшаган – ап-ак тәнле иде ул. Шул елны үзебезнең урам егете белән очраша башлады.

8 нче сыйныфны «бишле» билгеләренә генә тәмамлагач, Казан педагогика училищесына укырга керергә китте. Мин аның чыгып киткәнен бүгенгедәй хәтерлим. Чемодан, ул чемоданда чүпрәк капчыклар эчендә таба белән кәстрүл һәм... киез итекләр! Әни апаның укырга керүенә шулкадәр ышанган – җәй көне үк итекләрен дә җибәргән.

Апа училищедан кызыл диплом белән чыкты һәм шул ук 1968 елда Казан дәүләт университетына укырга керде. Ул вакытта шок дигән сүзне белми идек әле. Абый белән безнең халәтне аңлата торган гына булмады. Ничек инде Ленин укып йөргән җирдә бәләкәй генә татар авылыннан чыккан кыз белем алсын?! Ул укырга кереп кайткач без аның белән сөйләшергә дә кыймый йөрдек... Апа өченче курска күчкәндә, мәктәпне «бишле»гә генә тәмамлап, Казан педагогика училищесына укырга кердем. Әлбәттә, җиңелрәк булды: бөтен җиргә апа җитәкләп йөртте. Торырга урын тапканчы, университетның Кызыл Позиция урамындагы тулай торагында икебез бер караватта йокладык. Бүлмәдәшләре бик кызыклы шәхесләр иде. Икесе ике факультетта укысалар да, Нурия Измайлова белән бик дус иделәр. Марсель Галиев, Роберт Миңнуллин, Фәннур Сафин, Риман Гыйлемханов, Шәмсия Җиһангировалар барысы да апаның танышлары гына түгел, дуслары да иде.

Без җәйге каникулга кайтуга, әтиләр район үзәгенә күчтеләр. Шул елны апа йөргән егете (ул агроном булып эшли иде) белән ачуланышып, бөтенләй диярлек белмәгән Азнакай егетенә кияүгә чыгып куйды. Әниләр өчен бу аяз көнне яшен суккан кебек булды. Аларны бер җөмлә белән «красавица и чудовище» дияргә була иде. Тышкы кыяфәт турында гына бармый сүз. Дөрес, апа укуын көндезге бүлектә тәмамлады, ире акчалата да ярдәм итте, әмма аның көнчелеге! Холкы! Безгә, бик тату, бербереен яратып, юк кына әйбергә дә сөенеп яшәүче әти-әни белән үскән кешеләргә апаның ирен кабул итү авыр булды.

Азнакайга кайткач, апаны Тымытык авылына рус теле һәм әдәбияты укытырга җибәрделәр. Ул анда бер генә ел эшләде. Эшкә бирелгәнен күреп, башта Азнакай кичке мәктәбенә завуч итеп күчерделәр, аннан район мәгариф идарәсенә башта методист, аннан соң инспектор итеп куйдылар. Соңгы 33 елда ул мәгариф идарәсендә җитәкче урынбасары булып эшләде. Гаҗәеп эрудицияле, искиткеч кече күңелле, ярдәмчел, татарча һәм русча чиста сөйләшә... Әмма шәхси тормы-



Әни мине бик ярата иде, әлбәттә. Икеләтә ярата иде – янымда булмаган әти өчен дә.



шында уңышсызлыклар гел сагалап кына торды шул аны. Беренчедән, баласы булмады. Сәбәбе ирендә иде.

«Яман шеш» дигән диагнозны апага 28 яшендә куйдылар. Аңа операция алдыннан, яшь баламны иремә калдырып (без Горький өлкәсендә яши идек ул чакта), 2 яшьлек олы кызым белән Казанга кайттым. Шул көнне аның янына аерылган ире дә килгән иде... Апаның уң күкрәген алдылар. Операция ясаган хирург: «Бу кадәр матурлыкны ничекләр бозарга соң?» – дип озак уйланды, диделәр соңыннан. Тәне мәрмәр кебек матур иде аның... Операциядән соң әни бик нык карады апаны. Халык медицинасында нинди үләннәр бар – барысын да эчерде.

Апаның иң зур хыялы – әни булу иде.

Башта ул бу хакта әни белән сөйләшкән, аннан бездән киңәш сорады. «Гомерем буе атом бомбасы өстендә утырган кебек яши алмыйм. Бу чир миндә калган булса, авырга узгач, тиз генә китеп барырмын. Исән калып, балам туса, мине ярдәмегездән ташламассыз», – диде ул. Без, әлбәттә, ризалаштык. Авырга узып өч ай булгач кына хатын-кызлар консультациясенә барды. Анда шау-шу купкан. Бөтен табиблар җыелып, консилиум уздырганнар. Апаны учетка да алмыйча, Казанга юллама биргәннәр: баладан котылырга, дигәннәр.

Бернинди токсикозсыз күтәрде ул авырын һәм декретка чыгарга дип, җиде ай булгач, кабат консультациягә барды. Андагы табибның аптыравы! Ачулануы! Ә апа: «Мин баламны табам», – дип, тыныч кына елмаеп тик утыра... «Казанда табасың!» – диделәр, ә ул китмәде. Операциядән соң ике ел үткәч, Азнакайда, 7 март көнне Илшатны тапты...

Илшат: Әни, миңа тапшыру өчен, бер дәфтәргә хатирәләрен яза башлаган булган. Анда мондый юллар бар: «Гомеремдә иң бәхетле берничә мизгел булды: үзем теләгән Казан педучилищесына, аннан соң Казан университетына укырга керүем, беренче дәресемнән соң урамда укучыларымның танып исәнләшүе, берничә бик авыр операциядән соң исән калуым... Ә Илшат туганнан соң Җир шарында миннән дә бәхетле тагын берәр кеше булдымы икән?! Искиткеч балам минем: иң акыллы күзләр, иң тәмле хуш исле биләү, бик нәфис бармаклар, киң маңгай, матур борынлы, чия иренле улым... Илшатым, улым, бәгърем минем. Сиңа кадәр гадәт буенча гына яшәгәнмен икән бит. Ә 1980 елның 7 мартында минем мәгънәле, иң кадерле кешемә багышланган тормышым башланды. Улыма 3 яшь тулганчы бер тапкыр да кичтән беркая бармадым. Һәр кичне йә макет җыйдык, йә китап укыдык...»

Әни бик чибәр булган. Ә аннан операция, бер күкрәген алдыру. Хатын-кыз өчен зур фаҗига бит бу. Тагын бераздан – авария. Кулсыз калу... Кулы өчен әни бик кимсенә иде – ул елдан-ел күбрәк шеште, кием сайлау авырлашты, кулы бернәрсәгә сыймый башлады.

Аннары без яшәргә әбигә күчендек. Ашарга гел әбигә йөрибез – болай да үзебезгә кунарга гына кайта идек. Кулы эшләмәгәч, әни ашарга бик сирәк, иң гади әйберләрне генә пешерә иде. «Их, кулларым булганда өчпочмаклар да ясый идем бит», – дия иде ул. Тәмле әйберләр миңа әбидә һәм Тәнзилә апада эләгә иде гадәттә.

Тәнзилә апа: Ул авариядә апаның исән сул кулы сынып, аны гипска салдылар. Уң аягы бик нык җәрәхәтләнде, авызы тайган иде. Шушы хәлдән соң әнигә өченче инфаркт булды... Без аларны кызым белән икәү карадык. Ике кулсыз апа яшь бала хәлендә калды. Әмма ул бик көчле рухлы кеше иде: тизрәк аякка басарга тырышты, еламады, зарланмады. Өч ай дигәндә эшкә чыкты. Инде авырлыклар артта калды дип йөргәндә, алар медосмотр үттеләр һәм анда апага аналыгын алдырырга туры киләсен әйттеләр. Операцияне Казанда, шул ук онкология больницасында ясадылар. Мин аны сакларга барырга җыенгач, Илшат: «Апа, әнине исән алып кайт, яме», – дип, күз яшьләре белән озатып калды... Буран иде. Көчхәл белән төнлә генә килеп кердек Казанга. Туганнарда кунып, таң белән больницага киттем. «Соңрак барсаң да була, хәзер аны барыбер операциягә әзерлиләр», – дисәләр дә, ашыктым. Палатага барып керсәм, апага укол кадап яталар. Шунда ул көлеп җибәрде: «И-и, иртән торгач операциягә кадәр сине күрсәм, бар да әйбәт була дип уйлаган идем, килеп җиттең!» – диде. Операция бүлмәсенә үзем озаттым һәм каршы алдым – унбер көн буе яныннан китмәдем. Аннан, хирург чакырып: «Анализлары чиста», – диде. Апа белән икәү ко-



Тәслия ханым улы Илшат белән.

Гомере буе барлык проблемаларны да үзе чишеп яшәгәч, кыенрак булгандыр, мөгаен.

Соңгы көненә кадәр Илшат һәм аның гаиләсе өчен борчылды. «Мин китсәм дә Илшатымны какмагыз», – диде. Нинди кагу! Илшат миңа үз улым кебек якын. Без үзебез өчәү бик дус-тату идек, бүген балаларның, оныкларның бер-берсе белән аралашып, ярдәмләшеп яшәүләре сөендерә. Илшат та хатыны Влада белән Азнакайда туры безгә кайта, уллары Әнвәр белән Йосыф безгә әби-бабай, дип дәшә. Апа ризадыр...

чаклашып елаштык... Бер ай да тормады, тагын эшкә чыкты ул. Ә 2006 елда кабат операция кичерде: уң кулының умрау сөяген алдылар. Авария вакытында сынып, дөрес ялганмаган булган. Операция урыны ачык калды, ялганмады – нурланыш терапиясе алу нәтиҗәсе. Шуннан башлап соңгы көнгәчә – ундүрт ел буе аңа һәр көнне перевязка ясарга кирәк булды.

Илшат: Минем телем чиста татарча ачылган. Татар балалар бакчасына йөрдем. 8 нче сыйныфтан соң Әлмәттә ачылган төрек-татар лицеенда укыдым. Әйе, өйдән мин 14 яшемдә үк чыгып киттем. Әнине ул елларда районның татар иҗтимагый үзәге җитәкчесе итеп тә белгеләделәр: Азнакайда татар мәгариф системасын төзеде ул, татар гимназиясе ачу артыннан да күп йөрде.

Әни мине бик ярата иде, әлбәттә. Икеләтә ярата иде – янымда булмаган әти кеше өчен дә. Әмма үземнең «әтием юк» дип кимсенгән чагымны белмим. Аның каравы, Ландыш абыем бар иде бит. Әниемнең бертуган энекәше ул. Югары белемле, акыллы, географак тәмамлаган, диңгез флотында хезмәт иткән. Мин җәен Минзәләдә аларда берәр ай торып кайта идем. Көн саен икәү балыкка йөрибез. Абый юмор ярата, кулы эш белә – мине бик күп нәрсәгә өйрәтте. Күпмедер дәрәҗәдә әти дә булды. Әби дә ир-атларча коры куллы иде – ул да әти ролен үтәгәндер. Әмма мин әбинең яраткан оныгы статусында идем.

Кечкенә чакта миңа «әтиең үлде» дип әйтәләр иде. Әни аның хакында 30 яшемә җиткәч кенә сөйләде. Шундый куркып сөйләде... Тик минем бит бернинди югалтуым юк иде – тапмаганны югалтып булмый. Моны аңлагач, әни бик тынычланып калды... Соңгы елларда генетика, ДНК белән шактый кызыксындым, бу темага күп укыдым. Кешенең генетик картасында «чүп» геннар дип аталган бик мөһим геннар бар: мохиткә карап, шул геннар синдәге башка геннарны йә кабыза, йә сүндерә икән. Шуңа күрә миндә әнидә, әбидә булмаган гадәтләр, сыйфатлар юк: мин шул гаилә, шул мохит баласы. Әтидән күчкән геннар күзнең яки чәчнең төсенә генә тәэсир иткәндер, бәлки.

Тәнзилә апа: Апа соңгы көннәренә кадәр яшәү рухын югалтмады. Мәзәкләр сөйләп көлдерә иде. Берәрсенә ярдәм кирәк булса, телефоннан әллә кемнәрне табып сөйләшә, уңай якка хәл итә. Аны бик хөрмәт иттеләр: пенсиягә чыккач та яныннан кеше өзелмәде. Хәл белергә, киңәш сорарга киләләр иде.

2005 елда Илшат туйлап өйләнде. Апа: «Ике оныгымны да күрергә язды», – дип бик сөенә иде. Аларны сөйли башласа, сәгатьләр буе да туктамый. Илшат белән горурлануы да чиксез иде, әмма ул аны беркайчан да күрсәтмәде. Соңгы ике елда апаны карарга кеше кирәк булды (безгә күчәргә ризалашмады ул), «сиделка»га акчаны Илшат түләп торды. И-и, шуңа уңайсызлана иде инде апа: «Балаларның өлешенә керәм», – дия иде.

Илшат: Әнигә яман шеш дигән диагноз куйгач: «Күп булса, өч ел яшәр», – диген булганнар. Ә ул 70 кә җитте... 2007 елда әби вафат булды. Ялгызы читен булса да, икенче яктан тормышы үзенчә көйләнгән иде әнинең. Кая күченү?! Үз өен ярата иде ул: күпме чакырсак та, Казанда бездә ике тапкыр гына кунак булды. Ә Мәскәүгә килмәде дә. Чирләре күп иде аның. Микроинсульт та кичерде. Земфира исемле шәфкать туташы аңа 14 ел буе көн саен перевязка ясап торды – ул безнең бер туганыбызга әйләнде. Әни урынында йомшаграк кеше булса, күптән бирешер иде, ә ул дисциплина белән яшәде, шуңа күрә дә күп нәрсәне җиңде.

Әни икенче тапкыр егылгач, сөйләшүеннән үк сиздем: хәле әйбәт түгел. Шунда ук самолетка билет алдым. Казаннан Азнакайга машина белән кайттым. «Бер сәгать элек өзелде», – диделәр. Әмма соңгы тәүлектә ул инде беркемне танымаган...

Әби, әни язмышына таянып бер фильм төшерәсе килә. Сериалга җитәрлек материал бар бит анда. Бер өлеше әнинең туган вакытлары – 1949–50 нче еллар, совет чорындагы татар авылы, андагы кеше драмасы турында булыр. Аннан, әнинең бер авыз русча белмәгән килеш Казанга килүе, тулай торакта яшәп, югары белем алуы. Мәхәббәт тарихлары. Бик озак очрашып йөргән кешесе белән аерылышу... Авырып китүе... Операция кичерүе, аннан мине табуы... Әнидәге архив! Милли-мәгариф темасына диссертациягә җитәрлек материал бар аңарда.


Фото: www.pixabay.com



Сорауларга табиб-гинеколог Эльвира НОГМАНОВА җавап бирә

Икенче баламны көтәм. Беренчесенә – яшь ярым. Аны еш кына кулга күтәрергә туры килә. Авырлы хатын-кызга бу рөхсәт ителәме?

– Йөклелек чорында хатын-кызга авыр әйберләр күтәрү тыела. Чөнки бу аналыкны тонуска китерүгә, умыртка баганасы дискы бүсере, кан тамырлары варикозы чыгуга сәбәп булырга мөмкин. Авырлы хатын-кызга 3 килограммнан артмаган әйберләр генә күтәрү рөхсәт ителә.

Балага узганчы хатын-кыз актив рәвештә спорт белән шөгыльләнгән булса, 5 килограммга кадәр авырлык күтәрергә ярый. Әгәр дә баланы барыбер кулга алырга мәҗбүр булсагыз, куркынычсызлык кагыйдәләрен сакларга тырышыгыз. Моның өчен, беренче чиратта, махсус бандаж кияргә киңәш итәм. Бандаж кию аналыкның алгы ягын тонуста тотудан саклый. Шулай ук компрессион оеклар кию дә – профилактик чара. Аларны кигәндә кан тамырларына басым кими. Көн дәвамында ятып ял итәргә тырышыгыз. Бу – тонусны җибәреп торыр һәм кан тамырларыннан киеренкелекне бетерер.

Алдагы йөклелек чоры ярып алу ысулы белән тәмамланган хатын-кызлар өчен 5 килограммнан да авыр әйберләр күтәрү бөтенләй тыела. Бу кагыйдә сакланмаган очракта туачак баланың тормышына куркыныч яный дигән сүз.

Мин беренче балама йөкле. 35 нче атнага җиттем, 21 килограммга арттым. Табибым авырлыкны киметергә куша, әле тагын биш атна йөрисең бар ди. Авырлыкның артуы шулкадәр зыянлымы?

– Йөклелек чорында хатын-кыз табигый рәвештә авырлык җыя. Һәр хатын-кыз өчен үз нормасы бар. Бу тән авырлыгы индексына (индекс массы тела – ИМТ) бәйле. Мәсәлән, ИМТ 18,5 кадәр булган ябык хатын-кызлар өчен 12,5–18 кг кадәр авырлык җыю норма санала. ИМТ 18–25 булса, 11,5–16 кг артырга була. Хатын-кызда болай да артык авырлык булса (ИМТ 25–30 кг), аңа 7,5–11 кг арту гына норма санала. Хатын-кызның авырлыгы шушы билгеләрдән артып китсә – ашау һәм тормыш рәвешенә игътибар кирәк дигән сүз.

Артык авырлык кан тамырларына, умыртка баганасы дискына басымны арттыра. Дөрес тукланмау һәм артык авырлык җыю аркасында моңа кадәр үзен сиздермәгән авырулар да калкып чыгарга мөмкин. Күп ашап, аз хәрәкәтләнгән очракта артык калорияләр май катламына әйләнә. Бу – диабетка, югары кан басымына сәбәп булырга мөмкин. Карындагы бала да артык авырлык җыя, һәм бала табу процессы кыенлаша.

Аналыкта беренче йөклелек чорыннан җөй калган булса, әнинең артык авырлыгы карындагы балага куркыныч белән яный. Май катламы кан тамырларына, сосудларга басым ясый. Шуның аркасында гиподинамия барлыкка килә һәм аналык-плацента кан йөреше бозыла. Нәтиҗәдә, бала начар үсә, кечкенә булып туарга мөмкин. Шуңа күрә ашауны контрольдә тотарга кирәк, артык авырлык җыюдан сакланыгыз. Аксым, углевод һәм майларның тиешле күләмен ашагыз, витаминнар эчегез. Сезнең сораууга кире кайтып, табиб сүзенә һичшиксез колак салырга киңәш итәм. Кан басымыгыз уйный башласа, шешенү барлыкка килсә – бигрәк тә. Сез әле йөклелек чорының ахырына җитмәгәнсез, әмма тиешле авырлык нормасының чиген бик нык арттыргансыз. Атнага бер тапкыр ашауны нык киметү көне ясагыз. Ул көнне аксым гына кулланырга һәм су эчәргә ярый. Икенче көнне авырлыгыгызга контроль ясар өчен табиб янына барыгыз.

Нәниләргә күчтәнәч!

Телефон камерасын QR-кодка якынайтып, аудиоформатта язылган әкиятне балагызга тыңлатыгыз.



Кадерле әниләр!
«Яшь әни» рубрикасына сездән сораулар кабул итәбез.
Җавап бирүче белгечләр: педиатр, гинеколог, стоматолог, невролог, хирург-ортопед, кардиолог, иммунолог-аллерголог, гастроэнтеролог, эндокринолог, офтальмолог һәм башкалар.

Балаларга кагылышлы сорауларыгызны – 8 (843) 2-22-09-77 телефоны аша, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 нче йорт адресы буенча яисә ssuum@yandex.ru электрон адресына «Сорау–җавап» дип язып җибәрә аласыз.



Сорауларга педиатр Ләйсән НОТФУЛЛИНА җавап бирә

Улыбызга ун ай булды. Әле дә теше чыкмады. Башка балаларда сигезәр теш күреп борчылам. Безнең проблемалар юкмы икән?

– Теш чыгу процессы һәр балада үзенчә уза. Теге яки бу якка берничә айга тайпылыш булырга да мөмкин. Ягъни беренче тешләр кайбер балада иртәрәк, икенчеләрендә соңрак чыга. Гадәттә, беренче тешләр 6–9 айда чыга башлый. 1 яшькә баланың 8 теше чыгып өлгерә.

Беренче тешнең ничәнче айда чыгуына әнисенең йөклелек чоры ничек узуы, ничәнче айда баласын табуы, генетик үзенчәлекләр йогынты ясый. Теш чыгу шулай ук баланың имезлек суыруы, ашауда тиешле элементларның җитмәве, Д витамины дефициты, калкансыман биз функциясе кимүенә дә бәйле. Һәрхәлдә, паникага бирелмәгез. Баланың үзен ничек хис итүенә һәм үсеш үзенчәлекләренә игътибар итегез. Бер яше тулуга теше чыкмаса, табибка мөрәҗәгать итегез. Ул сезгә өстәмә тикшерүләр билгеләр.

Диңгезгә ял итәргә барырга җыенабыз. 3 яшьлек кызыбызны үзебез белән алырга микән дип баш ватабыз. Әни әйтә, кыш көне климат алыштырып йөрмәгез, чирләргә мөмкин, ди. Кышын диңгездә ял итү балага зыянлы булмасмы?

– Олылар белән чагыштырганда, бала организмы климатның кискен үзгәрүенә кыенрак ияләшә. Әйе, алар акклиматизацияне авыррак кичерә. Бу чорда баланың үз-үзен тотышы үзгәрә: сүлпәнлек барлыкка килергә мөмкин, ул ешрак борчыла, елый, йокы режимы бозыла, ашамый башлый. Хәтта тән температурасы да күтәрелергә, эч китәргә, хроник авырулары баш калкытырга, стресс күзәтелергә дә мөмкин. Табигать шартларын кисәк үзгәртү баланың сәламәтлегенә зыян китермәсен өчен, ялыгызны җәй айларына планлаштырсагыз, яхшырак булачак.

2 яшьтә баланың начар сөйләшүенә игътибар иттек. Шул яшьтә генә табиб тел кереше (уздечкасы) кыска булуын ачыклады. Аны кистереп тә, төрле күнегүләр белән тарттырып озынайтырга да була икән дип укыдым. Операция ясамый гына хәл ителә торган проблемамы бу?

– Тел кереше сыгылмалы, яхшы сузылучан була. Ләкин кайвакыт аның сыгылмалылыгы кимергә мөмкин. Димәк, сузылу мөмкинлеге дә кими. Моның нәтиҗәсе буларак, балада сөйләшү, кайбер хәрефләрне, авазларны дөрес әйтү ягыннан авырлыклар туарга мөмкин. Ситуациянең нинди дәрәҗәдә булуыннан чыгып, әлеге проблеманы хәл итәр өчен стоматолог яисә логопедка мөрәҗәгать итәргә кирәк. Алар бу очракны ничек хәл итәргә кирәклеген аңлатырлар. Логопед тел керешенең сузылучанлыгын арттырыр өчен төрле күнегүләр комплексы, массаж ясауны тәкъдим итәр. Әлеге киңәшләрне үтәр өчен, әлбәттә, баладан гына түгел, әти-әнидән дә зур түземлек, сабырлык, максатчанлык сорала. Логопед тәкъдим иткән күнегүләрне эшләү нәтиҗә бирмәсә, хирург ярдәме кирәк булачак.

ДРКБның матбугат хезмәте җитәкчесе Зөһрә Гыйбадуллина ярдәме белән әзерләнде.

СОРАУ—ҖАВАП

БӘЙРӘМНӘН СОҢ ДӨРЕС ТУКЛАНУ



Килешәсездер, Яңа ел каникуллары вакытында аз дигән дә бер-ике килограмм авырлык өстибез. Моңа сыгылып торган бәйрәм өстәлләре дә, әниләрнең кайнар бәлешләре дә, урамда суык булып, өйдә утырулар, ягъни аз хәрәкәтләнүләр дә сәбәпче. Яңа ел үтүгә, җәйгә әзерләнә башлыйбыз. Ул инде артык авырлыкны киметеп, итәк-чабуларны җыю дигән сүз. Әмма кыш – катгый диеталар тоту өчен авыр чор. Ничек тукланырга? Интегратив диетолог Гөлназ ГЫЙМРАНОВА сорауларыбызга җавап бирә.

Көнлек ашау режимын ничек төзергә?

Беренче ашау – иртәнге аш – йокыдан торгач бер сәгать эчендә; икенчесе – әбәт вакытында; кичке аш, ятарга өч сәгать кала, сәгать җиделәр тирәсендә булырга тиеш. Мин, гомумән, иртән ботка ашарга киңәш итмим, чөнки углевод (ботка) белән генә тамак туймый. Мәсәлән, иртән котлет белән карабодай, салат һәм ак май ашарга була. Әбәттә теләсә нинди ризык ярый, туклыклы гына булсын. Сөт ризыкларын 25 яшьтән олырак кешеләргә ашарга киңәш итмим, чөнки эчәклекләрдә ферментлар кимегәнлектән, организм аны үзләштерә алмый. Кичке аш вакытында ашкайнату системасы тиз эшкәртә алган җиңелчә ризыклар ашагыз. Ашау арасында су эчү әйбәт.

Яңа елдан соң ашкайнату системасын тернәкләндерү өчен нинди ашау режимына күчәргә? Нинди продуктларга өстенлек бирергә, кайсысыннан баш тартырга?

Яңа елдан соң өч-дүрт тапкыр ашый торган режимга күчәргә кирәк. Ашау арасында капкалап алу гадәтен туктатыгыз. Бәйрәм чорында артык күп ашаганлыктан, ашкайнату системасына авырлык килә, ризык тиешенчә эшкәртелеп бетми, тоткарлана. Җитмәсә, кеше ризыкны ныклап чәйнәп йотмый. Ашказанындагы авырлыкны бетерү өчен, ферментлар бүленеп чыксын өчен 400 мг магний эчәргә һәм озаклап чәйнәп ашарга кирәк. Авызга капкан һәр кисәкне 32 тапкыр чәйнәргә кирәк, диләр. Ашарга 20 минут кала, җылы су эчү дә ашкайнату системасы өчен файдалы. Гадәти туклану режимында аксымга (ит, балык, йомырка, сыр), майга (82,5 процентлы атланмай, туңмай, сарымай, зәйтүн мае), яшелчәгә (барысы да) һәм ярмаларга (дөге, карабодай, борчак, кузаклылар) өстенлек бирегез. Рафинадланган ак шикәр ашаудан тыелыгыз.

Су балансы нинди булырга тиеш?

Су режимы елның теләсә кайсы фасылында да 1 кг авырлыкка 30 мл булырга тиеш. Мәсәлән, 60 килограмм авырлыктагы кешегә көненә ике литрга якын су кирәк. Суны һәр сәгать саен аз-азлап эчсәгез, тагын да яхшырак.

Бәйрәмнән соң ук ач торырга, каты диетага утырырга ярыймы?

Сәламәтлек буенча зур проблема булса гына катгый диетага утырырга киңәш итәм. Көненә өч тапкыр ашау да җитә. Ризык бары тик баллы гына булмасын.

Яңа ел табынына әзерләнгән салатларны гадәттә берничә көн ашыйлар. Бу дөресме?

Салатларны атна буе ашарга ярамый, чөнки анда гөмбәчекләр үрчи. Әзерләгән ризыкларны икенче көнне үк ашап бетерергә кирәк.
Ә иң мөһиме – артык күп әзерләмәскә!

Яңа еллардан соң, гадәттә, салкыннар башлана. Бу чорда ничек тукланырга?

Суыкта май ашарга кирәк. Май организмны җылыта, аңа энергия бирә. Курыкмагыз, әлеге ризыктан артык авырлык булмый. Туклану режимында атланмай, кокос мае, зәйтүн мае, майлы итләр булсын.
Ә көнбагыш маен, гомумән, ашарга рөхсәт итмим, чөнки ул организмда омега-3 балансын начарайта һәм канда глюкоза артуга китерә. Ә бу – шикәр чиренә җитү чиге дигән сүз.

ЭЧ ЯССЫ БУЛСЫН ӨЧЕН


Пресс күнегүләр – теләсә кайсы спорт тренировкалары программасындагы мәҗбүри элемент. Тәҗрибәле атлетлар да, яшь спортчылар да корсак мускулына зур игътибар бирә. Яссы тартылган эч яки рельефлы кубикларга ия булу өчен тренажерлар залында көн саен шөгыльләнү кирәкми дә. Әлеге нәтиҗәгә спортзалда гына түгел, өй шартларында да ирешергә мөмкин. Иң мөһиме – күнегүләр программасын дөрес төзү һәм системалы рәвештә башкару. Шулай ук дөрес туклану режимы турында да онытмагыз. Параллель рәвештә май катламнарын да бетерергә кирәк, мускулларны даими эшләтү генә нәтиҗә бирмәячәк. Ә пресс өчен физик күнегүләрне тренер Резеда МУСИНА өйрәтер. «Бу күнегүләрне көн саен дүртәр кат 10–15 тапкыр эшләсәгез, 8 Март бәйрәменә яссы эчле булырсыз», – ди ул.

1

Аркага сузылып ятабыз. Куллар баш астында, аяклар тездән туры итеп бөгелгән. Сулыш чыгарганда җилкәне (башны гына түгел!) идәннән аерып, күтәреләбез.



2



Шулай ук аркага сузылып ятабыз, куллар баш очыннан сузылган. Сулыш чыгарган вакытта бер аякны тездән бөклибез дә, гәүдәне күтәреп, кулларны тез астында кушабыз. Бу күнегүне һәр аякка, чиратлаштырып, эшлибез.

3

«Китап» күнегү. Аяклар идәннән күтәрелеп, тездән бөкләнгән, гәүдәне куллар белән терәтәбез. Терсәкләр идәннән аерылган. Сулыш чыгарган вакытта аякларны гәүдәгә таба китерәбез. Аңлагансыздыр инде – китап ачыла-ябыла.



4



«Скалолаз» күнегүе. Кул һәм аяк очлары ярдәмендә гәүдәне күтәреп торабыз. Сын тип-тигез булырга тиеш. Сулыш чыгарганда, чиратлаштырып, сул аякны – уң, уң аякны сул кулга таба китерәбез. Аякны үз урынына кайтарганда сулыш алабыз. Физик күнегүләр ясаганда сулышны бервакытта да тоткарламагыз.

5



Шулай ук кул һәм аяк очлары ярдәмендә гәүдәне күтәреп тотабыз. Бу күнегүдә терсәкләр эшли. Эч мускуллары тонуста булсын. Терсәкләрне, чиратлаштырып, бөклибез һәм турайтабыз.

6



Аркага ятабыз. Аяклар, 90 градуслы почмак ясап, тездән бөкләнгән, куллар – баш астында. Җилкәләр идәннән аерылган. Чиратлаштырып, сул аяк белән – уң кул терсәген, уң аяк белән сул кул терсәген «очраштырабыз».

7

«Кайчы» күнегүе. Аяклар һәм арка идәннән аерылган. Куллар ярдәмендә гәүдәне тотабыз. Терсәкләр идәнгә тияргә тиеш түгел. Туры итеп сузылган аякларны кисештерәбез.



8



Бу күнегүләрне эшләгәннән соң, умыртка баганасын ял иттерер, тарттырыр өчен, мәче кебек сузылабыз.



QR-код аша кереп, күнегүләрне видеодан да карап ясый аласыз.
Фото һәм видео: Анна Арахамия.



Яңа елдан – яңача!



Дуслар! Сез яраткан «Аш-су» рубрикасын яңача дәвам итәргә булдык. Хәтерлисездер, ноябрь санында тутырылган күркә боты әзерләү серләре белән оста хуҗабикә, аш-су остасы Венера АРСЛАНОВА бүлешкән иде. Венера үзенең яраткан шөгыленә бөтен вакытын багышлый. Пешекче булып эшләүдән кала, зур табыннар, мәҗлесләр өчен ризык әзерләү тәҗрибәсе дә зур аның. Шуңа күрә Венера ханымның бар осталыгыннан файдаланып, алдагы саннарда да аның шәхси рецептлары буенча төрле сыйлар белән бүлешүне дәвам итәрбез. Бүген безнең табында – тутырылган чуртан балыгы.





Кирәк

1 кг тирәсе чуртан балыгы / 1 баш суган / 1 татлы борыч / 100 г атланмай / 50 г көнбагыш мае / 1 йомырка / тәмләткечләр (нинди булса да ярый) / аджика, майонез, тоз, борыч, яшелчә.





Эш барышы




■ Балыкның тәңкәләрен, саңакларын чистартабыз. Башын кисәбез дә, шуннан җайлап кына эчлеген чыгарабыз. Эчен әйбәтләп юабыз. Башыннан алып койрык очына кадәр тиресен салдырабыз.

■ Койрык очына җиткәч, 1–2 см калдырып, ите белән умырткасын кисеп алабыз. Балыкның койрык очы белән тиресе капчыкны тәшкил итәргә тиеш.




■ Балыкның итен умыртка сөягеннән аерабыз да, ваклап турап, иттарткыч аша үткәрәбез.

■ Суганны ваклап турап, атланмайда кыздырабыз. Ит янына кушабыз. Шунда ук йомырка, бераз туралган татлы борыч, яшелчә, тәменчә тоз, борыч, тәмләткечләр өстибез. Массаны яхшылап болгатабыз.




■ Әзер эчлекне балык тиресеннән ясалган капчыкка тутырабыз. Балыкны көнбагыш мае белән майлаган табага салабыз, башын да шунда ук салып пешерәбез. Балыкны майонез һәм аджика кушылмасы белән майлыйбыз. Тиресе ярылмасын өчен, дүртбиш җирдән таякчык белән тишеп куярга да онытмагыз.




■ Табага 1 см тирәнлектә су салып, балыкны 30–40 минутка духовкага озатабыз. Әзер балыкны суынгач кына кисеп, табынга яшелчә белән чыгарабыз. Башын балык янына куеп, тоташ балык формасына китерәбез.



Видеоны карар өчен смартфонның камерасын QR-кодка якынайтыгыз.
Фото һәм видео: Анна Арахамия.

PRESSA

Өйнең яме – гөлләрдә!

Яңа елда яңа сәхифәбезне өйдә үсүче гөлләргә багышларга булдык. Укучыларыбыз арасында гөлләр яратучылар күп. Ә бәлки, кемдер әлегә аларга кызыгып, бу хакта хыялланып кына йөридер. Яңа сәхифәбез гөлләр телен өйрәнергә теләүчеләр өчен файдалы булыр дип ышанабыз.



Хлорофитум

Иң талымсыз гөлләрдән ярыш оештырсалар, хлорофитум җиңәчәк. Аны бүлмәнең яшел үпкәсе дип атасаң да була. Һавадагы зарарлы матдәләрне үзләштереп, ул күп итеп кислород бүлеп чыгара. Хәтта бүлмәдәге гөмбәчекләрне һәм аллергеннарны юк итәргә дә сәләтле. Аңа пар, югары температура, корылык, күләгә куркыныч түгел, аш бүлмәсендә дә яхшы үсә. Салкынга да, эссегә дә чыдам, шулай да иң кулай температура – 18 градус җылылык.

Суны аз-азлап даими сибеп торырга кирәк. Кышкы якта суны атнага яки хәтта ике атнага бер генә сибәләр. Тамырларында су запасы туплый торган бүлбеләр бар. Шулай да суны озаграк сипмәсәң яки бүлмәдә артык коры булса, яфракларының төсе тоныклана, очлары көя башларга мөмкин.

Әлеге гөл якты, ләкин кояш төшми торган урынны ярата. Хәтта бүлмә түрендәге караңгырак урында да хлорофитум үзен яхшы хис итәчәк.

Җәй көне хлорофитумны урамда да үстерергә мөмкин. Ләкин көндез кояш туп-туры караган, су тонып тора торган урын булмасын.

Кечкенә гөлне ел саен, зурракларын ике-өч елга бер яңа туфракка күчереп утырталар. Моның өчен бер өлеш кәсле туфракка бер өлеш черемә һәм бер өлеш ком кушыла. Күчерер өчен иң яхшы вакыт – кыш азагы яки яз башы.

Хлорофитумны мыекчаларында яралган бәбчекләрдән яки төптән чыккан үсентеләреннән үрчетәләр.

Фәнни исеме – Шлюмбергер Зига кактусы. Кактуслар төркеменә керсә дә, алардан аермалы буларак, декабрист эссе һаваны һәм артык яктылыкны яратмый, дымга мохтаҗ. Кыш көне чәчәк атканга, аңа халык декабрист дигән атама биргән.

Декабрист туры төшкән кояш нурларын күтәрми. Иң яхшысы – аны көнчыгышка караган тәрәзә төбенә урнаштыру. Бу гөлгә җәй көне дә җиләс, салкынча урын һәм әледән-әле өстенә су бөркеп тору кирәк.

Чәчәккә бөреләнгән декабрист гөлен боргаларга, урынын үзгәртергә ярамый. Һава температурасы 25 градустан артмаган, 18 градустан ким булмаган бүлмәдә яхшы үсә ул. Суны, артык мул итми, даими сибәргә кирәк. Чүлмәкнең тәлинкәсенә мүк салып калдырсаң була, ул артык дымны үзенә сеңдерә. Көзгә якта үсемлекне салкынча урынга күчерегез. 10 градустан 15 градуска кадәрге температурада чәчәк бөреләре күбрәк ярала.

Июнь аенда гөлгә санитар кыскарту үткәрелә. Артык озын булып үсеп киткән тармакларны сындыралар. Декабристны әледән-әле зуррак чүлмәккә утырталар. Зур гөлне бүлгәләп, аерым савытка да утыртырга була. Күчерү өчен яхшы вакыт – чәчәк атып бетергәннән соң, кыш азагы. Туфракның суккулентлар өчен махсус әзерләнгәнен сайлагыз.

Гөлне үрчетергә теләсәгез, өзгәннән калган ботак очларын тармакландырырга мөмкин. Бу очракта тамыр чыгарганны озаграк кына көтәргә туры киләчәк.



Декабрист



Пуансеттия

Өске яфраклары кып-кызыл чәчәкне хәтерләткән бу күпьеллык гөлне халыкта Раштуа йолдызы дип атыйлар. Аның сары, алсу яфраклы төрләре дә бар. Тумышы белән кояшлы Мексикадан. Ботак очларында кызыл йолдыз кебек балкыган яфракларын күпләр чәчәк дип уйлый. Ләкин пуансеттия купшы чәчәк атмый. Салкынча һаваны, җилсез һәм якты урынны ярата. Кулай температура 16 градус чамасы. Туры төшүче кояш нурлары бу гөл өчен зарарлы. Су чүлмәк төбенә җыелып тормаслык кына итеп сибелә. Салкын су сипкәнне яратмый. Җәй көне суны ешрак сибәргә, ара-тирә яфракларына да бөркергә мөмкин.

Март аеннан пуансеттиянең тынлык чоры башлана. Ботаклары шәрәләнсә, димәк, гөл ял итә. Бу вакытта су сибүне сирәгәйтәләр. Ботакларын 10–15 см тирәсе кыскартып кисеп, гөлне салкынча (12 градус чамасы) караңгы урынга куялар. Күчереп утырту өчен иң яхшы вакыт – май ае. Пуансеттия өчен кулай туфрак составы – өч өлеш кәс туфрагы, өч өлеш черемә, өч өлеш урман туфрагы (яки таркала башлаган яфраклар), бер өлеш ком.

Кабаттан «чәчәк аттыру» өчен, сентябрьдән башлап ике ай дәвамында көннең озынлыгын ясалма рәвештә кыскарталар. Көн озынлыгы 8–10 сәгатькә генә калдырыла, калган вакытта гөлне йә каплап, йә караңгы урынга күчереп торалар. Ике айдан якты урынга куялар. Салкынча, якты урында аның төсе җетерәк була. Үрчетергә уйласагыз, кисkәннән калган тармакларны ташламагыз. Аларны бераз «Корневин» эремәсендә тотып, туфракта тамырландырырга мөмкин. Онытмагыз: сөтле үлән (молочай) төркеменә кергән пуансеттиянең согы агулы.

Фото: www.pixabay.com

тест: Үзегезне кулда тота беләсезме?

Сорауларга «Әйе» йә «Юк» дип җавап бирегез.

1. Кемгәдер охшарга тырышу авыр тоела.

2. Җае чыкканда, тирә-юньдәгеләрнең күңелен күрер өчен яисә игътибар җәлеп итәр өчен юләргә салына алам.

3. Миннән ярыйсы гына актер чыгар иде.

4. Чынлыкта алай булмаса да, мине артык нык борчылучан дип уйлыйлар.

5. Компаниядә мин игътибар үзәгенә сирәк эләгәм.

6. Төрле ситуацияләрдә һәм төрле кешеләр белән аралашканда үземне төрлечә тотам.

7. Чын күңелдән ышанган әйберемне генә яклый алам.

8. Эшемдә һәм кешеләр белән кирәкле мөнәсәбәт урнаштыруда мине нинди итеп күрергә телиләр, шундый булып күренергә тырышам.

9. Яратмаган кешеләрем белән дә дустанә мөнәсәбәттә була алам.

10. Мин һәрвакыт ничек бар, шундый булып калам.

Балларны санагыз. 1, 5, 7 нче сорауларга «Юк» дип җавап бирсәгез, берәр балл санагыз. 2, 3, 4, 6, 8, 9, 10 нчы сорауларга «Әйе» дип җавап бирсәгез, шулай ук берәр балл кушыгыз.

0–3 балл: аралашуда контролегез түбән. Үз-үзегезне тотышыгыз тотрыклы. Төрле ситуациядә сез аны үзгәртергә кирәк дип санымйсыз. Аралашуда чын күңелдән ачылып китәргә сәләтле сез. Туры сүзле булуыгыз аркасында сезне аралашуда кыен кеше дип санаучылар да бар.
4–6 балл: аралашуда контролегез уртача. Сез ихлас, ләкин эмоцияләрегезне күрсәтергә яратмыйсыз. Үз-үзегезне тотышыгызда якын-тирәдәгеләрнең фикере белән исәпләшегез.
7–10 балл: аралашуда контролегез бик югары. Сез теләсә кайсы рольгә тиз керәсез, ситуация үзгәрешләренә дә бик сизгер. Тирә-юньдәгеләргә нинди тәэсир ясавыгызны да алдан белергә сәләтле хәтта.

йолдызнамә февраль

Кучкар Бар яктан да уңышлы ай көтә сезне. Эш ягыннан да яңа мөмкинлекләр һәм җиңүләр булачак. Тормыш энергиягез, максатчанлыгыгыз, көчегез үзегезгә генә түгел, янәшәдәгеләргә дә ярдәм итәр.

Үгезбозау Елның беренче аен актив уздырганнан соң бераз сүлпәнлек, төшенкелек сизәрсез. Ләкин бу чор белемегезне арттыру өчен кулай. Гадәти көндәлек тормышыгызны яңа җирләр өйрәнүгә алыштырып карагыз.

Игезәкләр Кызу һәм үзгәрешләргә бай ай көтә сезне. Шуңа күрә карарларны тиз кабул итәргә, тормышның бормалы юлларында сыгылмалы булырга әзер торыгыз. Ай ахыры нәтиҗәсе белән сөендерер.

Кысла Бу чорда акча мәшәкатьләре, салымнар, рәсми кәгазь эшләре белән шөгыльләнергә туры килер. Авыр хәлгә калмас өчен, компромисска килергә әзер булыгыз. Айның икенче яртысында үзегезне бөтенләй башкача хис итә башларсыз.

Арыслан Бу аегыз «Эзләгән – табар» девизы белән узар. Авыр да, уңышлы да чор көтелә. Шуңа күрә бернидән курыкмагыз, максатыгызга барыгыз, ләкин артык мавыгып ташламагыз.

Сөмбелә Шәхси тормыш белән эш арасында бәргәләнергә туры килер. Хәер, мондый очракларда үзегезне әзерлекле тота аласыз. Шуңа күрә алга баруыгызны дәвам итегез. Ай башында тапкан яңа танышлар сезгә киләчәктә зур файда китерәчәк.

Бизмән Янәшәдәге кешеләр белән катлаулы мөнәсәбәтләр туар. Ләкин тоемлау көчегезгә ышанып, тормыш тәҗрибәсенә таянып, сайлаган юлыгыз белән баруны дәвам итегез.

Чаян Бик күп мәсьәләләр хәл итәргә туры килер. Ай ахырында гына җиңел сулап куярга мөмкин булачак. Ай башында гаиләгезгә карата аеруча игътибарлы булыгыз. Алар сезнең ярдәмгә мохтаҗ.

Укчы Максатчанлыгыгыз көннән-көн арта. Сездә таулар күчерерлек көч бар. Иң мөһиме – теләк булсын. Бөтен әйбергә дә берьюлы тотынмагыз. Юкса үзегез дә буталып бетәчәксез.

Кәҗәмөгез Сезнең алда бик яхшы перспективалар ачыла. Эш һәм шәхси тормыш арасында баланс табарга тырышыгыз. Бу – эмоция ягыннан янып бетмәс өчен кирәк. Үзегезне күрсәтә алуыгызда шик юк.


Сукояр Ай башында сезнең өчен зур мөмкинлекләр ачылыр. Игътибарыгызны читкә җибәрмичә, үз эчегезгә юнәлтегез. Барлык җиңүләрегез, тотрыклыгыгыз нәкъ менә шул сәләтегезгә бәйле.

Балык Тормышыгызның бу чорында дусларыгыз терәк булыр. Алар ярдәменнән баш тартмагыз. Эмоцияләр ягыннан тирәнтен үзгәрешләр башланыр. Шул сәбәпле, хисләрегез бик еш үзгәреп торыр. Ләкин бу берничек тә эчке тотрыклыгыгызга тәэсир итмәс.

«Хатын-кыз галәме» сәхифәсен Чулпан ГАЛИӘХМӘТОВА, Лилия ГӘРӘЕВА, Алсу ШАКИРОВА әзерләде.







КАЙТУ

Рәссам Ринат Хәнәфиев 1963 елда Чистай шәһәрендә дөньяга килгән. «Әтиебез Сәлимҗан һәм әниебез Оркыя өч бала үстерделәр: абыем Рөстәмне, мине һәм Гөлия сеңлемне. 1968 елда гаиләбез Кыргызстанның Җәлалабад шәһәренә күченде. Рәссамлык сәләтем дә шушы республика шартларында формалашты. Сынлы сәнгать белән мавыгып китүем бары тик әнием тәрбиясеннән генә дип саныйм, – диде Ринат Сәлимҗан улы. – Чөнки безнең газиз әниебез искиткеч яхшы чигүче иде. Бәйли дә иде ул, кул эшләнмәләрендәге бизәкләре дә һәрчак төрле иде аның. Әнием миңа шушы дөньяның бар матурлыгын күрергә өйрәтте. Әлхәмдүлилләһ, әниебез исән-сау! Чистайда яши. Без ул калага әни янына, туганнарыбыз янына әле дә кайтып йөрибез».

Ринат балалар сынлы сәнгать мәктәбен, урта мәктәпне, 1986 елда С. А. Чуйков исемендәге Кыргыз дәүләт сынлы сәнгать училищесын тәмамлаган. Армиядә полк рәссамы булып хезмәт иткән. Аннары Җәлалабад театрында рәссам булып эшләгән. Бәхетле гаилә корган. «Маргарита белән училищеда бергә укыдык, ул да – рәссам. Ике улыбыз бар. Руслан – архитектор, интерьер дизайнеры белгечлеген үз итте, университет тәмамлады, бүгенге көндә шушы юнәлештә. Рөстәм политехника институтыннан соң электроника өлкәсен сайласа да, хәзер дә рәсемнәр ясый», – ди оста. Гаилә 1990 нчы елларда Бишкәккә күченгән, бүген дә шунда көн күрә. Әңгәмәдәшем – шул ук еллардан башлап бихисап күргәзмәләрдә катнаша башлаган иҗатчы. Ул – Кыргызстан Рәссамнар берлеге сафында. 2012 елдан башлап Кыргызстанның Г. Айтиев исемендәге милли сынлы сәнгать музеенда узучы бар төр күргәзмәләрдә катнашып килә. Киндерләрдәге темалары – ел фасыллары, Ватан, яшәеш, «Кыя белән мәк чәчәге» картинасындагы кебек фантастик мәхәббәт мизгелләре, хатын-кыз образлары һәм шушы еллар афәте сәбәпле туган югалтуларга багышламалар...




«Мин күп язам, шуңа күрә үз шәхси күргәзмәләремне ачуга күбрәк өстенлек бирәм. Залларга һәрчак 50–60 яңа картинамны элән. Күңелем күбесенчә фәлсәфи күренешләр сурәтләүгә тартыла», – дип ассызыклады Ринат әфәнде. Ул Төркиядә, Мәскәүдә, Санкт-Петербургта оештырылган гомуми күргәзмәләрдә дә теләп катнашкан инде. Кайда гына булмасын, тамашачылар аның иҗатына һәрчак ихлас соклана.

2021 ел ахырында рәссам Казандагы «Окно» картиналар галереясында Казандагы үзенең беренче шәхси күргәзмәсен дә ачты. Бирегә ул «Кайту» дип аталган күргәзмә белән килде. «Мин инде күп еллар буе туган якка, әнием янына кайтам. Әмма Татарстанга рәссам буларак чакырыла башлавыма – нибары бер ел. Бирердәге Рәссамнар берлеге белән моңа кадәр хезмәттәшлегем булмаганга үтә тыйнаклыгым комачаулады... Әмма мине Интернет аша республика рәссамнары үзләре эзләп тапты, һәм аларның чакыруларын кабул итеп, Татарстандагы берничә иҗади пленэрда катнаштым инде. Татарстан Рәссамнар берлегенә дә кабул ителдем.

Иҗатымдагы төп юнәлеш – абстракционизм, шул ук вакытта романтика стилен дә бик яратам. Уйлана белүче тамашачыларны үз итәм. Рәссамнар иҗатымны интеграль реализм сынлы сәнгать юнәлешенә кертә. Мин моңа каршы түгел. Интеграль реализм – минем иҗатта кечкенә сюжетларымның зур бер уй-фикергә берләшүе ул. Холкым да шундый: картиналарымны тиз язам. Һөнәрем, уңышларым һәр яңа көн саен сөендерә генә бара!» – диде талант иясе Ринат Хәнәфиев.

Бишкәк ерак, әмма без бу рәссамыбызны Татарстанда яңа күргәзмәләре белән көтеп калабыз. Ринат Сәлимҗан улының хезмәтләре республика рәссамнары иҗатыннан аерыла. Киндерләрендәге экспрессив мохит безне дөнья төрлелеген күрергә илһамландыра.

Зилә НИГЪМӘТУЛЛИНА




РИНАТ ХӘНӘФИЕВ



2022 ЕЛДА ДИНИ БӘЙРӘМНӘР
(һиҗри исәп буенча 1443–1444 нче еллар)

4 февраль – Рәҗәб аеның беренче җомгасына каршы кич Рәгаиб кичәсе дип атала. Мөхәммәд пәйгамбәрнең әти-әнисе Габдуллаһ һәм Әминәнең бергә кушылуын искә алу кичәсе дә. Кече хаҗ – гомрә хаҗы да шушы айда кылына.

27–28 февраль – Мигъраҗ кичәсе. Мигъраҗ уразасы 100 төн ураза тотуга тиңләнә.

17 март – Бәраәт кичәсе, ягъни «ләйләтүл-Бәраәт». Бәхет һәм һәртөрле уңышлар, изгелекләр иңә торган изге көн. Нәкъ шушы төнне Аллаһы Тәгалә һәркемнең изге гамәлен һәм догаларында ялварып сораган үтенечләрен исәпкә алып, кешеләрнең язмышы турында карар кабул итә.

2 апрель – изге Рамазан ае һәм ураза башланган көн. Коръән иңгән ай.

27–28 апрель – Кадер кичәсен рәсми билгеләү. Рамазан аеның соңгы ун кичәсенең берсе – Кадер кичәсе. Кадер кичендә Аллаһы Тәгалә Мөхәммәдне пәйгамбәр итеп сайлаган. Бу көндә кылган игелекләр мең ай эчендә кылынган яхшылыкларга караганда да хәерлерәк. Кадер кичендә гөнаһлар гафу ителә, догалар кабул була.

2 май – Ураза гаете.

2–4 май – Гайдел-фитыр көннәре.

21 май – Идел Болгарстанында ислам динен рәсми рәвештә кабул иткән көн (310 нчы – һиҗри ел, 922 нче – милади ел).

8 июль – Гарәфә көне. Хаҗ кылучылар тарафыннан Мәккә янындагы Гарәфә тавына бару һәм тау итәгендә намаз уку көне.

9 июль – Гайдел-Әдъхә, Корбан гаете. Ураза тәмамлангач, нәкъ 70 көннән соң башлана торган Корбан чалу бәйрәме. Тәшрикъ көннәре. Бу көннәрдә, фарыз намазларын укыганнан соң, Аллаһы Тәгалә ризалыгы өчен махсус догалар кылына.

10–12 июль – яңа мөселман елы – 1444 һәм мөхәррәм ае башланган көн. Хәер (зәкят) бирелә, изге гамәлләр кылына торган ай. Аллаһы Тәгалә бу көнне игелек кылучыларның гөнаһларын ярлыкар, савапларын арттырыр.

7–8 август – Гашура бәйрәме. Бу көнне мөнәҗәтләр әйтелә, күп итеп догалар кылына.

7–8 октябрь – Мәүлид бәйрәме. Пәйгамбәребез Мөхәммәд (с. г. в.) туган көн. Мәчетләрдә вәгазьләр укыла, хәер-сәдакалар таратыла.

Төзүчесе: хаҗи Абдулла ДУБИН.

Фото: Анна Арахамия

